1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН

2018 АПРЕЛЬ № 4

ISSN 0869-1398

Сөембикә



БЕР ТАМЧЫ ЯРАТУ ДА ДАРУ
табиб... яучы ролендә

ЮК
син бу сүзне әйтә беләсеңме?

АЛСУ ӘБЕЛХАНОВА СЫЙЛЫЙ
казанча тапалган ит

Венера АИТОВА:

ТАЯНУ НОКТАСЫ – БӘХЕТ БУЛЫРГА ТИЕШ

PRESSA.RU

Минем өчен син һаман да – 17 дә!..

Минем өчен син һаман да – 17 дә!..

Бу фотосурәтләр еракта калган кабатланмас мизгелләргә – Яшьлеккә алып китә... ...Шундый зур галәмдә меңнәр арасыннан бер-береңне эзләп табу – үзе үк могҗиза! Аны күргәч кабынган хисләр – иң саф, иң ихлас, иң садә... Йөрәктәге сагышы да – якты, татлы, моңлы... Беренче очрашу... Аның кебек башка берәү дә юктыр! Дөнья – матур, яшәү шундый рәхәт! Очар өчен канатлар кирәкми дә!.. Ярату, йөрәккә генә сыялмыйча, җанда шигырь булып бөреләнә... Һәм мәңгегә Син – Шагыйрь, Ул Илһамчың булып кала...



Рәшит ӘХМӘТҖАНОВ

МАТУРЛЫГЫ – СИННӘН БУ ДӨНЬЯНЫҢ

Яратам, дип тагын әйталмадым:
Таңнар атты, китә томаннар.
Ярый әле син бар бу дөньяда,
Ярый әле балкый бу таңнар.

Матурлыгың миңа күз йомарга
Мәңге ирек бирмәс, күрәсең...
Бар, әнкәңә йөгер, бу томанда
Ятлар күзләп йөри күрмәсен.

Таң җилләре тарый томан чәчен,
Җәйләүләрдән чыга көтүем.
Беләсеңме икән көтүченең
Кич җиткәнче сагынып бетүен.

Көн дә чыгам кояш каршына мин,
Әй зәңгәр дә инде бу таулар,
Ялтырыйлар көмеш чыклар монда,
Таралырга тора томаннар.

Таралсыннар... Сагыш көпә-көндез
Кылганнарга төшеп дөрләсен.
Матурлыгы – синнән бу дөньяның,
Мәхәббәте – миннән, күрәсең.

Рәсемдә: шагыйрьнең хатыны Луиза.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2018

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электронное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кулъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

4’2018



Фото: Ксения Богданова

Җитәкче-баш мөхәррир
Гөлнара Ильяс кызы САБИРОВА

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нәбирә Гыйматдинова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Айрат Сибагатуллин, Иркия Төхвәтуллина, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Эльвира Әхмәтова.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Җитәкче урынбасары 222-09-78
Рәмзия Кашапова
Баш мөхәррир урынбасары 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова

Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Дизайн-макет:
«ASAFIN GROUP»
Верстка:
Лариса Маликова

Тышлыкта:
Венера Аитова
Стилист-визажист: Маргарита Тимаева
Фото: Ксения Богданова

Бүлек мөхәррирләре:
Мәдинә Авзалова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Фәнзилә Мостафина
Ландыш Әбүдәрова
Фотокорреспондент
Ксения Богданова
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Равил Газизов

Формат: 225х290 мм.
Күләме 64 бит.

Басарга кул куелды: 28.03.2018 ел.
Заказ Е-733.
Тираж 5340.

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77
Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикә»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002



PRESSA.RU



Салисә ГӘРӘЕВА

Мин язларга гашыйк

Мин язларга гашыйк. Һәр яңа яз
Килгән саен җаным яңара.
Һәр яңа яз яңа ялкын бирә
Якты хисләр белән янарга.

Яңа җырлар шыта йөрәгемдә,
Яз җиленә каршы атласам.
Мин кояшка көлеп бармак яныйм,
Яңакларны сипкел капласа.

Көләч кояш, җирне назлар өчен,
Урал-таудан иртүк кузгала.
Йөрәгендә гөлләр үстерергә
Үз кояшын көтә кыз бала.

Кар пәрдәсен ерта умырзая.
Күлләр көтә аккош парларын.
Һәм, кояшны котлап шат яз белән,
Каен суза яшел тармагын.







Клара БУЛАТОВА

* * *

Апрельнең уналтысы –
Язның нәкъ кыл яртысы:
Кара җирләр ачыла,
Утырып яз атына,
Карамый да артына,
Күңел җәйгә ашыга.
Җәйгә ашыга.

Язларның да яртысы
Үткән инде. Ахырысы,
Ашыгыплар үткән,
Әйтерсең гел булмаган.
Ташулар да узмаган –
Су сызылып киткән,
Сызылып киткән.

Ә шулай да бу айда
Уйлар-хисләр өр-яңа
Җырлар бирә дөньяга...
Апрельнең уналтысы –
Язларның кыл яртысы:
Талда бөре уяна,
бөре уяна.



«Казаным». Айгөл Акманова-Окутан эше.

PRESSA.RU





БЕЗНЕҢ ТЫШЛЫКТА

ВЕНЕРАНЫҢ ТАЯНУ НОКТАСЫ
Гөлнур Сафиуллина

10

ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ



6

ҖӘСӘДЕМӘ ТИМӘГЕЗ!
Мәдинә Авзалова

ТАТАР ДӨНЬЯСЫ



БЕЗНЕҢ МАРАТ АБЫЙ
Роза Камалетдинова

24



18

КҮҢЕЛ КЫҢГЫРАУЛАРЫ
Мәдинә Авзалова



28

«ТОРМЫШТАН ЯМЬ ТАБАМ»
Гөлнур Сафиуллина



ЭЧТӘЛЕК

МӘДӘНИ ТОРМЫШ 



34 **КАРА ТӨННЕҢ АК ФӘРЕШТӘСЕ**
Роза Туфитуллова

ЯШӘЕШ 



44 **БЕР ТАМЧЫ ЯРАТУ ДА ҖИТӘ...**
Рита Сәлахова



48 **ТАРИХ, ТЫНЛЫК, ТАЛЛИН**
Чулпан Галиәхмәтова

ШУЛАЙ УК: 

14 **ИСЕМНӘРЕН ДӨНЬЯ БЕЛӘ!**
Ландыш Әбүдәрова

27 **ИРЛӘР НИГӘ ЭЧӘ?**
Илнар Зиннәтуллин

ХАТЫН-КЫЗ ГАЛӘМЕ 



62 **ГӨЛБАКЧАДА ЭШЛӘР БАР**

КИЛӘСЕ САННАРЫБЫЗДА: 

ТОРМЫШ КАГЫЙДӘЛӘРЕ. ФӘРИТ БИКЧӘНТӘЕВ

СЕРНЕ СӨЙЛӘРГӘМЕ-СӨЙЛӘМӘСКӘМЕ? ИЛАҺИ НИЯТ КЫЛДЫМ

«БӘРЕЛЕШ». КӘРИМ КАРА. ХИКӘЯ

ҺӘР ЭШНЕҢ ҮЗ ҖАЕ БАР. ӨЙ ҖЫЕШТЫРАБЫЗ



PRESSA.RU



Фото: Газинур Хафизов

ЯШЕ СИКСӘННӘН УЗГАН КЕШЕНЕҢ ҖӘСӘДЕН, ҮЛЕМ-КИТЕМ СӘБӘПЛӘРЕН АЧЫКЛАУНЫ СЫЛТАУ ИТЕП, ЯРЫП КАРАУ НИГӘ КИРӘК?



Мәдинә АВЗАЛОВА

ҖӘСӘДЕМӘ ТИМӘГЕЗ!

Бәхетемә, моңарчы беркайчан да монын нше җан өшеткеч проблемалар белән очрашырга туры килгәне булмады. Ә менә Әгерҗе районының Кичке Таң авылыннан килгән хат җитди уйларга салды.

«Безне, барлык өлкән яшьтәгеләрне, бер мәсьәлә борчый: җәсәдеңне ярып караулары... Ятсак-торсак, шул хәвефле хәлгә төшәсебезне уйлап, хәсрәт утында янабыз, – дип яза 92 яшьлек Рәйсә әби Зарипова. – Сугыш чоры баласы буларак, ачлык, ялангачлык, ятимлек ачысын күп күрдем. Сугыштан соңгы авыр елларны үз җилкәбездә күтәрдек, якты киләчәккә ышандык, балалар тәрбияләдек, оныклар үстердек.

ФИКЕР



Наилә ҖИҺАНШИНА,
ТР мөселманнары
Диния нәзарәтенең гаилә,
хатын-кызлар һәм балалар
эшләре комитеты җитәк-
чесе, Татарстанның
мөселман хатын-
кызлар берлеге рәисе

Татар хатын-кызлары үзләренең гаурәтләрен чит-ят кешегә күрсәтмичә яшәгәннәр. Ярып карауга дучар ителгәндә, хәтта үле гәүдә оялачак. Без, яшьләр, олы кешеләрнең васыятьләрен җиткерергә, аларны ярдырмаска тиешбез. Гәүдә – ул кыймммәтле хәзинә. Без бит халыкны яклый, саклый торган Конституцияле дәүләттә яшибез. Ул закон кеше үлгәч тә гамәлдә кала бирә. Димәк, үтәргә, якларга! Барыбыз да эчке әгъзаларыбыз үзебез белән күмелсен дип телибез. Олы кеше үлемгә әзерләнгәндә борчыла башлый, куркуга кала. Әйтәсе килгән сүзем: сәбәбе булмаганда рөхсәтсез ярдырырга ярамый!

Хәсрәтле еллар, шөкер, үтеп китте дигәндә, башыбызга ишелеп яңа кайгы төште: үлгәч, синең җәсәдеңне 60 чакрымдагы район үзәгенә илтеп, мөселман булмаган кешедән ярдырып, гүргә иңдерәчәкләрен уйлап җан әрни, йөрәккә шом керә. Мин – намазлы, динле карчык. Үз гаиләләре белән яшәүче ике балам миңа даими ярдәм итеп торалар. Бер дошманым да юк. Шушы яшемдә ярмаслар әле диган ышанычым бар иде дә, күптән түгел генә ике ел урын өстендә ятып, кызы тәрбиясендә вафат булган 97 яшьлек кодачабызның җәсәден яргач, бөтен авыл гөж килде. Бу хәл безнең авылда гына дисәм, ул бөтен районыбызны чолгап алган икән. Хөкүмәтебез ярып караган өчен алына торган дәүләт пошлинасына калган булса, җирләүгә дигән акчаны да биреп тормасын. Без аннан баш тартабыз! Авыл җирлеге башлыгы һәм участковый кемнең ничек яшәгәнен белеп тора. Алар медицина хезмәткәрләре белән берлектә ачыклый алалар бит безнең үлемнең сәбәбен. Җәсәдебезне мыскылламау чарасын күрерлек законнар чыгарсыннар иде. Дин буенча да, кешелеклелек, хөрмәт дигәннән дә бу безне бик кимсетә».

Әлеге хат әби-бабайларны гына түгел, безне дә тирән борчуда калдырды. Чыннан да, ни өчен яше сиксәннән узган олы яшьтәге кешеләрне вафатыннан соң ярып карыйлар? Үлем-китем сәбәпләре бу очракта бары бер генә: адәм баласы яшисен – яшәгән, күрәсен – күргән, ягъни картайган. Аның сәгате суккан... Ә картайгач, үзегез беләсез, нинди диагноз куйсаң да, дөрес була. Әлбәттә, мәетне пычак (хирурглар телендә әйтсәк, скальпель) астына салулар Федераль законга таянып эшләнә. Һәм ул закон бер бүген генә уйлап табылмаган, бүген генә кабул ителмәгән. Ул әз-мәз үзгәрешләре белән, менә инде ярты гасыр гамәлдә булып килә. Бүген әлеге мәсьәлә «Россия Федерациясендәге гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» дип аталган 323 нче номерлы Федераль законның 67 нче маддәсенә таянып хәл ителә. Мәгълүм маддәдә, автор әйткәнчә, «җәсәдебезне мыскылламау чарасын...» табарлык юллар ачык күрсәтелә. Тик безгә аны куллана белергә, кирәк чагында үз хокукларыбызны дөрес һәм грамоталы итеп раслый алырга гына кирәк. Үлгәч: «Ярмагыз мине», – дип ята алмыйсың. Шуңа бу хакта әле исән чагында уйларга кирәк. Моргка юлны ничек «кисәргә», ничек итеп бу хәлләрдән котылырга?

Ярмыйча да...

Шулай итеп, гәүдәне ярып карау – ул иң элек кешенең үлү сәбәпләрен төгәл ачыклау өчен кирәк. Әгәр дә инде үтерүгә яки табиб хатасына шик юк икән, бу очракта мәетне ярып тормаска да була. Кеше үлгәннән соң ярып карау процедурасына катгый каршы килү – ул безнең кирелектән генә тормый. Аның сәбәпләре күптөрле: әйтик, ул дини кеше булган, аның теләге шундый булган, васыять итеп әйтеп калдырган...

Патологоанатомик тикшеренүләрдән баш тартуның төп сәбәбе – мәрхүмнең теләге һәм дини тыюлар.

Үлеме шикле күренгәндә

Мондый вакытта, вафатыннан соң, мәетне моргка илтәләр. Гәүдәсен ярып, аның нидән үлүен тикшерәләр. Әгәр дә үтерү очрагы булмаганда, табибның авыруны дөрес дәвалаганмы-юкмы икәнлеге ачыклана. Табиб хатасы да шул чакта күренә. Ялгыш диагноз, ялгыш бирелгән дарулар... Әмма моннан, гадәттә, табибка берни булмый. Янәсе, ул тәҗрибә туплый. Ярып карарга ашкынып торуның бер сәбәбе шулдыр дип беләм.

Законда билгеләп үтелгәнчә, ярдырмыйча калырга ярамый дип, түбәндәге очраклар күрсәтелә: үз үлеме белән үлмәү (транспорт һәлакәтен, бәхетсезлек очракларын да кертеп), нилектән үлгәнен белмәү, хастаханәдә үлеп китү, авыруның ярамаган дару эчү нәтиҗәсендә үлеп китүе, йогышлы чирләрдән, кан салудан үлү, экологик һәлакәт нәтиҗәсендә вафат булу, бала тудырганда гомер өзелүләр, һичшиксез, ярып карауны таләп итә. Мондый хәлдә берниндиди гариза да булышмый. Һәм бу аңлашыла да.

PRESSA.RU

ФИКЕР



Илнар ГЫЙРФАНОВ,
юрист

Чыннан да, бу – җитди мәсьәлә. Һәрнәрсәнең үз тәртибе, үз процедурасы бар. Биредә дә шулай. Кеше вафат булган икән, иң беренче эш итеп: үз үлеме белән вафат булганмы дигән сорау туа. 90 яшьлек бабайлар, дисез. Ә бәлкем, аларны үтергәннәрдер? Азмы агулап үтерү очраклары? Моны да истән чыгарырга ярамый. Төрле хәлләр булырга мөмкин. Безнең законнар кешегә начарлык кылыр өчен уйлап чыгарылмаган. Барысы да уйланылган. Туганнарына авыр, әлбәттә. Минемчә, бу очракта мәсьәләгә берьяклы гына килергә ярамый.

Васыять итеп әйтәм

Әлбәттә, мәетне ярып карарга-мы-карамаскамы икәнлеген участок табибы яисә фельдшер хәл итә. Әйе, Разия әби хаклы: моны фельдшер да әйтә ала. Югарыда санап кителгән сәбәпләр юк икән, мәетне яру мәҗбүри түгел. Шулай да, ул-бу була калса дип, юристлар әйткәнчә, язмачамы, шаһитлар барында телдәнме теләгеңне

Үлем турында исән вакытта ук кайгыртып куярга кирәк.

алдан белдереп кую бер дә комачауламас. Гаризада исем-фамилияң, кайда яшәгәнлегең күрсәтелә. Числосы һәм имзасы куела. Мондый гаризаны мәетне җирләү белән шөгыльләнүче оешмалар исеменә дә язарга мөмкин. Нотариус та кирәкми. Әгәр дә гаризаны игътибарсыз калдырып, мәетне әлеге дә баягы «сынаулар»га дучар итәләр икән, бу закон бозу була.

«Озак еллар авырып, урын өстендә яткан 97 яшьлек әбинең җәсәденә кагылу мәҗбүри идеме?» дигән сорауны Әгерҗе районы үзәк хастаханәсенең баш табибы Эдуард Овчинниковка бирдек.

– Без закон нигезендә эшлибез. Кешеләрнең еллар дәвамында табибларга күренмәве ул әле ярмау өчен нигез була алмый. Чөнки безнең илдә һәркем, шул исәптән, 100 яшьлек әби-бабайлар да авырганда табиб ярдәме алу хокукына ия. Әгәр дә кеше ел саен үткәрелә торган гап-гади процедураны – диспансеризация яки флюорографияне үтмәгән икән, ул чагында ярмыйча җирләү турында сүзнең булуы да мөмкин түгел. Әмма якыннарының, кешенең исән чагында үзен ярмауны сорап язган гаризасы бар икән, кагылмаска мөмкин, – диде ул.

Патологоанатомик тикшеренүләрнең һәркайсы акча белән бәйле булуын да искәртик. Иминият компаниясе аларга бит акчаны факт буенча түли. Аннары... мәсьәләнең тагын бер җитди ягы бар: адәм баласы мал-мөлкәт бүлешүгә килгәндә, иң хәтәр адымны ясаудан да чирканмый. Тормыш катлаулы һәм рәхимсез, законнар да елдан-ел кырыслана, катгыйлана бара. Мондый хәлдә безгә бары югарыда санап үтелгән үз хокукларыбызны белергә һәм аларны вакытында үтәргә генә кирәк.

АВЫЛ ӘНИЛӘРЕНӘ ӨСТӘМӘ ТҮЛӘҮЛӘР

Илнең яңа демографик программасы нигезендә беренче бала тапкан әниләргә түләүләр кертелүе тормышларын көч-хәл белән алып барган гаиләләр өчен зур ярдәм булды. Инде менә тагын бер шатлыклы хәбәр: монысы авыл җирендә яшәүче яшь әниләргә кагыла. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының матбугат хезмәте хәбәр иткәнчә, быелдан республикабыз авылларында яшәүче 25 яшькәчә булган әниләргә, беренче балалары өчен 50 мең сум, ә 29 яшькәчә әниләргә өченче балалары өчен 100 мең сум акчалата өстәмә түләү кертелде.

Мондый өстәмә түләүләрне Россия Федерациясе гражданлыгы булган, авыл җирендә өч елдан да ким яшәмәгән хатыннар дәгъвалый ала. Һәм ул 2018 елның 1 гыйнварыннан соң гына туган балалар өчен бирелә.

Әлеге түләүләр тиктомалдан эшләнмәгән. Авыл җирендә бала туулар кими бара. Әйтик, Татарстанда туган балаларның 83 проценты – шәһәргә, 17 проценты авылга туры килә. Моның сәбәбе авылларда бала табу яшендәге хатын-кызларның кимүе һәм кияүгә чыкканчы ук шәһәргә китүе белән аңлатыла. Демографик хәлгә йогынты ясый торган тагын бер җитди нәрсә – бала табучы хатын-кызларның яше елдан-ел олыгая бара. Мисал өчен, 1990 елда күбрәк 25–26 яшьлек хатын-кызлар бала тапкан булса, 2016 елда 28–29 яшьтәгеләр әни булган.



«БЕЗ САЙЛЫЙБЫЗ, БЕЗНЕ САЙЛЫЙЛАР»

Фәнис МОТЫЙГУЛЛИН

Мәгълүм бер фильмдагы әлеге җыр юллары күпләргә таныш. Һәркем ышанычлы, сөйкемле, иң мөһиме – үзенә туры килерлек икенче яртысын эзли. Әмма кайвакытта нәрсәдер барып чыкмый гына инде – нәрсәдер туры килми. Кешеләр бит автомобиль детале дә, шөреп-гайка да түгел – бер-береңә яраклашып була кебек. Чыдау-ияләнү соңрак – бергә яши башлагач кына киләчәк, иң әүвәл үзеңә ярарлык кешене табарга, аны үзеңә каратырга һәм никахка хәтле үзеңнән ычкындырмаска кирәк.

Моңа ничек ирешергә соң? Психоаналитик Зигмунд Фрейд язганча, һәркем үзенең әти-әнисенә охшаш кешене эзли. Кайсы ягы белән һәм ни дәрәҗәдә охшаш булырга тиеш – бу хакта әйтүче юк. Моны ачыклау өчен бик катлаулы тикшеренүләр үткәрергә кирәктер, бер-берсенә туры килүләрен кеше, гадәттә, бер-берсен очраткач, күзләренә карап аңлаша. Бу – язмыштыр.

Ир-атлар хатын-кызның чибәр төс-кыяфәтле, төз буй-сынлы һәм буйсынучан булуын тели дигән ялгыш уйдырма яши. Бөтенесен дә бер калыптан сугып булмый, билгеле, һәркемнең үз таләпләре. Әмма күпчелек ир-ат гомерлек яр эзләгәндә бөтенләй башка сыйфатларга ия булган һәм яшьлегендә бергәләп күңелле вакыт уздырган кызларның капма-каршысына игътибар итүчән. Киресенчә дә булырга мөмкин: яшьлек мавыгуыннан арынып бетә алмаган ир-атлар шундый юлга бара һәм торабара мондый «рәхәт»нең ахыргы тәмен үзләре генә беләләр. Мәхәббәт өчен теләсә нинди хатын-кыз яраса, тормыш итү өчен яр сайлаганда бүтән үлчәм бирәмлекләре кирәк. Күпчелек ир-ат хатын-кыз чибәр, акыллы, уңган, җенси яктан канәгатьләндерерлек булырга тиеш дип уйлый. Уйлау гына бер хәл әле, әмма бөтен яктан килгән кеше балавыздан ясалган сыннар музеенда гына очрыйдыр. Белгәннәр фикеренчә, алда аталган сыйфатларның берсе генә табылганда да, андый хатын-кызны күз угында тотарга ярый, әмма ашыкмаска кирәк. Ике сыйфатка ия икән – аны инде, гомумән, ычкындырмаска кирәк, аңардан яхшы хатын чыгачак. Өч сыйфатны үзенә сыйдырган хатын-кыз очраса – кулыннан тотарга да мулла абзыйга никах укытырга йөгерергә. Син ваемсыз гына Фрейд теориясен өйрәнеп ятканда, өлгеррәк ир-атның ул кызга өйләнеп куюы бар. Ә дүрт сыйфатка ия булган хатын-кызны очрату – ул инде бәхет тавының түбәсенә менеп, байрак кадауга тиң, әмма андыйлар әлегә тумаган.

Хатын-кыз артык акыллы булырга тиеш түгел дигән ир-атларның кайсы ялгыша, кайсы ялганлый, әмма берәүнең дә хатынының акылсызлыгы аркасында кызарасы килми. Акыллы дию, әлбәттә, физикадан өй эшен күчертә алырлык булсын дигән сүз түгел, әмма бөтен укыганы социаль челтәрдәге «статус»лар гына икән – мондый хатын-кыз белән акыллы ир-атка бер дә кызык булмас. Тормышта гел җитди дә булып бетеп булмый, юмор хисе киеренкелекне, сорылыкны бетерергә ярдәм итә – янәшәсендә шундый кеше булган ир-атлар күпкә бәхетле. Гомер бакый чытык, һич канәгать була белмәгән йөзне күреп тору тормышның ямен дә, ир-атның дәртен дә сүндерә, шуңа күрә ешрак елмаегыз әле, хатын-кызлар, сезгә бит ул бик килешә!

Алда әйтеп үтелгән сыйфатлардан тыш, ир-атлар әле тагын хатын-кызларда тыныч холыкны югары бәяли. Артык темпераментлы булу – гаиләле кеше өчен бөтенләй үк туры килеп бетми торган вариант. Дәртле булу бик яхшы, әмма гаилә тормышы бит йокы бүлмәсендә генә бармый. Очрашып йөргәндә ызгыш-талаш, мөнәсәбәтләрне ачыклау һәм соңыннан татулашу бик кызык тоелса да, бергә яши башлагач, мондый тормыш тиз туйдырачак, һәм ир-ат көннәрдән бер көнне качачак. Аларны тагын хатын-кызның мәрхәмәтлелеге, кайгыртучанлыгы һәм тугрылыгы җәлеп итә. Мөнәсәбәтләрдә генә түгел, ә ир-атның дөньяга карашына, инануларына тугрылык. Ир-ат тормыш иптәшен сайлаганда үзенең мавыгуларын, карашларын, фикерен бүлешә алырлык кеше эзли. Үз хатынында мондый сыйфатларны күрмәсә, ул андыйны читтә табачак.

Тышкы кыяфәт тә соңгы урында түгел, тормышның яме пешкән аш белән юылган киемдә генә түгел – кирәк икән, анысын гына ир-ат үзе дә бик яхшы башкара ала. Оекбашны үзе юып кигән, үзе пешергән ризыкны ашап үлүчеләр турында ишетелгәне юк әле.

Хатын-кызда ир-атларга ошый торган тагын бер сыйфат – аның үз-үзенә ышануы. Бу кешене тышкы кыяфәткә караганда да күбрәк бизи. Кыюсыз, кеше фикеренә бәйле булганнар белән җиңел түгел. Хатын-кыз – әни кеше, балаларны көчле, бәйсез шәхес итеп үз-үзенә ышанганнар гына тәрбияли ала. Әмма артыгын кыланып ташларга да кирәкми, балалары белән бергә хатын ирен дә тәрбияли, үзгәртә башласа – яхшыга илтеп җиткермәячәк. Бу очракта «леди-босс» дигәнне дә әйтеп үтү кирәктер. Андыйларны ошатамы ир-атлар? Әлбәттә, ошата, аны күрер өчен бар дөньясын ташлап чабарга әзер, әмма өйдә түгел, эштә. Ир-ат үзенең табигате белән аучы, ә ике аучы бер сукмакта очрашса, билгеле ки, аларның юллары аерыла.

Беребез дә башкаларның уйларын укый алучы Вольф Мессинг түгел, һәркем үзе ни теләгәнне һәм сайлаган кешесенең ошамаган якларын әйтә ала торган булса, киләчәктә мәшәкатьләр дә азрак, нервылар да ныграк булыр иде. Ир-атлар идеаль хатын-кыз эзләми, аңа яраткан, якын кешесе кирәк. Ә тәҗрибәсе булганнар, картайган көнеңдә кара-каршы утырып чәй эчкәндә сөйләшеп туя алмаслык кеше эзләргә кирәк, диләр. Ә эзләгән табар!

PRESSA.RU

ВЕНЕРАНЫҢ ТАЯНУ НОКТАСЫ

**– Утыз секунд... Егерме... Ун... Башладык!
Турыдан-туры эфирда 26 минут озакмы-түгелме? Ток-шоу алып бару өчен ничә ел әзерләнергә кирәк? Студиягә чакырылган кунактан ничек фикерен суырып алырга? Татарча ток-шоу башкалардан аерыламы-юкмы? Һәр кичне үз аягың белән ут эченә – пожарга (турыдан-туры эфирда эшләүне ул үзе шулай чагыштыра) атлап керү өчен кайдан көч алырга?
Бүгенгә әңгәмәдәшебез – «Татарстан–Яңа гасыр» телеканалында эфирга чыгучы «Таяну ноктасы» социаль-иҗтимагый мәгълүмати-аналитик тапшыруының алып баручысы Венера АИТОВА (ИВАНОВА).
Һәр көн саен диярлек безнең өйләргә: «Хәерле кич! Исәнмесез!» – дип килеп керүче Венера үзенең тормышындагы бик күп нәрсәне язмыш бүләге – бәхет дип саный. Без бүген аны бәхетле итүче шушы БӘХЕТЛӘР хакында да сөйләшәбез.**

Гөлнур
САФИУЛЛИНА



Беренче бәхет

– «Нәүрүз гүзәле» Иванова фамилияле була алмый», – дигәннәр... Жюри шундый нәтиҗә чыгарган. Моны миңа соңыннан әйттеләр. Югыйсә районда да, зона бәйгесендә дә җиңеп чыккан идем. Хәтерем бик калды ул чакта. Авылда фамилиямә игътибар иткән кеше юк иде бездә...

Арсентий бабасы Иванов фамилияле була аның. Венера аны яхшы хәтерли: озын буйлы, баһадир гәүдәле, зәңгәр күзле... Укымышлы! Гомер буе Сарман һәм Минзәлә районнарында мәктәп директоры булып эшләгән, ялга чыккач, умарталар тоткан. Зур хәсрәтләр кичерсә дә, йөзеннән елмаю китмәгән Хәдичә әбисе балаларына татар исемнәре кушкан, аларны мөселман итеп тәрбияләгән. (Телевидениедә эшли башлагач, Венера Рамил кызына: «Бәлки эфирга Иванова булып чыкмассың, псевдоним алырсың?» – дип әйтеп карыйлар. Шунда кинәт кенә унынчы сыйныфта укыган чагы, «Нәүрүз гүзәле» бәйгесендә катнашуы искә төшә... «Юк, үзгәртмим!» – ди ул кырт кисеп.)

Үзенә зур йогынты ясаган кешеләрнең берсе дип, әнисенең әтисен – Фәйзи бабасын саный Венера. Бер авылда яшәгәч, аларга ешрак күрешергә, күбрәк аралашырга насыйп була. Брежнев шәһәрендә үсәсе Венера Зәй районы Бигеш авылы кызы булып китә шул. Әти-әнисенең беренче баласы ул. Кызчыкларының авырып китүе аларны шуңа да зур хафага сала. «Авыллар әнә ком ашап үсә, авырмый», – ди, тәмам гаҗиз булган әнисе табибка. «Анда яшәсәгез, сезнең балагыз да чирнең ни икәнен белмәс иде», – дип җавап бирә табиб. Шул сүз җитә! Ике айдан фатир алачакларын да оныталар, менә дигән эшләрен дә калдыралар – «малосемейка»дагы бүлмәне күршеләргә бүләк итәләр дә, көне белән авылга кайтып урнашалар. Югары белемле ике икътисадчыга эш, әлбәттә, анда да табыла. «Шәһәрдә яшәп калсак, мин, мөгаен, башка төрле булыр идем, – ди Венера. – Авыл кешесе табигатькә генә түгел, хакыйкатькә дә якынрак кебек тоела миңа». Өч ягыннан өч шәһәргә – Зәй, Түбән Кама, Чаллыга терәлеп утырган Бигешне гадәти авыл дию авыррак инде, әлбәттә. Әмма Венера үскәндә кала утлары авыл өстенә болай ук якын төшми торган була әле. Фәйзи бабасы белән Нурия әбисенең унбер оныгы алар – каникулда барысы да Бигешкә җыела. Ул җәйләр ничек күңелле узмасын?! Үзеннән бер яшькә генә кечерәк сеңлесе Айгөл белән әти-әнисенең иркәсе булып үсә Венера. Ә кызларның икенчесе дә инде мәктәп тәмамлаган елны әнисе аларга бик кадерле энекәш – Радикны алып кайта.

– Әниләр Казанга күченгәч, ике әбием дә алар белән килде. Аларның бездәге бүлмәләре авыл өен хәтерләтә. Хәдичә әбием күптән түгел вафат булды. 92 яшендә иде... Ә Нурия әбием бүген дә өебезнең нуры! Мин якыннарымның кайсысына охшаган икән? Мөгаен, барысыннан да аз-аз гына нидер алганмындыр. Фәйзи бабам туры сүзле иде, ике төрле сөйләшә белмәде, шул ук вакытта юмор хисле иде. Әнием дә шундый... Әмма мин сүземне азрак сабыр итеп әйтергә өйрәндем.



Фото: Ксения Богданова

Холкым исә – әтиемнән. Аның кебек мин дә эчтән генә борчылам – тышка чыгармыйм. Күңелдә уйнаган бураннарны күпләр кайчак күрми дә кала. «Венераның һәрвакыт барысы да әйбәт аның», – дип уйлыйлар...

Әти-әни, әби-бабайлар, туганнар – Венераның бәхете!

Тапшыру әйбәт килеп чыккан икән, бу – команданың уңышы.

Икенче бәхет

– Туры эфир алдыннан килгән кунаклар белән сөйләшеп торам. Уңайсызрак бастым, ахрысы, кинәт сизәм – туфли үкчәм сынды! Ул арада режиссер тапшыру башланырга калган вакытны саный башлады: «Утыз секунд, егерме, ун...» Нишләргә?! Әйтсәм – килгән кешеләр дә минем белән бергә дулкынланачак. 26 минут буе бер аякта диярлек басып тордым – бу хакта барысы да тапшыру тәмамлангач кына белде... Әйе, төрле хәлләр булырга мөмкин. Көн саен туры эфирда эшләүне Мәскәүдәге коллегалар юкка гына «молотилка» дип атамый.

2004 елдан бирле телевидениедә – балалар һәм яшьләр редакциясендә эшләп (без аны «Яшьләр тукталышы», «Яшьләр on-line» тапшырулары буенча таныйбыз), шактый тәҗрибә туплаган Венера «Таяну ноктасы» кебек җитди тапшыруны алып барырга әзер була инде. Әмма ток-шоу – башка формат. Эфирга чыгып, әзер текстны уку гына түгел ул, алып баручыдан бик күп сыйфатларга ия булуны таләп итә: югалып калмауны, киң эрудицияле булуны, тапкырлыкны, кайчакта – кискенлекне... Студиядә атмосфера тудыра белүне! («Татар телевидениесенә кайчак ихласлык җитми кебек

PRESSA.RU



миңа... Ул менталитетыбыз белән бәйледер. Бездә бит: «Авызың тулы кан булса да, кеше алдында төкермә», диләр, «Кеше ни әйтер?» дип уйлыйлар. Шуңа да эфирда кайчакта чын түгел, ә ясалма тормыш килеп чыга... Бала төшертүләр турындагы тапшыруда һәркем үз тормышын сөйләп китте шулай. Ачылдылар! Боз эрегән кебек булды ул... Бәлки кемдер: «Артык туарылып ташладым», – дип, соңыннан үкенгәндер, әмма мин күрергә теләгән тапшырулар – шундый ихлас алар. Чирен яшергән – үлгән, дигән гыйбарәне онытырга ярамый».)

«Булмый» дигән кешеләр белән аралашсам, мине мүк сарган кебек була.

Көн саен – яңа тема һәм син анда судагы балык кебек йөзәргә тиешсең. («Темаларның һәрберсе үзенчә катлаулы. Узган ел, мәсәлән, тел темасы бик кискен торды. Дөреслеккә хилафлык та китермәскә кирәк, профессияңнең чикләреннән дә чыкмаска, кешеләрне артык хискә дә бирелдермәскә... Тапшыруда катнашучылар сөйләгәннәр аларга зыян салмаска тиешлеген дә онытмаска. Басым ясамаска, үз фикеремне такмаска (ул хакыйкать була алмый!). Минем максат – теманы күтәрү, резонанс тудыру, чишү юлларын санап чыгу – тамашачыга уйланырга җирлек калдыру».)

Татар телевидениесенең төп проблемасы – татарча әйбәт сөйләүче кешеләр табу – аларга да кагыла. Әмма «Таяну ноктасы»на бу гына җитми – аларга проблеманы курыкмыйча сөйләүче, фикерле кешеләр кирәк! («Кайберәүләрнең тирәнлегенә шаккатам! Ә кемнәрнедер үзем өчен яңадан ачам. Төрле хәлләр була. Кайберәүләр текстны алдан язып, ятлап килә. Аны шул тексттан «чыгара» алсаң, ул әйбәт кенә сөйли башлый. Һәркем белән алдан контакт булдырырга тырышам, бигрәк тә студиягә беренче килүчеләр белән. Тик иң авыры – «киләм» дип вәгъдә иткән кешенең «югалуы», телефонын алмавы».)

Тапшыруның дилбегәсе – алып баручы кулында. Вакыт чикле: кирәк дип тапкан урында сөйләүчене туктату – аңа бирелгән вазыйфаларның берсе. («Беренче тапкыр эфирда Миңгол абый Галиевны туктаткач, миңа: «Син кем соң әле аны бүлдерергә?» – дип хат яздылар... Кешене сүзен бүлеп туктату – минем өчен гел стресс. Безнең бит тәрбия дә шундый: өлкәннәр сөйләшкәндә бүлдермә, кысылма дип өйрәтәләр. Әйе, эфирда мин кырыс, каты күренәм, әмма тормышта күпкә йомшаграк».)

«Таяну ноктасы» кебек тапшыруны алып бару – ул әле социаль җаваплылык та. Венераны кайда гына күрсәләр дә, бер белмәгән кешеләрнең аның янына килеп, проблемаларын сөйли башлаулары хәзер гадәти күренеш. («Бер генә мисал. Яман шеш белән авыручылар турында тапшыру әзерләгән идек. Өмет уята торган итәргә тырыштык аны. Никадәр мөрәҗәгать итүче булды шуннан соң?! Ышаналар, димәк. Барысына да ярдәм итәсе килә дә бит...»)

– Кайчаннан бирле туры эфирда эшлим, әмма барыбер дулкынланам... Бу хакта бер тапшыруга килгәч, Салават абый белән дә сөйләштек. «Дулкынлану миндә дә бар әле, – диде. – Ул булганда гына уңышка ирешергә өмет бар». Эчке халәтеңне сиздермәс өчен үз өстеңдә эшләргә дә эшләргә кирәк, димәк...

Үз өстендә эшләүдән Венераның туктаганы юк: Познер, Долецкая кебек автор-алып баручылардан алып, чит илдәге коллегаларының инглиз телендәге интервьюларын бик күп карый, чагыштыра, үрнәк итеп ала, үз эшендә куллана. Магистратура тәмамлаган, диссертациясенең темасы да бүгенге төп эшенә бәйле. Яраткан эше – Венераның бәхете!

Өченче бәхет

Венераның исемен җыйсаң, узган елның көзеннән бирле интернет иң беренче чиратта «Венера Иванова кияүгә чыкты» дигән мәгълүматны бирә. Бөтен татар дөньясына билгеле аклы Аитовлар нәселенә килен булып төште ул.

– Аллаһы Тәгалә бөтен нәрсәне кичектерермен, әмма никахны кичектермәм, дигән бит. Безнең татарда: «Вакытында кияүгә чыгарга кирәк, югыйсә утырып каласың», – дип әйтү бар. Чит ил журналларын укыйм: гаиләле булып та, үзен ялгыз тойган кешеләр кайда да күп хәзер. Балалары да бар. Ә мәхәббәт киткән... Ашыгып тормыш корганга, ди белгечләр. Чиләгенә күрә капкачы табыла: сиңа дигән кеше, һичшиксез, сиңа була. Кая китсен инде – ул да бит сине эзли... Динар белән гел бер юлларда йөреп торганбыз. Уртак дусларыбыз булган. Бер-беребезне көтеп җиткездек – очраштык менә... Мин хәзер аның фамилиясен йөртәм. Әнием бер генә җөмлә әйтте: «Яраткач, Нәбиуллинаны Ивановага да алыштырдым әле...»



ЯЗМАГА КЕРМӘГӘН ЮЛЛАР

■ Әгәр инстаграмың тормышыңа караганда кызыграк була башлый икән, шәхес буларак югаласың. Чама булырга тиеш. Минем өчен ул тормышның бер өлеше генә һәм иң яхшысы түгел.

■ Минем өчен ничек йоклап китү мөһим: борчулы уйлар, начар кәеф белән иртәрәк ятып йоклаганчы, канәгать булып, соңрак ятуны дөресрәк дип саныйм.

■ Мәктәптә укыганда Айгөл белән икебезне әти Зәйгә – каратэ түгәрәгенә йөртте. Аннары айкидо белән шөгыльләндем – кызыл билбавым да бар *(көлә)*. Аның фәлсәфәсе ошый миңа. Айкидо – үзең һөҗүм итү түгел, сиңа һөҗүм итүченең көчен кире үзенә җибәрү генә ул.

■ «Син җиңел генә җыенып, тиз генә берәр илгә чыгып китә аласың», – дип аптырыйлар. Бу җиңеллек узса, яшьлек китә дип уйлыйм... Ашыгып чыгып киткән кебек тоелсам да, барысы да бөтен нечкәлекләренә кадәр планлаштырылган була. Һәр илдә эшлисе килгән биш әйберне язам башта. Дус кызым белән Венага барып кайттык менә. (Кечкенә багаж белән билетларыбыз нибары 1200 сумга төште!) Барысына да өлгердек: Бельведерда булдык, Густав Климтның атаклы «Үбешү»ен күрдек, Вена операсын тыңладык...

■ Сәяхәтләр миңа илһам бирә. Бер урында озак утыра башласам, калыплашам кебек тоела. Очкычка утырып очып китәсең дә, бөтен нәрсәгә өстән карыйсың: проблема кебек тоелган мәшәкатьләргә, көндәлек ыгы-зыгыга... Шушы хис – кайчак тормышка азрак өскә менеп карау – күп кешегә җитми кебек.

■ Тел белү дигәннән. Бервакыт шулай тапшыруда бер сүзне оныттым. Испанча хәтерлим, инглизчә, русча, ә татарча – юк! Баштагы компьютер буталды... Татарча начар белгәнгә түгел бу – башка телләрне тагын да камилләштерү кирәк дигән сүз генә.

■ Казан мәдәният һәм сәнгать университетында мин алган белгечлек «социаль-мәдәни өлкәдә икътисадны идарә итү. Чит телне тирәнтен өйрәнү белән» дип атала иде. Хәзер аны берничә белгечлеккә бүделәр. Ә без ни генә өйрәнмәдек: сәнгать, кино тарихы (тарихлар, гомумән, 8-9 иде!), инглиз теле, режиссура... «Болар, берберсенә бәйле булмаган нәрсәләр, миңа нигә кирәк?» – дип уйлый идем кайчакта. Һәркайсының кирәге чыкты! Әйтик, режиссер буларак, «Аулак өй» тапшыруында эшләдем (аны идеядән чынбарлык иттек!), «Студентлар язы», «Созвездие-Йолдызлык», хәтта Бөтенроссия студентлар язы гала-концерты видеоверсиясен төшердем. Безнең тормышта бүген булган һәр вакыйга, нигә икәне хәзер аңлашылмаса да, дулкын сине үзе алып барган кебек кенә тоелса да, бервакыт бер җепкә барыбер тезеләчәк. Мин моңа күптән ышандым.

■ Бервакыт әбинең апасы чирләде – кан басымы күтәрелде. Кызы җанын бирергә әзер булып басып тора, тик бернәрсә эшли алмый. Мин укол кадагач, Фәйрүзә апаның хәле җиңеләйде... Чарасызлык, ярдәм итә алмау – иң куркынычы, табиб булам дип уйладым. Хирург! Химия, биологияне тырышып укыдым. Әмма сукмаклар башка юлга алып кереп китте менә... Яхшы хирург була алыр идем – кирәк чакта үземне кулга ала беләм мин.

Мин пешерергә һәрвакыт ярата идем. Әмма кемдер өчен әзерләү бөтенләй башка икән... Җирдә үз парыңны табу – бәхет ул...

Дүртенчесе

Михаил Лабковский, Уильям Пол Янг, Карлос Кастанеда, Сергей Довлатов, Элизабет Гильберт, Айн Рэнд, Курбан Саид, Нурихан Фәттах, Клара Булатова, Равил Фәйзуллин, Эльмира Җәлилова... Бер язучыдан икенчесенә, өченчесенә күчәбез – укыган китаплары хакында Венера бертуктамый сөйли ала!

– Китаплар мине үзләре эзләп таба, – ди ул. – Психология белән бәйле китаплар белән 19 яшьтә үк кызыксына башладым. Мин беркайчан да бер авторның гына карашын укымыйм. Анысыныкын да белергә кирәк миңа, монысыныкын да. Бу китаплар миңа үз өстемдә эшләргә, үз-үзем белән дуслашырга ярдәм итә.

Китапларга, укуга мәхәббәт уятканы өчен укытучым Мәдинә апага рәхмәтлемен. Яңа кеше белән танышканда, аның ул китапны да, монысын да укымаганын белсәм, югалып калам, ә мин аның белән нәрсә хакында сөйләшермен соң, дип уйлыйм. Дусларыма китап бүләк итәргә яратам. Аны озак итеп сайлыйм, китап аша кеше күңеленә дә ачкыч табам кебек тоела... Өстәлеңдә укырга яңа китап булу – бәхет ул...

...«Сәләт», «Алтын каләм», дуслар, сәяхәтләр, ул күргән илләр, уйнаган рольләр («Тузган тoрактан күчкәндә», «Ак чәчәкләр» белән генә тәмамланмаячак, киләчәктә, һичшиксез, тагын булачак әле алар!), Мәскәүнең Кремль сарае кебек мәһабәт биналарда узган концерт-тамашаларны, Татарстанда барган халыкара һәм республика күләмендәге чараларны алып бару, остазлар киңәшләре... Болар барысы да Венераны бәхетле итә! «Ул бүген яши!» – диләр дуслары аның хакында. Бүгенге заманда күбебезгә җитми бу сыйфат...

PRESSA.RU














Фото: http://kremlin.ru, http://mdms.tatarstan.ru, Газинур Хафизов

ИСЕМНӘРЕН ДӨНЬЯ БЕЛӘ!



Ландыш ӘБҮДӘРОВА

Көньяк Кореяда узган XXIII кышкы Олимпия уеннарын бары тик шушы сүзләр белән генә бәялисе килә. Россия спортчыларының әләмсез чыгыш ясавы русның «яу кырында үзең генә яугир түгел» дигән мәкаленең киресен раслады. Яугир! Олимпия атлеты осталык белән чыдамлыкны һәм, иң мөһиме, киеренке вакытта үз-үзеңне кулга ала белүне аңлата. 9-25 февраль көннәрендә әйтерсең лә бөтен дөнья уеннарны зур бер стадионнан күзәтте. Нервлар киеренке, дәрт ташып тора, йөрәк җилкенә. Спортчылар үзләре дә, җанатарлар да, тренерлар да, спорт чиновниклары да туктаусыз сөйләште бу көннәрдә: «Без бирешмәдек!» – «Безнекеләр булдырды!»

Татарстан спортчылары: чаңгычы Андрей Ларьков – бер көмеш, бер бронза, тимераякта фигуралы шуучы Евгения Тарасова – көмеш, чаңгычы Анна Нечаевская бронза медаль яулап алып кайтты. Россия командасыннан беренче булып алтын медаль яулаган 15 яшьлек Алинә Заһитова белән аеруча горурланды без! Сөйләшүләр чыннан да күп булды.

«Татарстан спортында яңа сәхифә ачылды», – диделәр беравыздан Татарстанның спорт чиновниклары. Моңа кадәр спортчыларының Татарстанга берьюлы дүрт Олимпиада медале алып кайтканнары юк иде әле.

Хатын-кызлар хоккеенда да татар кызлары бар иде. Хоккей буенча Россия хатын-кызлар җыелма командасында берьюлы өч татар кызы уйнады. Актаныштан Лиана Ганеева, Кукмарадан Фәнүзә Кадыйрова, Мәскәүдә туып-үскән Диана Канаева. Хоккей ярышларында кызлар бронза медаль яулый алмасалар да, дүртенче урын – яхшы күрсәткеч! Моңарчы Россия кызларының Олимпия уеннарында мондый уңышка ирешә алганнары юк иде әле. Тарихта беренче мәртәбә Олимпия уеннарының ярымфиналына чыктылар.

Боз кузгалды

Спортның иң нәзакәтле төре – фигуралы шуу буенча хисләр киеренкелегеннән боз ялкынланып янды дияргә дә була. Команда чыгышларына берьюлы 10 балл китерүе белән үк Алинә Заһитова алтынга өмет уятты. Һәм безнең барыбызны да сөендереп, хатын-кызлар арасындагы шәхси беренчелектә дә алтын медаль яулады! Ул бозда чын балет күрсәтте!

Алинә Ижевскида үсеп, Әлмәттә спортка аяк басып, Мәскәүдә яшәсә дә, бөтен дөнья буйлап сибелеп яшәүче татар халкы өчен Алинә – безнеке!

– Әйе, – диде кыз үзе дә, – мин Татарстанның да, татар халкының да теләктәшлек белдереп торуын тойдым. Рәхмәт!

Ул арада Заһитованы Татарстанга кайтару турында сөйләшүләр бара икән, дигән имеш-мимеш таралды.

– Мин дә ишеттем бу сүзләрне, – дип елмайды Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министры Владимир Леонов, бу турыда сорагач. – Ләкин мондый сөйләшүләрнең булганы юк. Әгәр дә Заһитовлар гаиләсе Татарстанга кайтырга теләк белдерә икән, рәхим итсеннәр!

Кызыл принцесса фигуралы шуу спортын яңа биеклеккә күтәрүе белән дә тарихта калачак – монысы бәхәссез.

Кызганычка каршы, Алинәгә дә, әти-әниләренә дә Дөнья чемпионатына кадәр журналистлар белән аралашу тыелган булган. Бары тик Япониядән килгән коллегаларыбыз гына аның турында сюжет әзерләгәннәр. Шул сюжеттан соң Алинә белән әбисе Нәдиләнең Мәскәүдә кысан гына фатирда яшәүләре билгеле булды. Бүген аның Инстаграмындагы сәхифәсен 370 меңнән артык кеше күзәтеп бара. Алинәне Япониядә бик яраткаңнар. Дөнья чемпионатыннан соң махсус аңа багышланган аниме эшләнәчәк, имеш. Ә инде кызның акитаину токымлы эт турында хыяллануын да белгәч, Алинәгә Япониядәге шушы токымнарны саклаучы ассоциациядән бүләк эт юлга чыкты.

– Ярты юлда туктап калырга җыенмыйм, – дип белдерде көчле рухлы Алинәбез, фигуралы шуу спортында тагын да үрләр яуларга ниятләвен әйтеп. Алдагысын күз күрер.

Ул арада Казан шушында туып, шушында үскән кызын – Евгения Тарасованы каршы алды. Аэропортка Евгениянең тренерлары, дуслары гына түгел, ә Казанның фигуралы шуу спортына аяк баскан бәләкәй бала-

PRESSA.RU

лары да килгән иде. Ул Владимир Морозов белән парлап шуды. Олимпиадада Евгения – Татарстан өчен, Владимир Мәскәү өчен чыгыш ясады.

Евгения – Казанның Дәрвишләр бистәсеннән. Кечкенә дә төш кенә үзе. Әнисе Татьяна Александровна кызлары Женя белән Валерияне ялгызы гына үстергән.

– Женя кечкенәдән фигуралы шууга мөкиббән иде. Телевизордан күрсәткәндә, аерып алып булмый иде. Фигуралы шуу белән шөгыльләнсен, дип, иң беренче әбиләре әйтте, – ди Татьяна Александровна. «Ракета» стадионында шөгыльләнгәндә, кызчыкны аның беренче тренеры Геннадий Тарасов күреп ала һәм үзенә чакыра. Аннан соң Казанда Женяны Вячеслав Головлев, Татьяна Александрова әзерлиләр.

– Хис-кичерешләребезне ничек кирәк алай тыярга тырыштык. Гомумән, чыгышлар алдыннан сөйләшмәдек диярлек, – ди Женяның әнисе.

– Үзе түзем, үзе эшчән. «Женя, ял итеп ал», – дисең аңа, ә ул һаман бозда, – дип искә төшерә Тарасованың Казан чорындагы тренировкаларын алып барган Головлев.

– Үзебезнең программага чыгар алдыннан боз өстендә ниләр булып ятканын белмәдек. Ул вакытта без әзерләнә идек. Көндәшләребезнең никадәр балл җыюы белән дә кызыксынмадык, – дип искә төшерә Женя Пхёнчхандагы чыгышын.

– Пьедесталда илебез гимнын ишетмәгәч, авыр булды, ләкин ватандашларның безгә көч биреп торуы булышты, – дип, рәхмәтләрен белдерә Владимир Морозов.

– Женя Казанның яшь спортчыларына өмет бүләк итте. Хәзер фигуралы шуу спортының Казан мәктәбе турында да горурланып сөйләргә була, – ди Казан Фигуралы шуу спорты федерациясе җитәкчесе Элина Быстрицкая.

«Бездә спортның бу төре өчен дә инфраструктура бар»

Вологда өлкәсенең Теплый Ручей бистәсеннән килгән Анна Нечаевская – Олимпиаданың төп кәләше, ә чаңгычыларның тренеры – Елена Вяльбе чын мәгънәсендә чаңгычыларның анасы булып танылды. Анна Мәскәүгә кайтып төшүгә, аэропортта ук яраткан кешесе аңа кияүгә чыгарга тәкъдим ясады. Ә Елена Вяльбеның «балаларына» трибуналардан көч биреп торуын телевидение операторлары бөтен дөньяга күрсәтә белде.

Аннаның Олимпиадага кадәрге стартлары алай ук өметләндерерлек түгел иде. Нәкъ менә Вяльбеның дөрес уйланылган стратегиясе чаңгы эстафетасындагы бронза медаль язмышын хәл итте.

Стартка чыгар алдыннан Нечаевская тренерына: «Бәлки кирәкмидер, мине пычак астына ташлыйсызмыни?» – дип карышып карый.

– Шул вакытта миңа күрсәтелгән ышаныч хәл итте дә инде. Хәзер үземнең мөмкинлекләремнең зуррак булуын аңладым, – ди Анна.

– Тренерларга зур рәхмәт, алай гына да түгел, безнең медальләрдә сервисның да өлеше зур. Чаңгыларның югары сыйфатлы булуы, безне карап торган табибларның югары квалификациясе – болар барысы да безнең нәтиҗәләргә уңай йогынты ясады, – дип белдерә Яшел Үзән егете, полиция кече лейтенанты Андрей Ларьков.

Татарстанда спорт үсеше өчен инфраструктура бар, без аны алга таба да үстерәчәкбез һәм алга таба да Олимпиада медальләре өчен тырышачакбыз, – дип хуплый аны Татарстанның Яшьләр эшләре һәм спорт министры Владимир Леонов.

Хәтерлисезме, Андрейны җанатарлар Татарстан әләме, «Казан», «Яшел Үзән» дип язылган әләмнәр белән алкышлады. Марафонда җиңүчеләрне тәбрикләү тантанасы Олимпиаданың ябылу тантанасы кысаларында узды. Дмитрий Губерниев Ларьковның Татарстан спортчысы булуын берничә тапкыр әйтте. Горурланып утырдык! Казан аэропортында ничек каршыладылар үзен! Җанатарларының исәбе-хисабы юк... Ә Яшел Үзәндә инде салют аттырып көтәләр иде Андрейны!

Билгеле булганча, Олимпия уеннарыннан соң ук, кагыйдә буларак, Паралимпиада башлана. Безнекеләргә монда да әләмсез һәм гимнсыз чыгыш ясарга туры килде. Ә гимн сигез тапкыр яңгырый ала иде: безнең паралимпия атлетлары анда шуның кадәр алтын, ун көмеш, алты бронза яулап, икенче урынга чыкты!

Ул көннәрдә Татарстанның Түбән Кама кызы Марта Зәйнуллина ватандашларын көн саен диярлек сөендереп торды. Ул биатлон ярышында – көмеш, чаңгы спринты, чаңгы ярышында ике бронза медаль яулады.

Марта кечкенәдән дзюдо белән шөгыльләнгән. Ләкин 15 яшендә аңа гомерендәге иң зур сынауны узарга туры килә. Сөяк рагы булып, аяксыз кала... Әмма спортны калдырмый. Бүген ул – Россиянең спорт мастеры.

Марта Пхёнчханда булганда, аны Казанда 2 яшь тә дүрт айлык кызы Айла көтеп калган. «Эшкә» дип киткән әнисен телевизорда күреп, әнисеннән Олимпия уеннары символы булган йомшак уенчык аю алып кайтуын сораган. «Аю безгә кирәк!» – дигән ул әнисенә.

– Җиңүләр дә, җиңелүләр дә артта хәзер, өйдә безне илһамландыручылар көтә! – ди Марта.

Казан Кремлендә Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов Пхёнчханнан медальләр белән кайткан Олимпия уеннары чемпионнары белән очрашты. «Республика спортчыларының теләсә кайсы җиңүе дә ил өчен бик мөһим. Сез булдырдыгыз. Без сезнең белән горурланабыз!» – диде ул.

...Әйе, без гоурланабыз. Алар – көчле ихтыяр үрнәге. Алар – безнең өмет, киләчәк җиңүләргә ышаныч! Пекин Олимпиадасы медальләренә юл алардан башлана...

ӘТИСЕ БАЛАНЫ ЯРАТМЫЙ

«Ирем белән аерылыштык. 7 яшьлек улыбыз минем белән калды. Баштарак әтисе көн саен шалтырата, атна ахырында килеп йөри, улымны киного, сәүдә үзәгенә, кафега, паркларга алып бара, төрле бүләкләр бирә иде. Бала безнең аерылышуны сизмәде дә диярлек. Ләкин тора-бара әтисе балага карата суынды. Атналар буе шалтыратмый башлады. Очрашу билгеләп тә, берничә тапкыр килми калды. Соңыннан, эшләрем килеп чыкты, дип акланды. Улым баштарак көн дә әтисен сорап аптырата, аңа шалтыратырга куша иде. Ә хәзер үз эченә йомылды, әтисенең суынуын үзе дә сизде кебек. Шулай да кайвакыт: «Хәзер әтием мине яратмыймыни?» – дип сорап куйгалый. Менә шундый чакта эсселе-суыклы булып китәм, нәрсә дип җавап бирергә белмим, сүзне икенчегә борырга тырышам. «Балам, әтиең мине яратмый башлагач, сине яратуы да сүрелде», – дип әйтиммени? Элеккеге иремнең ике тамчы судай үзенә охшаган улын яратмый башлавын аңлый алмыйм...»

Ләйсән.
Казан шәһәре.

Альбина ШИҺАПОВА, 25 яшь:

– Мин ир-атлар ике төргә бүленә дип саныйм: җаваплылар һәм иреккә омтылучылар. Җаваплылары үз өстенә бурыч, вазыйфалар алудан курыкмыйча, аларны үтәп яшәсә, икенчеләре исә җаваплылыктан кача, иректә яшәргә тели. Андыйларында үз-үзләрен ярату көчле инде. Үзләрен генә кайгыртып яшиләр. Ирнең кайсы төргә караганлыгы балага мөнәсәбәтендә күренә дә инде. Үзен генә яратучы ир баласына да тиешле тәрбияне бирми, баласын үстерү, тәрбияләү, ярату аның эчке вазыйфасына керми. Кемдер ярату хисен күрсәтә белми. Ә кемдер ул хисне бөтенләй тоймый. Андыйларны таш бәгырьле, диләр. Балага карата сүрелүнең сәбәбе дә шундадыр дип уйлыйм. Бәлки, хатыны белән аерылышканнан соң, ир-атта ниндидер үпкә, хәтта нәфрәт хисе уянгандыр һәм ул хисләр балага да күчкәндер...

Әхтәм МӨХӘММӘТҖАНОВ, 67 яшь:

– Ир-атның табигате шундый инде: безгә чынлап торып ярату бирелмәгән. Ярату турында сүз киткәч, бер мисал китерим әле. Пәйгамбәребез Мөхәммәд с. г. в-гә сәхабәләре сорау белән мөрәҗәгать итәләр. «Рәсүлебез, бу фани дөньяда безнең өчен иң якын, иң изге кеше кем булыр – шуны аңлат әле», – диләр. «Анагыз», – дип җавап бирә Рәсүлебез. «Аңардан соң кем?» – дип сорыйлар сәхабәләр. Тагын: «Анагыз», – дигән җавап алалар. Өченче тапкырында да Рәсүлебез: «Анагыз», – дип җавап бирә. Дүртенче тапкырында гына: «Атагыз», – дип әйтә. Димәк, адәм баласының ярату хисләрен бер түгәрәк итеп алсак, шуның дүрттән бер өлеше генә атаны ярату булып чыга. Баласының менә шул 25 процент ятатуын да тулысынча файдалана алмаган ир-атлар шактый. Моның сәбәпләре төрле. Беренчедән, аерылышкач, хатын-кыз ирне санламый башлый, баласы каршында аның дәрәҗәсен төшереп, хурларга тотына, ирнең мин-минлелеген җиргә салып таптый, горурлыгын юкка чыгара. Шуңа күрә ирдә хатынга карата нәфрәт, ачу барлыкка килә, һәм ул хис балаларга да күчә. Чөнки ир аларның барысын да бер яссылыкта күрә башлый. Икенчедән, күп хатыннар, аерылышкач, баланың фамилиясен алыштыра – атасыныкын сызып ташлап, үзенекен яздыра. Бу күп кенә ирләрнең җен ачуларын чыгара. Хатынга булган ачу янә балага төшә.

Өч фикер



Ләлә БӘҺРАМШИНА, психолог

– Гадәттә, мондый хәл ир белән хатын начар итеп аерылышканда күзәтелә. Хатыны белән низагта булган ир тора-бара баласын да тормышыннан һәм күңеленнән кысрыклап чыгара башлый. Шундый гыйбарә яши бит: ирнең үзенең балалары юк, аның яраткан хатыны табып биргән балалары гына бар. Хатыны аша ир-ат үзен ир буларак, ә баласы аша ата буларак күрсәтә. Ир белән хатын аерылышса да, балага барыбер ата да, ана да кирәк. Күп очракта барысы да хатын-кызның зирәклегенә, уйлап эш итә белүенә кайтып кала. Зирәк хатын-кыз ата белән бала арасындагы җылы мөнәсәбәтне саклап калу өчен тырыша. Бала алдында әтисен (элекке ирен) хурламый, мин аны хөрмәт итәм, дип кабатлый, балада әтисе белән горурлану хисе формалаштыра. Баланың ике канаты бар: берсе – әти, икенчесе – әни. Ике канаты булган бала гына оча, биеклекләргә күтәрелә ала. Ә гаиләдә ата начар итеп күрсәтелсә, бала бер генә канатлы булып, шулай булуына үзе дә кимсенеп үсә. Ата бала тәрбиясендә катнашмый икән, аны бетереп ташларга ярамый. Ир-ат җәмгыятьтә эш күрсәтә, төрле үрләр яулый торгандыр, шуларны балага сөйләргә, күрсәтә белергә кирәк. Ирен яманлап, хатын-кыз иренә түгел, балага зыян сала, аның канатын сындыра. Бала белән утырып сөйләшү дә бик мөһим. Ул тыңлауга, аңлауга мохтаҗ. Ананың аңлавы, яратуы атаның юклыгын капларга ярдәм итәчәк, бала тынычланачак. «Хәзергә әтиеңнең эшләре күп, ә эше беткәч, ул синең янга киләчәк, ул сине ярата», – дип кабатлап тору да хатын-кызның зирәклеген күрсәтә.

Шул ук вакытта хатын-кыз әти кеше (элекке ир) ягын да җайларга тырышырга тиеш. Үзе турында гаиләдә ничек итеп сөйләүләрен ир кеше белеп торсын, үзенә хөрмәт булганын сизсен. Хатын-кызга элекке иренә: «Балаңны да карамыйсың, юньсез», – дип, көн саен ачуланып шалтыратырга түгел, ә бәлки: «Балаң сине сагынды. Балаңның синең белән сөйләшәсе килә. Балаңның сиңа әйтер сүзе бар», – дип мөрәҗәгать итәргә һәм моны ир-атның күңеленә үтеп керерлек итеп эшләргә кирәк.

PRESSA.RU











КҮҢЕЛ КЫҢГЫРАУЛАРЫ

Мәдинә
АВЗАЛОВА

КАРГА ДА ОЧМЫЙ ТОРГАН, «БЕТКӘН», ДИП КУЛ СЕЛТӘГӘН АВЫЛЛАРГА БҮГЕН ЯҢА СУЛЫШ КЕРДЕ.

Зөһрә Рөстәм кызы Гарифуллина исемен тәүге мәртәбә Балтач районында уздырылган «Ел хатын-кызы» республика бәйгесендә ишеттем. Җирлек башлыгының бетә барган кечкенә авылларны, җирлекне ничек итеп таркалудан саклап калу турындагы чыгышы ул чагында безне хәйран иткән иде. Бик теләгәндә, нинди генә катлаулы проблеманы да уңышлы хәл итәргә мөмкин, дигән сүз иде бу. Ә бернигадәр вакыттан соң, Биектау районының Алан-Бәксәр авылына баргач, миңа аның үзе белән танышырга да насыйп булды. Ул яшәгән йортка аяк басуга, беренче күзгә ташланган әйбер – җыйнак-матур итеп эшләнгән камин өстенә тезелгән кыңгыраулар булды. Арада ниндиләре генә юк: җизе дә, кулыңа алсаң, нәфис чыңы йөрәкләргә үтеп керердәй бәллүре дә...

– Кыңгырауның чиләк кадәрлесе сарайда әле, – ди, бу тамашага ис китеп карап торуыбызны күргән хуҗабикә. – Җыям мин аларны. Һәркайсының – үз моңы, үз авазы. Кая барсам, шуннан алып кайтам. Дусларым да бүләк итә.

Әңгәмәбезне аның җирлек башлыгы булуын күздә тотып башламакчы идек тә, көтелмәгәнчәрәк килеп чыга. Ул безнең сорау биргәнне көтеп тормый. Үзе сөйли: күңелендә еллар буена җыелып килгәнен, борчыганын, тормышындагы иң кадерле, иң бәхетле минутларын өстәлендә яткан дистәләгән фоторәсемнәрдә мәңгеләштерелгән мизгелләр аша тасвирлый.

«Яраттым, яратам...»

Аны инде туктатып булмый.

– Без ирем Марсель белән 1986 елның җәендә таныштык, – ди ул, истәлекләренә бирелеп. – Минем Зур Битаман урта мәктәбен тәмамлап, Казан авыл хуҗалыгы институтының икътисад факультетына кабул ителгән чагым. Шулай бер көнне абыем Зөфәр белән Дөбъязда Казанга йөрүче иртәнге автобусны көтәбез. Абыем, тукталышта торган егетләргә күрсәтеп: «Әнә теге егетләр дә сельхозда укый», – диде. Мин шул тарафка карадым да сызылып киткән кара мыеклы егетне күреп алдым. «Күреп алдым» диюе генә җиңел. Ул мизгелдәге халәтемне белсәгез?! Искә төшердемме, ничә еллар узган булса да, тәнемне сихри дулкын биләп ала. Бер күрүдә гашыйк булуның шушы икәнлеген соңыннан аңладым. Мин аны яраттым һәм хәзер дә... яратам.

Марсельнең армия сафларыннан кайтып, Авыл хуҗалыгы институтының механика факультетына имтихан биреп йөргән вакыты була. Шуннан танышып китәләр. Томырылып торган зур зәңгәр күзле, чибәр һәм тыйнак кыз егеткә дә ошагандыр. Студент еллары, атаклы кешеләр белән төрле очрашулар, кызыклы кичәләр... Шул рәвешле өч ел вакыт узганын сизми дә калалар. Матур җәй иртәсендә бөреләнгән мәхәббәт дүртенче курска җиткәндә кавышуга китерә. Диплом алгач, алар әле өч ел Казан шәһәрендә яши. Зөһрә бер-бер артлы ике кыз бала таба. Өйдә бәләкәчләрне карый. Ә Марсель Питрәч районына йөреп эшли башлый. «Икебез дә авыл хуҗалыгы белгече булгангамы, шәһәргә күңел ятмады, авылга кайтасы килде». Зөһрә шулай ди. Бәлкем шуңадыр да, 1994 ел башында Биектау районы «Новая жизнь» күмәк хуҗалыгына эшкә чакыргач, алар ике дә уйламый Алан-Бәксәргә юл тота.

Менә хәзер шул авылның, инде март башы булса да, чак кына да яз исе килмәгән карлы урамнары буйлап йөргәндә, табигать уянгач, Ашыт елгасы җәйрәп ага башлагач, елганың икенче ярына тоташкан иксез-чиксез урманнарында җиләк өлгергәч, иркен болыннарына чыгып, кыр чәчәкләре җыярлык булгач кайтмаганыбызга мең кат үкендек. Бигрәк матур икән бит бу яклар!

Авылга кайткач...

– Яшь белгечләр буларак, колхозга кайтуга эшкә чумдык, – ди Зөһрә Гарифуллина. – Ирем баш инженер булып эшли башлады. Хуҗалыкта кышкы техника ремонтлау чоры, запас частьлар табасы, кадрлар мәсьәләсен хәл итәсе... Кыштан соң язы җитә. Кыр эшләре башлана: чәчү, бәрәңге утырту дисеңме, бераз сулу алуга, печән өсте җитә, сенаж-силос салу чоры. Мин – баш хисапчы. Укыганда алган белемнәр эшкә җигелде. Шулай да тәҗрибә җитмәү үзен нык сиздерде. Ярый әле хезмәттәшләрем әйбәт булды. Алар булышты.

Ул чагында балалар кечкенә, ә янда әби-бабайлар юк. Күңелле мәшәкатьләр белән ел арты ел үтә тора. Кызлары Диана белән Диләрә мәктәпкә китә.

– Шул чорда без өченче бәби алып кайтырга ниятләдек, – дип сөйли Зөһрә ханым. – Дөресрәге, Марселем бик тә малай теләде. Тик Ходайның әмере шулай булгандыр инде, өченчегә дә кыз туды. Гәрчә бик тә малай көтсәк тә, әтисе Диләфрүзне аерата яратты, өченче кыз – «әти кызы» булып үсте. Әтиебезгә малай бүләк итәргә тагын бер талпынып карадым. Нәтиҗәсе: 40 яшемә җиткәндә тагын бер кыз – төпчегебез Динәне алып кайттым.

Ә бит барысы да уенычыны белән әйтелгән бер сүздән башланган иде.

Авыл хатыннары өчен үрнәк була ул. Ике балалы хатыннар өченчегә уза. Зөһрәдән күреп, күрше хатыны да 43 яшендә бала таба. Авылда хәзер күп балалы гаиләләр саны унбергә җитә. «Дүрт егетебез бүген армия сафларында хезмәт итә», – дип мактанып та куя җирлек башлыгы. 140 хуҗалыклы авыл өчен унбер гаилә, чыннан да, күп инде ул.

Көндәлек мәшәкатьләр белән балалар үсеп җиткәнен дә сизми калган алар. Гарифуллиннарның олы кызлары югары белем алып, берсе – «Таттрансгаз»да кадрлар бүлегендә, икенчесе укытучы булып эшли. Өченче кызлары Казандагы Спорт һәм туризм академиясендә белем ала. Төпчеге авылда – әнисе янында, өченче сыйныфта укый.

– Әтиләре генә юк, – ди Зөһрә ханым, моннан ярты ел чамасы элек булган хәлләргә кайтып. – Кичтән

PRESSA.RU



Гарифуллиннар гаиләсе тулы чакта төшкән соңгы фото. (Марсельнең вафатына – нәкъ бер атна.)

барысы да әйбәт кебек иде. Кем уйлаган иртәгәсен безгә зур кайгы килачәген... Кәнәфигә утырган да... йоклап кына киткән шикелле. Ул бер мәртәбә инсульт кичергән иде инде. Бусында инфаркт, диделәр. Һич уйламаганда, кинәт китеп барды. Без – ятим... – Ул бермәл дәшми тора да: – Сагынам, керфек очларына кадәр сагынам... Сәгать саен, минут саен истә, – дип куя.

Бәләкәй авылларда да зур эшләр башкарырга була. Җирлек башлыгы моны үз үрнәгендә раслап тора.

Инвестор ярдәмендә

Читләргә җан ачысын күрсәтергә, сыгылып-йомшарып төшкәнен сиздерергә яратмый ул. Кайгы кагып киткәннән соң вакыты да әле бик аз үткән. Ә шулай да Зөһрә ханым бирешми. Әнә ул янә үткәннәргә кайтып, хатирәләргә бирелә. 2010 елның октябрь аенда аны Алан-Бәксәр авыл җирлеге башлыгы итеп куялар. Җирлек биләмәләренә Алан-Бәксәр, Алат спирт заводы, Гәр, Әсән, Шөмлән дип аталган биш авыл керә. Дөресен әйткәндә, юлы да булмаган, газы-суы да кереп җитмәгән бәләкәй-бәләкәй авыллар. Җиң сызганып, зур планнар белән эшкә керешә ул. Бирелә эшләү чорында тиз арада авыл кешесенең иң якын киңәшчесенә, дустына әверелә.

– 2011 елда оптимизация – җирлекләрне берләштерү, кушу башланды, – ди ул, авыллар гына түгел, медицина тармагы өчен гаять каталаулы чорларны искә алып. – Аның җиле безгә дә килеп кагылды. «Кеше саны 600 гә дә тулмый, авылыгызда ни ферма, ни бүтән эш урыны юк», – дип, безнең җирлекне дә бетерергә булдылар. Инде аның яңа картасы да әзер иде. Кушылырга дип, җыелыш җыя башладылар. Ә минем ятсам-торсам башымда гел бер уй: ничек итеп саклап калырга? Шул вакытта ел да үткәрелә торган Әсән авылы көне бәйрәменә кунак булып Казандагы зур бер оешманың генераль директоры Айрат Сабиров кайтты. Ул үзе тамырлары белән күрше Олы Битаман авылыннан. Бәйрәмгә район башлыгы да килгән иде, «Авылны күтәрергә, фермалар төзергә кирәк», – дип сөйләде. «Әйдә, гаилә фермасы төзеп җибәр, йорт сал, авыл кешесе булып китәрсең», – дим кунагыбызга. Ә ул уйлап торды-торды да, әкрен генә әйтеп салмасынмы: «Ә нигә салмаска?» Уйланып йөргәндер инде, күрәсең, бер-ике көннән килде аннары. «Йорт салырга җир бир. Калганын карарбыз», – ди. Карга да очмый торган як иде Әсәнебез. Бер җәй эчендә ханнар сарае шикелле өен дә салып куйды. Юлларны да тәртипкә китерде.

Аннан алар икәүләп район башлыгы янына китәләр. 100 баш мөгезле эре терлек өчен комплекс салырга дип керәләр. Нәтиҗәдә, комплексны 480 башка төзибез дип чыгалар. «Бер генә шартым бар, – ди Айрат Сабиров район җитәкчесенә, – җирлекне таркатмыйсыз, беркая да кушмыйсыз». Шулай итеп, җирлекне саклап калалар. Алан-Бәксәр авылында 100 дә түгел, 480 дә түгел, ә 700 баш мөгезле эре терлеккә исәпләнгән «Әсән» ширкәте эшли башлый. Хәзер аннан көн саен 10 тоннага якын сөт китә! Авыл кешесенә пайга бирелгән җирләр дә элек кулланылмый яткан. Ул җирләргә битаманлылар кереп чәчкән чаклар да булгалаган. Бүген инвестор пайга бирелгән җирләрне үз кулында тота. Шуның өчен халыкка гектарыннан 700 сумнан кипкән, чүпсез, чипчиста бодай бирелә.

– Элек бөтен кеше Казанга чыгып китә иде. Хәзер яшьләр авылда калу ягын карый, – ди Зөһрә Гарифуллина. – Чөнки аларга биредә эш бар. Яшәү шартлары дә хәзер шәһәрнекеннән бер дә калышмый. Өйләргә газы-суы кергән, юлларны да гел чистартып кына торалар.

«Йөрәктән – йөрәккә»

Җирлек башлыгы турында: «Талантлы, иҗади шәхес», – диләр. Авыл халкы өчен нинди генә бәйрәмнәр уйлап тапмый ул. «Ак калфак» иҗтимагый оешмасының район советы әгъзасы, «Мәрхәмәт» хатын-кыз депутатлар берләшмәсенең районлагы вәкиле, Россиянең Авыл хатын-кызлары комитеты әгъзасы буларак, аңа төрле чараларда катнашырга, алай гына да түгел, башлап йөрергә туры килә.

– Бер шулай мәктәп директоры белән районда үткәрелгән «Йөрәктән – йөрәккә» марафоныннан кайтып килләбез, – ди шул хакта сүз чыккач җирлек башлыгы. – Әйдә, марафонны үзебездә үткәрик, дим. Ә безнең җирлектә барысы алты инвалид бала бар. Җиденчесе – гемо-

диализга бәйле булган бер ир-ат. Район буенча бүлә башласаң, безнекеләргә эләкми дә әле ул акча. Шулай эшләдек тә. Мәктәп директоры программа төзеде. Аннан халыкка игълан иттек. Кыска гына арада инвалид балаларга 67 мең сум акча җыеп тараттык.

...Өстәл тулы төрле оешмалардан, министрлыклардан, профсоюзлардан килгән Мактау кәгазьләре, Рәхмәт хатлары, Дипломнар... Аларны санап бетерерлек түгел. Арада «Муниципаль идарә өлкәсендә иң яхшы хезмәткәр» дигәне дә, «Нечкәбил» бәйгесеннән алган Диплом да, «Ныклы гаилә» республика бәйгесендә җиңеп чыгуы турында таныкнамә дә бар.

Китешли әле күптән түгел генә салынган мәчетне, булачак часовняның (кәшәнәнең) урынын карап йөрдек. Әйе, булгач-булгач, ул ике милләт халкы өчен дә булсын инде. Җирлек башлыгына мәсьәләнең бу ягын да тигез кайгыртырга кирәк. Дус-тату булып, бер гаилә булып яшәү өчен кирәк. Авылның өр-яңадан төзекләндерелгән Изгеләр чишмәсенә дә төшеп мендек. Күңел кыңгыраулары аны һаман алга, игелекле эшләргә дәшеп тора. Планнары зурдан аның... Әле менә сугышта һәлак булган якташларына һәйкәл куйдырасы, музей оештырасы, шәп кенә бер Мәдәният йорты салып куясы бар. «Авылда кеше саны аз, диләр дә, акча бүлеп бирергә ашыкмыйлар», – дип көрсенә җитәкче. Ветераннар советы рәисе Наил Кәлимуллин белән берлектә, алар инде күптән музейга экспонатлар җыюны башлап җибәргәннәр. Кыңгыраулар җыюдан тыш, тагын бер яраткан шөгыле – хоббие бар: ул профессиональ дәрәҗәдәге фотограф. Тормышының һәр мизгелен мәңгеләштерергә, соңыннан фоторәсемнәрне кайта-кайта карарга, исенә төшереп, хатирәләргә бирелергә ярата ул. Ә тагын... үзенең фотокүргәзмәсен оештыру турында хыяллана. Кыскасы, гел хәрәкәттә булырга тырыша, авылдашлары өчен һичьюгы матур итеп эшләнгән бер эскәмия генә куйдырса да, чиксез бәхетле ул. Ярата ул авылын, үзе әйтмешли, ятса-торса, авыл бит аның уенда!

«КҮКЕ ТҮГЕЛ МИН»

Быелның гыйнвар санында «Җимерек. Яшәргә яраксыз» дигән язма басылып чыкканнан соң, безгә Булатның әтисе Фәрит Миннәхмәтов шалтыратты. Баксаң, ул беркая да китмәгән. Редакциягә килеп, булган хәлләргә карата үз фикерен белдерүдән дә баш тартмады. Язманы сезгә, хөрмәтле укучылар, ул ничек сөйләгән, шулай тәкъдим итәбез:

– Безнең Рәйханә белән танышу да, өйләнешү дә тиз булды. Мин аңа бер күрүдә гашыйк булдым. Минем ул чакта Үзбәкстаннан кайтып, Чаллыда эшләп йөргән чагым. Әни, авырып, хастаханәгә эләкте. Хәлен белергә килгәч, аны күрдем. Ошаттым. Рәйханәнең апасы Кадрия дә: «Танышыгыз, сез бер-берегезгә туры киләсез», – дип тора. Йөреп киттек тә, ул хастаханәдән чыккач, өенә бардым. Әти-әнисе белән таныштым. Аларны да бик ошаттым. Әйбәт, эчкерсез кешеләр. Шулай итеп, ике ай дигәндә, Рәйханәнең бармагына балдак кидердем. Өйләнешеп, әйбәт кенә яши башладык. Ул минем укыган кеше. Шуңа үзен гел туганнарына бурычлы саный, аларны тыңлый, аларның сүзләреннән чыкмый торган иде. Бигрәк тә Кадрия апасының сүзеннән. Васыйл улыбыз 1988 елда туды. Шунысын әйтим, ул чагында торырга өебез булмагач, Рәйханәнең әти-әнисе безне шундук үз йортларына яздырды. Ләкин без алар янында яшәмәдек. Үз җаебызны үзебез карадык. Күктәк-Мирсәет авылында элеккеге кибет корылмасын сатып алып, шунда яши башладык. Ә ата-анасы янына кайтып йөрдек.

Ике арага тыгылу бик яман нәрсә икән ул. Миңа каршы әйтә торгач, апасы максатына иреште. Безне аерды. Ул чагында хатынга да рәхәт булгандыр димим. Ул да күп михнәтләр күрде. Кешене яман сүз үтерә, диләр. Шулай икән. Еллар узган саен, мин моңа яхшырак төшенә барам. Югыйсә аның хәерсез, хәтәр җилләре бүген дә мине таламас, йөрәгемне әрнетмәс иде. Апасы Кадрия ничек кенә безне бергә яшәтмәскә теләсә дә, берникадәр вакыттан соң, янә кушылдык. Рәйханә икенче балага авырга узды. Вакыты җитеп, балага авырта башлагач, аны ашыгыч ярдәм машинасы белән Теләнче Тамак хастаханәсенә алып киттеләр. Без улым Васыйл белән көн аралаш Рәйханә янына барып, хәлен белешеп йөрдек. Соңгы мәртәбә килгәндә: «Иртәгә чыгам», – диде. Килеп алырга да сөйләшкән идем. Иртәгәсен туганы миңа: «Кадрия Рәйханә белән баланы өенә алып кайта», – дигән хәбәрне җиткерде. Мин шул ук көнне апасының өенә бардым. Хатын: «Сөтем юк», – дигәч, сөт алып кайттым. Алар янында бер кич кундым. Ике-өч көннән Рәйханәне кабат Тукай районы хастаханәсенә алып киттеләр. Бала апасында калды. Кадрия миңа: «Син Рәйханә белән Васыйлны кара, ә мин Булатны карармын», – диде. Операциядән соң хатын реанимациядән чыкмады. Бер генә көнгә аңына килеп алды да, мәңгелеккә күзләрен йомды. Без аны Күктәк-Мирсәеткә алып кайтып җирләдек. Шул арада Кадрия баланы үз тәрбиясенә алу чарасына керешкән. Мин баланы үземә алу артыннан йөри башладым. Бер елдан соң, Татарстан Югары Суды Булатны миңа бирү турында карар чыгарды. Кадрия апалар өенә суд приставлары белән кат-кат бардык. Өйдә чагын туры китерә алмадык. Ул бездән качып йөрде. Әгәр дә шул чагында туктамаган булсам, тарткалашу бүгенге көнгәчә барыр иде.

Васыйлны язгы каникулда Чаллыга алып киттем. Бабай йортында аңа урын калмады. Гомумән, аның ничек яшәве, нiләр белән шөгыльләнүе туганнарын кызыксындырмады. Кадрия сүтелергә тиешле кибетне ялган документлар ярдәмендә йортка әйләндергән. Булатны шунда яздырган. Имеш, аның милке – шул. Шуңа да ул бала бүгенге көнгәчә фатирсыз. Судтан судка йөреп, булмаслыгын аңлагач, туктадым. «Бала 7 яшькә җиткәнчегә кадәр опека һәм иганәчелек бүлегеннән бернинди ярдәм күрмәдем. «Акчаны әтисе алып барды», – дигән сүзе дә ялган. Ничек бирсеннәр миңа ул акчаны?! Бала бит миндә түгел иде.

Кадрия гел Рәйханәнең авырлы чагында алып барган көндәлеген селкеп йөри. Имеш, мин Рәйханәне кыйнаганмын, авырлы чагында да кул күтәргәнмен. Йөкле хатынның психикасы үзгәрә бит ул. Күңелендә ни булганын хәтта мин дә белә алмадым ул чакларда. Нәтиҗәдә, менә хәзер, дистәләгән еллар узганнан соң, залим ир булып калдым. Инде килеп, ул: «Баладан ваз кичтең, алимент түләмәдең», – дип, җанымны ашый. Әйе, ул Булатымны: «Синең исемдә түгел», – дип, кулымнан тартып алды. Әтисе исән килеш, бала атасы белән очрашмас булды. «Нигә очрашмадың?» – диярсез. Ул мине: «Әгәр дә Булат янына килсәң, төрмәгә утыртам», – дип янады. Һәм утырта да иде. Шөкер, Булатым мине аңлады. Без аның белән аралашып торабыз. Мин ата күке түгел, балаларымны яратам. Алар – минеке!

Фәрит МИННӘХМӘТОВ

PRESSA.RU



Фото: www.pixabay

МИННӘН СИҢА – «ЮК!»

«ЮК» – ДӨНЬЯДАГЫ ИҢ КЫСКА СҮЗ. ТЕЛӘСӘ КАЙСЫ ТЕЛДӘ БУ СҮЗ БЕР ЯКИ ИКЕ ИҖЕКТӘН АРТМЫЙ.

Ә шулай да ул иң авыр әйтелә торганнардан. Бигрәк тә үзең яхшы белгән кешеләргә «юк» дип әйтү җиңел түгел. Ничек итеп үзеңнең вакытыңа, матди хәлеңә, ниһаять, шәхси тирәлегеңә хилафлык китермичә генә яшәргә? Ничек итеп үз вакытында «юк» дип әйтергә һәм үзеңне гаепле итеп тоймаска?

Мин – «юк» дип әйтә белмәүче, үтенечне кире каккан хәлдә, үземне гаепле итеп сизүчеләрдән. Шушы урында мин психологлар армиясенең беравыздан: «Сез балачакта яратуга тиенмәгәнсез. Аң төпкелендә «мин яратуга лаек түгел» дигән ышану яши, шуңа да даими рәвештә үзегезнең лаеклы булуыгызны раслап тору кирәк. Бу – үз-үзеңә түбән бәя. Үтенечне кире каксам, ул кешене үпкәләтермен, мине яратмаслар, дип куркасыз», – дигән сүзләрен ишетәм. Алга таба психолог болай ди:

– Үзегезне шул кеше урынына куеп карагыз. Сезнең нәкъ шундый үтенечне кире кактылар, ди. Үзегез үпкәләячәксезме? Яратмый башлаячаксызмы?

Мин:

– Юк, юк, билгеле, үпкәләмәвемне белдереп, рәхмәт тә яудырам әле...

Шуннан психолог баштан сыйпап чыгарып җибәрә. Ә ишекнең теге ягында тормыш чынбарлыгы. Анда һәр вазгыятьне белгеч белән сүтеп-җыеп утыру мөмкин түгел, тиз арада карарлар кабул итәргә кирәк. Тиз арада эшләргә дә кирәк. Ахыр чиктә, кеше миңа үтенеч белән мөрәҗәгать иткән икән, димәк, мин аны башкара алам, һәрхәлдә, кулымнан килгәнчә нәрсәдер эшләп караячакмын! Ә балачагымда... ничек ярата белсәр, шулай яратканнар инде.

«Юк» дип әйткәндә, үзеңне гаепле итеп сизгән, «әйе» дигәндә үкенү хисе белән бимазалаган очракларны психологлар болайрак шәрехли:

1. Туганнарыгыз/дусларыгыз сездән һәрвакыт ярдәм/акча сорый. Сез мөнәсәбәтләрне бозмас өчен, әдәп саклап, баш тартмыйсыз. Әлбәттә, төрле хәлләр була, ярдәм итәргә кирәк! Әмма кеше үзе акча эшли ала һәм эшләми, әрсезләнә икән, бу очракта сезнең «юк» дип әйтүегез аңа карата зуррак ярдәм булачак. Андый кешенең ихтирамын югалтудан да куркасы юк: ул бурычын кайтармавы, паразитларча

кылануы белән сезне ихтирам итмәвен күрсәтте. Шул ук вакытта сез шәхсән кешене түгел, ә аның үтенечен кире кагасыз бит. Ә болар – икесе ике нәрсә.

2. Яраткан кешегез бик еш кына сезгә үзе өчен нәрсәдер эшләргә куша. Балаларыгыз сездән көн саен нәрсәдер сатып алуыгызны сорый. Алар сезне акча янчыгы итеп кенә күрә, һәм «мәхәббәтегезне» һәрдаим яңа әйбер сатып алу аша раслап торуны таләп итә икән... Монда чын ярату турында да сөйләп булмый бит әле. Дилер белән клиент мөнәсәбәтләренә күбрәк туры килә. Билгеле, бүләк алмаска дигән сүз түгел бу. Чын күңелдән ясалган бүләк белән үпкә-шелтәләрдән котылу өчен алынган бүләк арасындагы аерманы гына тоемларга кирәк.

3. Эштә хезмәттәшләрегез ярдәм сорый. Җитәкче эштән соң калып эшләргә куша. Җитәкче яки хезмәткәрләрнең өстәмә эш кушуына ризалык белдерү белән коллективта ихтирам яулау мөмкинме икән? Яки күбрәк акча эшләү? Һәрхәлдә, күбрәк акча эшләү мөмкинлеген Хезмәт кодексы хәл итә. Моны җитәкче дә, хезмәткәр дә белергә тиеш. Ләкин еш кына җитәкче белмәмешкә салыша, хезмәткәр әйтергә кыймый. Ихтирамны исә... үз вакытында «юк» дип әйтү белән яулау ихтималы зуррак.

Элгәре заманнарны әйтмим, хәзерге эгоистик заманда үзара ярдәмләшеп, аралашып яшәү гарип альтруизм булып санала. Заманы – шул, дип кенә әйтә алам бу турыда. Чөнки...

...хәтерлисезме, элек, йомышы төшеп, шәһәргә килеп чыккан авылдашны үзеңә сыендыру олы хөрмәт санала иде? Колхоз автобусына төялеп килгән авылдашлар да фәлән абыйның ерак туганнарында кунып чыга. Тулай торактан бүлмә биргәнче, авылдан килгән энекәште җизниләрдә яшәп тора. Аның каруы, күпме күңелле хатирәләр һәм якты йөз калган ул көннәрдән, ә теге җизнине, авылга кунакка кайткач, күтәреп кенә йөртмиләр... Ә шунда ишек төбенә килеп баскан авылдашың кыңгырау төймәсенә басканда, ишек ачмасаң? Яисә бертуган апаң улын сиңа ышанып тапшырганда, сыйдырмасаң? Ул вакытта «кеше ни әйтер», «авылдашлар күзенә ни йөз белән күренермен», дигән курку яши иде. Мондый мөнәсәбәтләр ул вакыттагы җәмгыятьнең язылмаган кануны иде, социологлар теле белән әйткәндә, социаль контроль дип атала.

Хәзер менә алай түгел. Казанга килгән кеше якын туганында гаеп итми-нитми генә кунып чыга ала әле, ә менә Мәскәүдә бу әрсезлек булып санала. Чит илдә исә, әйтик АКШта, чәй эчеп чыгу да мөмкин түгел. Болай кабул ителмәгән. Шулай ук бурычка акча сорап тору да килешми. Хәтта «Хәлләр ничек?» дигән соруга да елмаеп кына җавап бирәсе. Чит илләрдәгечә яшәү кануннары безнең милли яшәеш фәлсәфәсен кысрыклый бара.

Алсу (32 яшь):

– Кемнеңдер үтенечен җиңел генә, үземне гаепле итеп хис итмичә генә кире кага алам. Кемгәдер «юк» дип әйтү авыр бирелә. Кешесенә карап. «Юк» дип әйтә алмаган кешеләрем – үземнән көчлерәк кешеләр.

Ләйсән (25 яшь):

– Мин «юк» дигәнне кабул итә алмый торган кеше. Шул ук вакытта үзем бик җиңел генә «юк» дип әйтә алам. Хәтта энемнең: «Ападан сорап торасы да юк, ул барыбер бармак та селкетми», – дип әйткәне бар.

Эльвира (29 яшь):

– Бу турыда уйлаганым да юк. Уйларга кирәкмени? Булдыра алсаң, кешене борып җибәрмисең инде. Акча сорап торсалармы? Үзем дә сорамыйм. Сорарга туры килеп, бирмәсәләр, үпкәләмим дә.

Равилә (45 яшь):

– Шәфкать туташы булып эшлим, шуңа да үтенеч белән килүчеләр күп була. Баштарак бик теләп булыша идем, ләкин күпкә китә башлагач, кайберәүләргә канәгатьсезлек белдерергә туры килә.

Ландыш ӘБҮДӘРОВА



Маргарита ФӘТХУЛЛИНА, психолог

Шәхси пространство... Хәзер бу турыда шундый күп сөйлиләр.

Нинди була ул? Аны үзеңә һәм якыннарыңа уңайлы итеп ничек оештырырга? Сиңа үтенеч белән мөрәҗәгать итүчеләрне үпкәләтмәслек итеп, чикләрне ничек сакларга?

Берәрсенә ярдәм итүдән баш тартып, соңыннан үзеңне гаепле итеп сизгән халәт күпләргә таныштыр, мөгаен. Аның очы кайларга барып ялгана икән? Ачыклык кертеп карыйк әле.

Психологиядә 3 яшьлек бала кризисы дигән төшенчә бар – бу яшьтә балалар ахырын уйлап тормыйлар, «юк» дип кырт кисәләр. Шуннан аларны тәрбияли башлыйлар, тора-бара бала үзенең теләге иң мөһиме түгел икәнен аңлый. Теләмәсәң дә, дәрес әзерләргә кирәк, югыйсә «икеле» алачаксың, сине ачуланачаклар. Теләмәсәң дә, әни пешергәнне ашарга кирәк...

Гаеп хисеннән тыш, эгоист дип уйларлар, яратмаслар, киләчәктә сиңа да ярдәм итмәсләр дип куркабыз. Үтенеч белән килгән кешегә «юк» дип әйтә алмагансың икән, син ихтыярсыз булып тоелырга, ә аның үтенечен үтәү мәҗбүри кабул ителергә мөмкин. Гадәттә, «отличник» синдромлы кешеләр «юк» дип әйтә алмый, аларга һәрвакыт әйбәт булып калырга кирәк. Андыйларны башкалар рәхәтләнеп файдалана.

«Юк» дип әйтә алмауның тагын бер сәбәбе – синнән башка эшли алмаслар дигән уй. Мәсәлән, хуҗалыкта булышу, балалар карашу, эштә ярдәм итү... Сез булмаганда эшли алалар бит!

Нишләргә соң? Җавап гади: «юк» дигән сүзне үз-үзеңә ихтирамың да югалмаслык, башкалар алдында да итагатьле булып калырлык итеп әйтергә кирәк!

Үтенеч белән килгән кешегә җавап бирер алдыннан түбәндәгеләрне истә тотыгыз:

- Кемгә дә булса ярдәм итүең үзеңә зыянга булмасын.
- Үтенечне канәгатьләндерә алмыйсың икән, вәгъдә бирмә. Уйлыйм әле, соңрак җавап бирермен дип әйтергә була.
- Булыша алмасаң, әхлакый яктан теләктәшлек белдерергә тырыш. Еш кына киңәш кирәгрәк тә булып чыга.

Әгәр инде кеше теләсә кайсы үтенечкә «юк» дип җавап кайтара икән, ул яки ялкау, яки эгоист. Ә монысы инде бөтенләй башка тема...

PRESSA.RU



БЕЗНЕҢ МАРАТ АБЫЙ

ӘЙЕ, УЛ БЕЗНЕҢ МАРАТ АБЫЙ! Ә КАЙЧАКЛАРДА РЕДАКЦИЯБЕЗ ӨЧЕН – ХӨРМӘТЛЕ МАРАТ ӘМИРХАНОВИЧ!

Язган һәрнәрсәне иң элек аңа укытабыз. Хата-кимчелеге булса, төзәтә, киңәшен бирә. Табыш-уңышыбызга сөенә белә. Кайгы-көенечне, хәтта ки эч серләренә кадәр сөйләп була дип ышанабыз. (Капчыкны төбеннән тотып селкергә ашыкмыйбыз – тыңлый, сер сыя дигәч тә... ир-ат ич ул!) «Сөембикә»не дус-тату, көчле гаилә итеп туплый, редакциядәге каләм иясенең һәркайсына остаз да була белде ул.

Роза КАМАЛЕТДИНОВА

Марат абый белән беренче очрашу әле дә хәтеремдә. Сабакташым – «Азат хатын»ның баш мөхәррире Роза Туфитуллованың журналга эшкә чакыруын, әлбәттә, сөенеп кабул иттем. Егерме елга якын газетада эшләп чарланган, әмма көн туган саен мәкалә-хәбәрләр яза-яза нык кына алҗыган да идем инде. Адашым Роза бу абруйлы басманы күптән түгел генә җитәкләгәнгә, үзе дә редакциядә яңа кеше исәпләнә, урынбасары белән киңәшү зарурлыгын яшермәде. «Әмирханов ни дияр тагын...» Икеләнгән сыман шулай дип куюы мине ирексездән сагаерга мәҗбүр итте: «баш»ны узып үз сүзен үткәрүче «муен» – урынбасары Марат Әмирханов шулай ук кырыс кешеме икән әллә?

Иллеләрне узган олпат гәүдәле җитди урынбасарны күргәч тә эчке киеренкелек, каушау узмаган иде әле. Күзлек астыннан сынап карый торган күзләр... Нинди уй-өметләр белән монда килергә ниятләвем, ниләр язуым хакында фикер алышкач, Роза Рәхмәтулловна: «Яшьләй вафат булган шагыйрь Тәүфикъ Камалиевның тол хатыны ул», – дип тә әйтеп куйды. Шулчак Марат абыйның йөзенә моңсулык йөгерде: «Социалистик Татарстан»да бер бүлектә эшләдек. Намуслы, вөҗданлы шәп егет иде», – диде. Һәм егерме елдан артык бергә, иңне иңгә куеп дигәндәй, эшләү дәверендә «намуслы, вөҗданлы егет»нең хәләл җефетенә – миңа һәрчак ихтирамлы, хөрмәтле булды ул. Зур рәхмәт аңа! Хәер, миңа гынамы, һәркайсыбызга дустанә-хәерхаһ мөнәсәбәте белән сөендерә иде ул.

Ягъкуб Хәлили нигез салган «Азат хатын» ерак тарих инде. Төрле чорда журналист туташ-ханымнарга терәк – җаваплы сәркатип, баш мөхәррир урынбасарлары булып Һади Такташ, Хәсән Сарьян, Аяз Гыйләҗев, Габдулла Шәрәфетдинов кебек абруйлы ир-егетләр эшләп алган. Әмма ни генә әйтсәк тә, «Сөембикә» тарихында Марат абый кебек озак эшләгән ир-ат юк. Егерме-егерме биш кыз-хатын арасында зирәк акыллы, тәртипле-тотнаклы ир-ат кына шулай озак эшли аладыр. Дүрт баш мөхәррир – Венера Ихсанова, Роза Туфитуллова, Фирая Бәдретдинова, Ләйсән Юнысова белән эшләде. Туры сүзле, таләпчән, ә иң мөһиме: чиста күңелле һәм итагатьле булуы хуҗалар илә дә, гади хезмәткәрләр белән дә уртак тел табарга булышкандыр. Бәлки журналистикада легендар шәхес – Шәмси Хамматов мәктәбен үтүе дә эзсез узмагандыр. Педагог һөнәрен сайлап, әүвәл Питрәч районының Күн мәктәбендә чирканчык алуы, аннары Карабаш урта мәктәбендә байтак еллар уку-укыту эшләре мөдире буларак чарлануы чыныктыргандыр. Яраттык без аны. Яраттыра белде ул үзен. Бер юбилее уңаеннан әңгәмә корып утырганда бу хакта үзенә дә әйткәнем булды. Бөтен кеше ярата сезне. Ничек шундый булып була, янәсе. «Сабый бала үзен сөймәгән кешегә якын бармый, борылып та карамый. Ә иҗат дөньясындагы хатын-кыз садә, сабый күңелле, бала кебек бит ул. Чын йөрәктән, үзләрен ихлас яратканымны сизәләр, димәк!» – булды җавап. Кемнедер аерып, артыграк яратканын беркайчан, беркемгә дә сиздермәде, һәммә кешене тигез күрде.

«Алтын йөрәкле ир-ат» исеменә лаек булуы да тикмәгә түгел Марат абыйның. Мондый купшы исемгә дә лаек ул. Бүләк тапшырганда шул чактагы баш мөхәррир Фирая Бәдретдинованың Марат абыйга сыена төшеп, күзләре яшьләнеп: «Әти кебек күрәбез без Сезне, Сез – безгә әти урынына», – дигәне әле дә истә. Хәер, бу гыйбарәне бәйрәм саен берәребезнең кабатлавына берәү дә гаҗәпләнми иде. Кеше күңелен күрү дигән бик матур сүз бар татарда. Ә Марат абый чын татар ул. Бәйрәмнәрдә безне котламый калмый. «Актанышлар белсә-белмәсә җырлый инде», – ди дә бүләген – каплы шоколадын сиңа җырлап тапшыра.

«Парин, янар тау, вулкан өстендә утыруыңны беләсеңме?» – дип, аны ирештерүче Аяз Гыйләҗев кына түгел иде.

Әти кебек дигәннән... Бервакыт сәнгать институтын тәмамлаган сәләтле бер кыз белән сөйләшеп утырганда остазлары хакында сүз чыкты. Бу төркемдә ятимә кызлар берничә иде. «Остаз гына түгел, ятимнәргә әни дә булды бугай ул», – дидем. Әңгәмәдәшем, күңеле әрнүен яшерә алмыйча: «Бәлки кемгәдер әни булгандыр, ә миңа үги әни булды шул!» – дип куйган иде.

Ышанам, Марат абый хакында берәү дә «үги әти иде» дип әйтмәс.

Әмма аны ничек кенә хөрмәт итсәк тә, олы язучы, гаҗәеп каләм иясе белән һәрдаим аралашып, янәшә яшәвебезне без ул чакта аңлап бетермәгәнбез икән.

Марат Әмирханов әдәбиятка соңлабрак килде. Соң булса да, уң булсын, диләрме? Ә бит Марат абыйга бу җәһәттән чынлап та уң килде, бүгенге көндә ул – танылган язучы, дистәләгән бәян, романнар авторы.

Тигез канатлы, матур гаилә корып, тыныч кына яшәп ятканда... Сөеп алган, яратып яшәгән хатыны Җәүһәрия яман шеш дигән хәерсез чиргә дучар була. Операциядән соң табиблар күзәтүе астында булуы хәерле дип, яхшы фатирын, яраткан эшен калдырып, Марат Әмирханов гаиләсен алып Казанга күченә. Әмма... Язмыштан узмыш юк диләрме? Сөекле кызлары – Ләйләгә дә шул зәхмәтнең кара канаты кагыла. Кадерлеләрен югалткач... сердәш булып әдәбият кала. «Тәкъдир» романы шулай туа. Ә бу әсәрне яза башлаганчы әле күп сулар агар...

«Алаяк» дигән беренче хикәясен ул кырык биш яшендә яза. Туган авылы Кәзкәйнең мактанычы – ак бәкәлле чабыш аты үсмер чактан атлар саклаган егет күңелен җилкендерә. Сара апа Садыйкова «Ясәвиен сагынам «Чишмә»нең» дип җыр багышлаган данлыклы колхоз рәисе Ясәви Хөсәенов Мөхәммәт Мәһдиев белән якташы Марат Әмирхановны кунакка чакыра.

Фото: Газинур Хафизов

PRESSA.RU



Марат абыйның «Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» бәйгесендә «Алтын йөрәкле ир-ат» исеменә лаек булган көннәре. 2001 ел.

Ул язарга тиеш иде. Язмый калу, күргән-кичергәнне ак кәгазь битенә төшереп бушанмый хәле юк иде.

Шул очрашу вакытында, әсәрләнеп: «Языгыз әле шул ат турында!» – дип үтенә. Ак бәкәл тарихы Мәһдиевнең бер романында урын ала. Әмирханов хикәя яза. Икесенеке ике төрле чишелеш таба. Мин дә яза алам икән бит, дип җилкенеп, ул бәян язарга тотына. Язып бетергәч, Мәһдиевкә укырга бирә. Үзенә дә, бүтәннәргә дә гаять таләпчән олы талант иясе: «Кырыкны узгач... кая инде ул язучы булу?» – дип, аның хыялына киртә куя. Бәхеткә, Атилла Расих бәян хакында ишетепме, очраклы гынамы, үзе аңа мөрәҗәгать итә. «Кая инде ул... иллегә таба barганда», – диюенә исе китми: «Беләсең килсә, тормыш тәҗрибәсе, язарлык багажы булгач кына прозаик юньле әсәр иҗат итеп укучыны сөендерә», – дип, гүя канат куя. «Дөя муены» дигән сатирик әсәрен Аяз Гыйләҗев күтәреп ала. Алар – гаилә дуслары. Марат абыйның икенче никахтагы хатыны Ләлә ханым да Нәкыя апа кебек укытучы, аралашып яшиләр.

Марат Әмирханов гомер буе иртәнге тугыздан кичке алтыга кадәр казна эшендә эшләп каләм тибрәткән әдип. Ничек өлгерәсез, дигән соравыма: «Язучылык та, шагыйрьлек кебек үк Ходай тарафыннан тәгаенләнгән, кешенең эчке халәтенә салынган бер могҗиза ич. Ягъни Тәкъдир, Язмыш! Шигърият – әдәбиятның әнкәсе, ә проза аның алтын баганасы, диләр. Проза язу өчен зуррак көч, ихтыяр көче кирәк. Әмма иҗат дәрте, язучылык корты күңелеңә бер кереп утырса, вакыт та табыла, акча, ару-талу белән дә исәпләшмисең», – дигән иде.

«Гөлнәзирә», «Мөкәррәмә», «Үрбәт ханикә гыйшкы», «Гәүһәршад», «Ләйлә», «Бибимәмдүдә» – хикәя, бәян, романнарының атамалары ук хатын-кыз исемнәрен кычкырып тора. Кыз-кыркын, туташ-ханымнарның хис-кичерешләрен, хатын-кыз галәмен гаять үзенчәлекле һәм белеп тасвирлавы әдипне яңа баскычка күтәрде. Соңгы елларда дөнья әдәбиятында нәкъ менә хатын-кыз язучылар бу өлкәдә үр арты үр яулый. Бу гаҗәп түгел. Әмма ир-ат әдипләрнең сирәге генә гүзәл җенеснең тойгы-хисләрен зур төгәллек белән, үтемле итеп ача алу сәләтенә ия дип уйлыйм мин. Хикмәт Марат абыйның егерме елга якын укытучы ханымнар белән уратылган мәктәптә, чирек гасыр «Сөембикә»дә эшләвендәме икән әллә?! Хәер... Сугыш башланганда 8 яшьлек малай гаиләдә бердәнбер ир заты булып кала. Әтиләре яудан кайтмый... «Сабый чактан гел кыз-хатын арасында кайнашканмын. Әнкәй, ике әби – әнкәйнең әнисе һәм сеңлесе, үземнең ике сеңел... Әнкәй гомер буе эштән бушамады – унбиш ел колхоз бригадиры йөген тартты. Гел хәрәкәттә, гел чабуда... Көндез ятып торуны ялкаулар гамәле дип саный. Әллә шуңа Ходай аңа озын гомер насыйп итте. 93 яшендә дә акылы камил. Авылдан китми, бөтен эшен үзе эшли, бакча казый, яшелчә үстерә. Әмма миндә әткәй каны, ирләр холкы», – дип сөйләгән иде ул унбиш еллар элек.

Марат абый 85 яшьтә дә егетләргә биргесез әле: армый-талмый роман арты роман яза. Соңгы елларда Тукай иҗаты белән сихерләнде. «Бар күңелләрдән җылы, йомшак синең кабрең ташы» дип язган Тукаебыз. Шөкер, Бибимәмдүдә абыстай рухын яд итеп, үз сүземне әйтә алдым. Зиннәтулла хәзрәт хакында да сөйләр сүзләр бар», – дип шалтырата. Әйе, ул тарих катламнарын барлый, актара. Сөембикә («Әлвидаг» романы), Гәүһәршад, Фатыйма-Солтан образларын илгә-көнгә танытты. Әдипнең Гөлйөземе, Гөлнәзирә, Мөкәррәмәләре исә – сугыш елы авылының михнәтгазабын, бар ачысын татыган, тетрәндерә, уйландыра торган образлар. Адәм балалары хата-ялгышлардан хали түгел. Геройларның холык-фигыле, эш гамәлләре укучыга ошап та бетмәве ихтимал. Әмма тормыш бу. Ә Марат Әмирханов геройлары – тормышның үзеннән. Тормыш үзәненнән!

РЕДАКЦИЯДӘН: Хөрмәтле Марат абый! Сезгә без рәсми рәвештә Марат Әмирханович дип эндәшсәк тә, якын итеп, барыбер Марат абый дип йөртә идек үзегезне. Хәзер дә бергә эшләгән елларны искә төшергәндә, «безнең Марат абый үзе бер кабатланмас шәхес», дип, яратып, сагынып кабатларга яратабыз. Язучы, журналист-публицист, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, журналистларның Хөсәен Ямашев исемендәге премиясе лауреаты дип, мактаулы исемнәрегезне санап китсәк тә, «Сөембикә» журналының алыштыргысыз кадерле кешесе» дигән исемгә лаек булуыгыз холкыгыз, талантыгыз, оештыру осталыгыгыз турында күп нәрсә сөйли. Бәйрәмегез – олы юбилеегыз белән чын күңелдән котлыйбыз! Иҗат сөенечләре, көр кәеф, нык сәламәтлек, күңелле мәшәкатьләр телибез Сезгә!

ИРЛӘР НИГӘ ЭЧӘ?



Илнар хәзрәт ЗИННӘТУЛЛИН, «Туган авылым» мәчете имам-хатыйбы

Эчкән ирен хөрмәт итмәгән өчен хатын-кызны гаепләргә кирәкме?

– Ир белән хатын мөнәсәбәтен бер килешү дип карарга ияләшкәнбез: ир кешегә үз вазыйфасы йөкләнгән, хатын-кызга – үзенеке. Ләкин дин күзлегеннән караганда, алар бу эшләрне бер-берсе өчен түгел, ә Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен башкара. Димәк, аларның вазыйфалары бер-берсенә бәйләнмәгән: ир кеше үз вазыйфасын үтәмәсә, хатын да үзенә йөкләнгәнне үтәмәсә ярый дигән сүз түгел. Һәм киресенчә.

Ирнең эчүе – ул аның хатыны алдында түгел, ә Аллаһы Тәгалә алдындагы гөнаһы. Мондый ир тәкъва, ягъни Аллаһыдан куркучы ир түгел инде. Шуның өчен дә хатын-кыз кияүгә чыкканда иң элек тәкъва ир эзләргә тиеш. Ә без үзебезгә гомер юлдашы (ир, хатын) сайлаганда, чибәр, бай, акыллы булсын дибез. Төп хатабыз – шушында. Әгәр кеше Аллаһыдан курыкмый икән, аны гөнаһ эшләүдән бернәрсә дә тоткарламый.

Эчү, әлбәттә, зур гөнаһ. Ләкин «запой»га китеп эчүнең төрле сәбәпләре бар. Беренчедән, әлбәттә, физик бәйлелек. Элек тәмәке тарткан бер дустым әйтә: «Мин тәмәкене нервым чыкканга тарта идем. Ә нервым тәмәке тартмаган өчен чыга иде», – ди. Монда да шулай. Аракы турында уйлау кешедә йә стресс, йә депрессия китереп чыгара. Ә ул аларны аракы белән баса.

Эчүнең рухи сәбәбе дә бар. Теләсә кайсы эчкече хакыйкатьтән, чынбарлыктан качу өчен эчә. Ир кеше салгалый башлый икән, димәк, аңа нәрсәдер җитми, реаль дөнья ошамый – аның параллель дөньяда яшисе килә. Бәлки ул эшеннән канәгать түгелдер, бәлки гаиләсеннән...

Дөресен генә әйткәндә, хатын-кыз ир-атны җәлләми. Ир кеше өйгә ял итәргә кайта ул. Ишекне ачып керүгә исә хатыны аны исемлек белән көтеп тора: моны эшләргә кирәк, тегене эшләргә... Ул әйбер беткән, монысы беткән... Баланы анда алып барырга кирәк, монда... Җитмәсә, ир бусагадан атлап керергә дә өлгерми, сорау ала башлыйлар: «Кайда булдың? Ник озак тордың?» Аны ашыктыралар, каушаталар, әйткәнемчә, эш өяләр... Кыскасы, ирне өйгә кайтмаслык итәләр. Безнең хатыннарның төп хатасы да шунда.

Ә ир кешегә гап-гади бер әйбер кирәк: ишектән килеп керү белән аңа кагылмасыннар. Көне буе эштә арыган иргә азрак хәл алырга ярты сәгать вакыт җитә – аннары үзе сөйләшә; кирәк икән, хатынына өй эшләрендә ярдәм дә итә башлый ул. Нибары ярты сәгать-бер сәгать вакыт! Ашыйсы килеп кайткан икән – алдына салып куйсыннар. Балалар да аны борчымый торсын...

Өендә үзе теләгән шушы ялны тапмаса, эчәргә сәбәп эзли башлый да инде ул. Кичләрен каядыр керәп утыргалый, анда үзе кебек өендә тынычлык тапмаган кешеләрне очратмый калмый...

Ул исереп кайткан саен, хатыны тавыш чыгарса (ә тавыш чыкмый калмый, әлбәттә!), эчәргә сәбәп тагын табыла... Аңарда өйгә кайтырга теләк уятырга кирәк. Зирәк хатынның моны эшләргә көче җитәчәк.

Ә кайбер хатын-кызга эчкән ир кулай гына. Алар моңа тышкы яктан зарлансалар да, исерек ир белән яшәүне рәхәтрәк күрәләр. Ни өченме? Сәбәбе гади – ир кеше эчкәч, үзенең дәрәҗәсен югалта. Ир дәрәҗәсен югалту белән, гаиләдә беренче урынга хатын-кыз чыга: ул бит эчми, балаларны карый, йорт-җир дә аның өстендә, әле тагын эшләсә, акча да алып кайта... Ир-ат исә көннән-көн түбән тәгәри... Хатынга исә үзен аңардан югары итеп тою ошый, ул моның белән канәгать. Кайвакыт үзе үк иренә эчәргә аракы салып бирергә дә мөмкин. Кычкыра-кычкыра, начар сүзләр әйтә-әйтә булса да. Әмма бит бирә! Эчүен теләмәсә, ул аны бирмәс иде. Мәсьәләнең бу ягын да онытмаска кирәк.

Эчкечегә бу чирдән арынырга ничек ярдәм итеп була соң?

– Гөнаһларны бары тик дин белән генә дәваларга мөмкин. (Ир кешенең хатынына хыянәтен, читкә йөрүен дә, туктатса, дин генә туктата – башка бернәрсә ярдәм итми.) Исәнлегеңне җуясың, үзеңне үзең харап итәсең, диюне ишетми ул. Сәламәтлек хакында уйласа, бер табиб та хәмергә якын килмәс иде (аракының зыянын алардан да күбрәк тагын кем белә?!), үзләре башкаларга тәрбияче булырга тиеш укытучыларның берсе дә эчмәс, тартмас иде. Юк, бу сорауга кеше акыл белән килми. Күңеле, җаны белән килсә генә әлеге афәттән котыла ала ул.

Эчүдән туктый алмаган ир белән аерылышу хатын-кызга гөнаһмы?

– Иренең эчүеннән артык күп зыян күргән очракта (ул аны акча белән тәэмин итми, кул күтәрә) хатын-кызга әти-әнисе янына кайтып китәргә ярый. Иреннән рөхсәт сорап тормыйча да. Һәм бу гөнаһ саналмый. Башка вакытта ул, иреннән сорамыйча, өйдән беркая да чыгып китә алмый. «Әтиләргә барып кайтыйм әле», – дип сорагач, ире: «Юк», – дисә, ул хәтта аларга да бара алмый.

Бу проблеманы икәү генә хәл итә алмаганда, Аллаһы Тәгалә туганнарны чакырырга рөхсәт итә: ир ягыннан – берне, хатын ягыннан – берне. Әлбәттә, ислам динендә бу мәсьәләне хәл итү җиңелрәк: хәмер эчкән ир-ат инде җинаятьче санала – аны 80 тапкыр таяк белән суктыралар. Безнең җирлектә мондый нәрсә юк. Ир кеше эчсә, хатын-кызның куллары бәйле – ул берни эшли алмый. Дөрес, 15 тәүлеккә утыртып куярга мөмкин. Тик, беренчедән, ире төрмәдән айнып кайткач, хатыныннан үч алачак. Әле шуннан да аянычрак бер хәл сөйләделәр. Ире эчеп кайткач, хатыны, полиция чакыртып, аны 15 тәүлеккә озаткан, ә тегесе камерада асылынып үлгән... Юк, бу – мәсьәләне чишү юлы түгел.

PRESSA.RU



Фото: Ксения Богданова

Мин аның яшь чагын күз алдына китерергә тырышам. Район, калалар белән идарә иткән вакытларын. Ул аралашкан кешеләрне: КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретарьлары – Фикрәт Табиев, Рәшит Мусин, Гомәр Усманов, Чаллы шәһәр партия комитетының беренче секретаре Рәис Беляевны...
Һәрберсе Татарстан тарихында тирән эз калдырган шәхесләр. Хәер, ул үзе дә шуларның берсе.
Бүгенге әңгәмәдәшем – ГАБДУЛЛИН Салих Галимҗан улы 1933 елның 10 апрелендә Яңа Чишмә районы Татар Волчья (Акбүре) авылында туган.
Аңа – 85. Аңа әле 85 кенә! (Телефон номерын контактларга теркәүгә, экранга ватсабы да килеп чыкты! Заман белән бергә атлаган кешенең шулай булырга тиеш!) ике «Хезмәт Кызыл Байрагы» ордены, «Хезмәттәге батырлык өчен» медале белән бүләкләнгән. Татарстанның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре. Алабуга һәм Яшел Үзән шәһәрләренең шәрәфле гражданины.

«ТОРМЫШТАН ЯМЬ ТАБАМ»



ТАМЫРЛАР Әти белән әнигә бербирсен эзләргә дә кирәк булмаган – алар күршеләр. Сугышка киткәнче әти механизатор булып эшләде. Башлы кеше иде! Бер пешкәкле двигатель белән тегермән тарттырган. Армиягә алганда аңа 29 яшь була. Мин аның Фин сугышыннан хәрби киемнән кайтканын хәтерлим. Кечкенә идем әле, әмма колхоз идарәсе каршында әти белән басып торганымны беләм. Аннары алар, полуторка машинаның әрҗәсенә төялеп, Бөек Ватан сугышына чыгып киттеләр. Гармуннар уйнап, «йә кайтырбыз, йә кайтмабыз, сау булыгыз, туганнар» дип җырлап... Әтинең кош теледәй бер генә хаты килде. 1941 елның көзендә без инде «похоронка» алдык. Ленинград өлкәсендә, Синявино сазлыкларында ятып калды ул. Әнинең җиргә ятып елаганы бүгенгедәй күз алдында. Искә төшсә, хәзер дә күзләремә яшь тула...

Дүрт бала ятим калдык. Миңа, иң өлкәненә, 8 яшь... Әнием Фәһимә – Залаковларның әтиләре белән бертуган. Мәхмүт абый (без аңа «Зур әзи» дия идек) сугыштан бер кулын өздереп кайтты. Әмма шул килеш тә әнигә безне күтәрешергә бик булышты. Әтинең әтисе Габдулла бабай безнең белән яшәде – әнигә ул да зур терәк булды. Шуңа күрә әни сыер да асрый алды. Абруйлы, төпле кеше иде бабай. Икенче улы сугыштан исән кайтты – аның өлешенә әсирлек газаплары тиде.

Төп йортта бүген сеңлем Шакирә гаиләсе яши. Тормышлары бик матур. Авылыбыз да матур! «Татмелиорация» компаниясенең генераль директоры Әнвәр Мәхмүт улы Залаков Акбүрене төзекләндерүгә шактый өлеш кертте. (Чистай «Сельхозтехника» җитәкчесе, аннан партиянең Чистай шәһәр комитетының икенче секретаре булып эшләгән елларымда туган авылыма мин дә шактый булыштым. Авылда урта мәктәпне шул вакыт төзи башладык.) Ике мәчет эшләп тора. Капка төпләренә кадәр асфальт юл салынган. Әмма, кызганыч, яшьләр барыбер авылдан китә – эш юк. Буш нигезләр гел күбәя бара. Хәер, бу күренеш бездә генә түгел инде.



БАЛАЧАК Балачакның бөтен хатирәләре дә моңсу бугай... Ачлык та, юклык анда...

Безнең әнидә ирләр акылы бар иде. Үткенлеге дә бар. Хатыннар белән ындыр табагында эшлиләр шулай. Кичен өйгә кайтырга җыенсалар, амбар мөдире барысын да тентеп чыга икән – кесәләренә аз гына иген салсалар да, бушаттыра. Әни беркөнне, бәрәңге буразнасында посып ятып, шул хатынның төнлә эштән кайтканын көткән. Көтеп җиткергән. Ә ул, нәкъ әни уйлаганча, аркасына ярты капчык иген күтәргән булган. Каршысына чыккан инде әни. «Фәһимә апа, кешегә генә белгертмә, башка сине тикшермәм!» – ди икән мөдир хатын. «Моннан соң беребезгә дә кагылмыйсың! Югыйсә районга хәбәр итәм!» – дигән әни... Төн уртасында кайтып керде дә: «Балалар, ашагыз!» – дип, идән уртасына мөдирнең ярты капчык игенен куйды. Без йоклый идек, уяндык... Бу турыда авылда беркем белмәде, әни кешегә чыгармады. Чибәр иде безнең әни. Чәче аяк табанына кадәр җитә иде. Мин өйгә килен төшергәндә, әнигә 43 яшь кенә иде әле.

Тагын бер хатирә. Күрше авылда Карточкин дигән комбайнер бар иде – безне шуңа ярдәмче итеп куйдылар. Ашарга юк, өйдән алып барырга да берни юк. Ә алар ирле-хатынлы эшлиләр – әпәйләре бар. Шуннан безгә дә өлеш чыгаралар иде. Бу яхшылыкны ничек онытасың?! Авылга кайткан саен хәлләрен белешергә барам. Хатыны вафат инде, Семен Васильевич әле исән – аңа 90 яшь тула. Кызларында яшәп ята. Шәп кеше! Эшкә безне ул өйрәтте.



УКУ Җиденче классны тәмамлаганда бирелгән таныклыкта гел «бишле» генә иде минем. Яхшы укыган өчен «Мертвые души» дигән китап та бүләк иттеләр әле. Сигезенче класска Лашманга укырга барырга булдым. Бабайның анда бер туганы яши иде – шуларда торырмын дип уйладым. Җәяү, яланаяк чыгып киттем. Кырпак кар төшкән вакыт. Туган тиешле кеше начар каршы алмады үзе, әмма шунда ук: «Улым, ашарга алып килдеңме?» – дип сорады. Ә бу йортта дүрт кыз үсә, мин, әлбәттә, артык кашык буласы идем – бер генә көн укыдым да, кире кайтып киттем. Ул елны колхозда эшләдем. Икенче елны Мәхмүт әзинең улы Габбас белән икәү биш чакрымдагы Яңа Ибрайга – Аксубай районына укырга киттек. Әнинең мине бик тә укытасы килде, үземнең дә теләк зур иде. Безнең белән авылдан дүртбиш малай барган иде Яңа Ибрайга. Әтиләләр, ашарларына бар... Бераздан алар укуны ташлады, без Габбас белән икәү генә калдык.

Яңа Ибрай җидееллык мәктәбендә укыганда Гомәр исемле бер дустымнан гармун уйнарга өйрәндем. (Бу сәләт әтидән килгәндер, ул хәтта үзе скрипка ясаган булган!) Үземнең дә гармунлы буласы килә бит! Әнине урман кисәргә җибәргәннәр иде ул елны. Мин аңа: «Әни, гармун алма келим. Бераз ярдәм итә алмассыңмы?» – дип хат язганмын. Исенә төшергән саен көлеп сөйли иде әни... Гармунчы егетләр ул чакта дәрәҗәле: кызлар янына барып керсәң – урын түрдән. Яңа Ибрайда укыганда, кызларны биетергә шактый йөрдем. Эш бүлмәмдә гармуным, тальяным тора әнә әле дә. Кичләрен уйнап, берәр җыр җырлап куям. Күбрәк «Галиябану»ны сузам инде...

Урта мәктәпне тәмамлагач, Габбас белән Казанга киттек. Документларны Казан авыл хуҗалыгы институтының механика факультетына тапшырдык – анда танышларыбыз укый иде.



МӘХӘББӘТ Мәрзияне беренче тапкыр... алтынчы класста укыганда күрдем. Шунда ук ошаттым! Иң арткы партада утыра иде ул. Сигезенчедә укыганда беренче тапкыр аңа хат яздым. Ул җавап бирмәде...

PRESSA.RU

Институтта укыган чагым. Безнең авылдан Шакир дигән җырчы берсендә мине Зифа Басыйрованың туганнарына кунакка алып китте. Әлмәттән дә кунаклар килгән икән, матур гына кызлары да бар. Мине шул кыз белән таныштырдылар. Алабугада фельдшерлыкка укый бу. Без аралаша башладык. Минем ниятләр шактый җитди, әмма өйләнергә уем юк иде әле.

Казанда Горький исемендәге ял паркының яңа ачылган вакыты. Апрель ахыры иде. Егетләр белән шунда киттек бер көнне. Барып җитүгә үк дус кызы белән Мәрзия очрады. Безнең кебек алар да танцыга килгәннәр. Малайлар койма тактасының каерылган урынын беләләр икән: барыбыз да студентлар бит – һәр тиенебез кадерле, шуннан гына эчкә уздык. Мин ул кичне Мәрзияне биергә чакырдым. Ул каршы килмәде...

Соңыннан Мәрзия миңа болай дип сөйләде: «Шул көнне миңа нидер булды... Сиңа башка күз белән карадым... Һәм дөнья кинәт үзгәрде: бөтен нәрсә яшәрде, яшелләнде, кояш балкый башлады. Тулай торакка кайттым да: «Кызлар, хараплар булдым! Кайчандыр миңа хатлар язган егеткә күзем төште!» – дим. «Аны кабат үзеңә карату сиңа проблема түгел. Җый студентлар вечеры, аны да чакыр, шунда ул синеке булачак», – диде кызлар».

Шул көннәрдә минем бер дус егетем Мәрзия янына: «Мин сине күптән ошатып йөрим, әйдә, өйләнешик тә, бергә торыйк», – дип барган. «Юк, ризалаша алмыйм, башка кешене яратам – Салихны», – дип җавап биргән аңа Мәрзия. «Үзе беләме соң?» – дип сораган теге дустым. «Юк әле», – дигән Мәрзия. Алар мине Мәрзия оештырган вечерга ничек китертергә дип бергә план корганнар.

Бардым. Алай гына да түгел, Мәрзия белән таныштырырга дип, бер дустымны да ияртеп бардым әле. Үзем инде буш түгел бит – йөргән кызым бар... Вечер беткәч, безне чәйгә чакырдылар. Боларның икесен янәшә утыртмакчы булам – дустым яныннан Мәрзиягә урын әзерләп куйдым. Табын әзерләп йөргән Мәрзиям: «Ә мин синең яныңа утырырга җыенып торам әле», – димәсенме?! Шуннан бар да кабынып китте инде яңадан... Йөрмәсәк тә, йөрәктә булган инде ул минем. (Әлеге хатирәләрне искә төшергәндә Мәрзиядән гел: «Шулай әйтә алдыңмы Салих Галимҗановичка?» – дип сорыйлар. «Ул чакта Салих кына иде бит әле ул», – дип көлә.)

Мин өченче курста укыганда без инде өйләнештек: бер-беребезне кабат югалтудан икебез дә курыктык бугай. Әле тагын ике ел укыйсым булса да, әни дә каршы төшмәде. Аның белән утырып киңәшләштек. Мәрзияләрнең нәселләрен беләбез – ул вакытта бу бик мөһим иде әле.

Бала тугач, Мәрзияне авылга, әниләргә кайтарып куйдым. Алтынчы җан булып кайтты ул анда. Әни белән ялгыш та сүзгә килмәделәр. Соңгы сулышын да Мәрзия кулында алды әни. «И-и Мәрзия кызым, ярый син туры килдең безгә», – дия иде. Мәрзия апаң белән бергә тора башлаганыбызга инде 63 ел булды. Бриллиант туебызны үткәрдек менә... Ул миңа бер кигән күлмәкне икенче тапкыр кигезмәде. Әшкә көн саен бәйрәмгә җыенган кебек киенеп чыгып китә идем.



УҢЫШ Институттан соң, Ямаштагы авыл хуҗалыгы училищесында ел ярым гына укытып калдым: Яңа Чишмә районының иң зур совхозына – «Красный Октябрь»гә баш инженер итеп куйдылар. Ике мең гектарда борчак кына игәләр иде анда. Бөтен эш кулдан башкарыла. Авыл хуҗалыгы институты галимнәре белән берләктә, борчакны чабып алуны механикалаштыру юлын эзли башладым, һәм таптык. Бу – ул чакта керткән яңалыкларның берсе генә.

Чистайда «Сельхозтехника» оешмасын җитәкләгән вакытта өлкә комитетының беренче секретаре Фикрәт Табиев белән таныштым. Бу шәхес язмышымда шактый зур роль уйнады... 1969 елның башында мине партиянең Чистай шәһәр комитетының икенче секретаре итеп сайладылар. Ел ахырында ялга җыендым. Көтмәгәндә Фикрәт Әхмәтҗанович шалтыратты: «Алабугага күчәсең. Шәһәр комитетының беренче секретаре итеп мин синең кандидатураңны күрсәттем», – ди. Миңа бу вакытта 36 яшь. Район зур: Морт, Менделеев, Алабуга районнарын берләштерә. Икътисады күп тармаклы. Туфрагы комлы, ярлы. Кыскасы, проблемалар җитәрлек... Мин анда эшне... Шишкин музеен ремонтка ябудан башладым. Музей бинасында әллә ничә оешма, контора урнашкан, шунда ук фатирларда кешеләр дә тора, ишегалдында – сарайда дуңгыз асрыйлар... Капиталь ремонт ясагач, өч елдан соң музей кабат ачылды.

Мин Алабугада эшләгән ун ел эчендә анда шактый үзгәрешләр булды. Як-40, Ан-24 самолетларын кабул итәрлек аэропорт төзедек. «Ижминводы» санаторие, май заводы, бассейн, «Техниклар йорты» ишекләрен ачты. Ел саен 600–800 баш малга исәпләнгән берәр комплекс сафка басты. Торак йортлар, тулай тораклар... Санап кына бетерерлекмени?!

1979 елның язында Фикрәт Табиев кабат минем белән элемтәгә керде: «Сине өлкә комитетының авыл хуҗалыгы бүлеге мөдире итеп билгеләргә тәкъдим иттем», – ди. Ләкин кабинетта утыру, кәгазь белән генә эшләүнең минеке түгел икәнен бик тиз аңладым. Яшел Үзәнгә җибәрүләрен үзем сорадым. Авыл хуҗалыгы буенча соңгы урында иде район. Без ул елны эшләп булмастайны эшләдек: 18 көн эчендә урып-җыюны төгәлләдек, 5 октябрьгә туңга сөреп бетердек. Тукай районыннан кала, иң зур уңыш бездә булды! Бер җитәкчене урыныннан алмадым – кешеләргә кайчак канат кына куя белергә кирәк... Ул чакта халыкны: «Партбилетың белән кил», – дип куркытып эшләтәләр иде. Мин ул юлны сайламадым. Бөтен мөмкинлекләре булган кыр станнары төзеп,

комбайнчылар гына түгел, без – бюро әгъзалары да куна-төнә эшләдек.

Гомер булгач, сынаулар да кичәсең... Яшел Үзәннән эштән алуларын әйтәм. Җир җимертеп эшли ала торган чагым – 50 яшем яңа тулган. Авыр булды, яшермим. Гаепсез икәнемне беләидем, шуңа сынмадым. Кемдер хәсрәтне аракы белән юа, мин ул чакта 100 грамм да эчмәдем. Тау битендә дачабыз бар иде: бакча янында яткан таш блокны иртән тауга тартып менәм, кич тартып алып төшәм... Гаиләм нык, балаларым исән-сау, кайда эшләсәм дә, уңышка ирешәсемне беләидем. 1992 елда улым Самат белән фермерлык эшенә тотындык. Эшнең ояты юк: КАМАЗ машинасына утырып, 100 гектарлы басуда иккән икмәкне элеваторга үзем ташыдым. Бишәр йөз тонна!



ДУСЛАР Тәүлекнең теләсә кайсы вакытында ярдәм сорый алырдай дусларым бар, билгеле. Күп алар! Дөрес, мин беркайчан да кеше өстенә салынмадым – үз проблемаларымны үзем хәл итәргә тырыштым. Фикрәт Табиевның мине якын иткәне күпләргә сер түгел иде, әмма беркайчан да аңа ниндидер үтенеч белән мөрәҗәгать итмәдем. Холкымны белгәнгәдер: «Миңа анда яки монда эшкә урнашырга ярдәм ит әле», – дип үземнән дә сораучылар булмады диярлек. Кирәк өчен генә дуслашучылардан ерак тордым.



АКЧА Беркайчан да зур акчаларыбыз булмады безнең. Суыткыч та гел буш иде... Мәрзия бер совхоз директорларына кунакка барып кайткач: «Кешеләр гел бөтенләй башкача яши икән», – дип аптырап сөйләгән иде.

Яшел Үзәндә эшләгән чагым. Ялга китәр алдыннан, җитәкчеләрнең берсе өстәлемә конверт кертеп куйды. Сикереп торып, аны бүлмәмнән куып чыгардым. Андый хәл башка кабатланмады. 50 яшем Яшел Үзәндә эшләгәндә тулды – бүләк бирергә түгел, хәтта беркемгә котларга да рөхсәт бирмәдем. Алдан ук әйтеп куйдым.

Фермер хуҗалыгын оештыргач кына акча күрдек без. Баедык! Үз йортыбызны салып кергәндә пенсиягә чыккан идек инде. Аңарчы гел хөкүмәт биргән вакытлы фатирларда яшәдек. Гомер буе!



БАЛАЛАР Кызларымнан да, улымнан да мин бик канәгать. Үзләре әйткәннәре юк, әмма алар миннән алай ук түгелдер. Үпкәләсәләр дә, хаклары бар... Күп вакыт өйгә алар йоклларга яткач кайттым, иртән, алар торганчы, инде чыгып киттем – сирәк күрделәр. Самат хәзер дә искә төшереп сөйли: «Иң рәхәт вакыт Алабугага яңа күчкән чакта булды. Син әле эшкә чуммаган идең, хәтта кичен безнең белән урамга йөрергә чыга идең», – ди. Ә берсендә Лилия көне буе минем белән булган, һәм мин аңа гел конфет кына ашатканмын. Башка әтиләр кебек ботка-мазар пешерә белми идем шул...

Икенче кызым Резеда мәктәпне алтын медальгә тәмамлады. Үз язмышын үзе хәл итәргә тиеш дип санадыммы икән – аңа булышып җибәрмәдем. Хатам дип саныйм моны... Резеда бик талантлы, потенциалы да зур иде. Казан дәүләт университетының механика-математика факультетын тәмамлады, Чаллыда үзенең фирмасы бар. Лилия – Алабуга дәүләт педагогика университетында чит телләр факультетында белем алды. Француз һәм инглиз телләрендә иркен аралаша – югары уку йортында укытты. Ә Самат бабасына охшаган – кулы эшкә бик оста: техниканы биш бармагы кебек белә. Ул теләсә кайсы машинаны үзе җыеп чыга ала. Минем машинага да, апасыныкына да техник хезмәт күрсәтү – аның өстендә. Улым белән без бер-беребезгә бик якын, яшәвебез дә янәшә генә.

Мин балаларыма: «Безнең әти беренче секретарь», – дип әйтергә беркайчан рөхсәт итмәдем. «Моның белән мактанмагыз, бу – вакытлыча, мин инженер-механик, – дия идем. – Башкалардан аерылып тормагыз, кешедән кайтышрак киенегез». Шулай үзләренә җиңелрәк булыр дип санадым. Сүземнән чыкмадылар. Резеданың университетта укыганда тулай торакта бергә торган бүлмәдәш кызы минем кайда эшләгәнне биш ел буе белмәгән.

Гаилә корганда да без аларга сайлау мөмкинлеге бирдек – үзләре тапкан, яраткан кешеләре белән кавыштылар. Тормышлары матур. Инде оныклар да буй җитте, башлы-күзле булдылар.



КУРКУ Бернәрсә дә куркытмый мине бу тормышта, сеңлем. Бүген күземне йомсам да риза. Ә нигә үлемнән куркырга? Анда баргач, туры оҗмахка эләгергә өметләнәм *(көлә)*. Әкрен генә әзерләнәм, догаларны беләм – зур мәҗлесләр булмаганда, өйдә үзем генә укыйм.

Үкенечләрем юк. Яраткан эшемдә эшләдем. Балаларым аякка баскан – алар өчен борчылмыйм. Күрәсен – шактый күрдем. Ничә тапкыр хирург пычагы астына гына яттым: сукыр эчәкне алдылар, үт куыгым күптән юк, күзләрнең икесен дә яңарттылар... Кремль астындагы хастаханәдә яттым – яман шешне кичердем. Инфарктның ни икәнен беләм. Озак яшәүнең сере бик гади – бернәрсәгә дә зарланмаска кирәк. Оптимист булырга! Мин юк кына нәрсәдән дә ямь эзлим, үз күңелемне үзем күтәреп яшим. Эштән бүген дә тәм табам. Сыерлар инде асрамыйбыз, тавыклар гына калды. Егерме башка якын умартам бар – җәйләрен шул кортлар янында әвәрә киләм. Әйткәнемчә, сәламәтлегем – Аллага шөкер. Бүген рульгә утырып, үземә кая кирәк, шунда чыгып китә алам.



ҮЗЕМ ТУРЫНДА Янәшәмдәге кешеләргә минем белән җиңел булмагандыр. Бик таләпчән идем! Әмма мин һәрвакыт гафу да итә белдем. Хәтта үземә начарлык эшләүчеләрне дә.

Гөлнур САФИУЛЛИНА

PRESSA.RU

Менә шулай! Халисә Мөдәррисованың исемен атау да җитә безнең кызларга!.. Янып, шигырьләрен яттан сөйлиләр. «Син бит миңа якты йолдыз булып, / Яңа йолдыз булып күрендең», – дип башлый берсе, «Йолдызларга кемнең буе җиткән...» – дип дәвам итә икенчесе. «Күзге урман, сары ялан... Коела кыңгыраулар...» – дип, «Балан»ын җырлыйлар, «Сагындым сөйгәнемне», – дип өзгәләнәләр... Халисәнең Казанга килгән көннәре исә бәйрәмгә әйләнә. Ул яз, ярату, хис, моң булып түгелә дә тагын Уфасына ашыга. Ә җанда күпме җырлар, шигырьләр кала!..

Халисә МӨДӘРРИСОВА

КҮЗ-ДӘРЬЯНДА – СӨЮ КӨЙМӘМ

* * *

Юк, кайтарып булмый үткәннәрне,
Ике какмый ярга бер дулкын.
Үткәннәрнең эзен эзләп килдем,
Үткәннәрнең эзе сап-салкын.

Кадерләрен белер гомерләрдән
Үтеп киттек ятлар җитәкләп.
Ә үткәндә, ятим бала кебек,
Үксеп калды безнең мәхәббәт.

Үткәннәрне эзләп йөрмә, диеп,
Җил йөгерә минем эземнән.
Үткәннәрне ташлап китеп була,
Ләкин китеп булмый үзеңнән.

Соңладык

Мин яраттым сине, тик югалттым,
Бердәнберем – яшьлек хыялым.
Мин бит сине сөеп туялмадым,
Аңлатырга гына,
Аңлатырга гына,
Аңлатырга сиңа соңладым.

Аерды да адаштырды язмыш,
Туктатырга нигә кыймадым?
Гомер буе сиңа ашыксам да,
Яратырга гына,
Яратырга гына,
Яратырга сине соңладым.

Һаваларда ялгыз торна моңы,
Соңгы җырын икәү тыңладык.
Көттермичә килде үкенүләр,
Кавышырга гына,
Кавышырга гына,
Кавышырга нигә соңладык?!

* * *

Миңа да бит җиңел түгел,
Сиңа да бик авырдыр.
Аяз көннәребез өчен
Сездә хәзер давылдыр.
Миңа гына калдырсаң да,
Күтәрермен ул йөкне.
Тик акланып, ят телләргә
Калдыра күрмә мине.

* * *

Күз-дәрьяңда – сөю көймәм –
Һәлакәткә юлыгу,
Кешедән дә, һәм синнән дә,
Үземнән дә бу курку.

Җиде җилгә ачык җаным
Бикле менә кысага,
Чикләр чикли алмый дисәм,
Алда кыя, бусага.

Араларда ажгыр җилләр,
Дулкын шомлы, юк тиңе,
Кемдер сине агарттымы?
Йә каралттымы мине?

Хушлаштың, китә аласың.
Арада – күпер-тәүбәм.
Тик нигә сон күз-дәрьяңда
Тирбәлә һаман шәүләм?

Кызыма

Урамда – март.
Соңгы буран бурый,
Яз булмас та кебек быелга.
Ак касәдә гөл орлыгы йоклый,
Йоклый кыз күңеле, бар дөнья.

Быел шытып гөл буласы орлык,
Ниләр кирә синең төшләргә?
Язгы кояш нуры, җәйге җилләр,
Кырау үбеп үтәр көз мәллә?

Гөл орлыгы кебек яшь кызыма
Күп нәрсә сер, яңа, яшерен.
Уянасын белми, язлар көтми
Һәм уйламый кырау төшәрен.

Гомер язы якын, белми кызкай,
Ак касәдә чәчкә орлыгы,
Урамда март, дөнья төшләр күрә,
Җирдә әле кышлар тынлыгы...

Тик яз якын инде...



Илфакча, Илфак турында, Илфак истәлегенә... Соңгы вакытта бу сүзләр еш яңгырый. Филармониядә узган Илфак Шиһаповны сагыну кичәсе... Аның җырлары... Берәүне дә битараф калдырмый – йә елата, йә көлдерә торган иҗаты... Журналист, продюсер, газеталар нәшер итүче, шагыйрь, җырлар авторы... һәм искиткеч чиста күңелле, милли җанлы олпат шәхес... Еллар узган саен, аны ныграк сагынырбыз әле. Хушлашу итеп язып калдырган сүзләрен искә төшерербез: «Китәм инде... Үкенечсез, үпкәсез... Күкләремә рәхмәт әйтеп... Мин яратам сезне, кешеләр...» Күңел белән Иске Иштирәк зиратындагы каберенә чәчәкләр салырбыз. Җырларыннан, шигырьләреннән һаман үзен эзләрбез...

Илфак ШИҺАПОВ

МИН ЯРАТТЫМ, ЯРАТАМ, ЯРАТЫРМЫН...

* * *

Берәр кайчан,
чып-чын картлык килгәч,
Чәчләргә чал кереп утлар сүнгәч,
Газраилне көтеп тик ятканда
Бер кат күккә менеп –
бер кайтканда,
Искә төшәр әле бу мизгелләр...
Күз яшьләре, уйлап тилерүләр.
Бер матур төш кебек булыр алар,
Беткән булыр без үтәсе юллар,
Һаман шулай агар агымсулар,
Һаман шул ай җир-ананы урар,
Без ятарбыз Газраилне көтеп,
Тиле булган чаклар өчен
нык үкенеп.
Соңгы сулыш белән мин
әйтермен тагын:
«Мин яраттым, яратам,
яратырмын...»

* * *

Берәр кайчан, бөтен юлны
үтеп беткәч
Кемдер күктән: «Улым, тукта,
җитте», – дигәч,
Шуннан илче көтеп тик ятканда,
Юкка яшәмәдемме дип уйлаганда,
Искә төшәр әле бүгенге көн,
Синең белән булган һәр изге төн.
Бер матур төш кебек булыр алар,
Син кочакта чакта саташулар,
Бер үкенеч калыр бу язмыштан,
Бергә була алмаган буш тормыштан.
Шунда әйтер күкләр:
«Очраштырдым.
Очраштырдым, таныштырдым,
кавыштырдым.
Бар дөньядан куркып сөештегез,
Кеше генә белмәсен тик», –
диештегез.
Үкенмәгез ул тормышны
хак санагач,
Кеше сүзе бәхеттән дә
кыйммәт булгач».
...Берәр кайчан бөтен юлны
үтеп бетәм,
Күктән: «Булды, улым» дигән
сүзне көтәм...
Җавап итеп күккә кычкырырмын:
«Мин яраттым, мин яратам,
яратырмын...»

* * *

Күккә карап сиңа телим теләк,
Шуны сорый бүген минем йөрәк,
«Бәхетле бул, акчаң булсын, димен,
Булсын бик акыллы, яратучы ирең,
Ул кичерсен синең гөнаһларны,
Бәгыреңне читкә таратканны...
Балаларың булсын сау-сәламәт,
Һәр көн тоеп яшә җирдә рәхәт,
Тәңрем! Ялгышлардан сакла аны,
Гел яхшыдан булсын бар булганы,
Эшең барсын, иреш хыялыңа,
Ак җәймәләр синең юлларыңа...»
Күккә карап сиңа бәхет телим...
Кайсы теләк кабул булыр – белмим,
Ләкин шуны беләм, һичбер сүзсез:
Син бәхетсез булсаң –
мин бәхетсез...

* * *

Яндырам күңелнең
Иң нечкә кылларын,
Буталды язмышлар,
Адашты юлларым.
Берни дә кирәкми,
Бар тормыш – чүп кенә.
Яндырам андагы
Саташып сөюнең
Иң изге булганын,
Беренче булганын,
Яндырам күңелнең
Иң нечкә кылларын...

* * *

Бәхет дигән серле ул кош
Бигрәк якын килгән иде.
Мин ул кошны җиңел генә
Тотам инде дигән идем.

Тик...
Булмады...
Качты кошым –
Минем гаеп белән түгел.
Тик барыбер
Гомерлеккә
Сыгылды да... Сынды күңел...

PRESSA.RU



Роза
ТУФИТУЛЛОВА

Күренекле җәмәгать эшлеклесе, язучы һәм журналист Роза Туфитуллова «Бәйлисе бар йөрәкне» дигән китабы белән укучылар күңелен яулаган иде инде. Халкыбызның бөек шагыйре Хәсән Туфан язмышының моңарчы серле булып кала килгән сәхифәләрен ачып, әлеге әсәре белән әдәбият дөньясында вакыйгага ясады ул. ...Һәм менә автор укучыларына тагын бер бүләк әзерли: «Язмыш җиле» әсәренең соңгы бүлекләрен төгәлләп килә. Күренекле хатын-кызларыбызның берсе, Петербургның атаклы Бестужев югары курсларында белем алган, 1912 елда Балкан сугышында шәфкать туташы буларак катнашып, зур каһарманлыклар күрсәткән, Габдулла Тукай, Гаяз Исхакый, Муса Бигиев, Фатих Әмирхан, Фатих Кәрими, Йосыф Акчура кебек олуг шәхесләребез белән аралашкан атаклы Чистай кызы Гөлсем Камалова турында ул. Игътибарыгызга шул әсәрдән бер өзек – Гөлсемнең Тукайга булган шагыйранә мәхәббәтен сөйләүче «Кара төннең ак фәрештәсе» бүлеген тәкъдим итәбез.

КАРА ТӨННЕҢ АК ФӘРЕШТӘСЕ

Ауру җанның бишмәте – тәнне дәваның төрлесе
Берлә һәр көнне ямыйм, иртән тагын ертык күрәм.
Бар иде ялгыз калып, җырлап юанган чакларым,
Ярты җырда инде күкрәкне тотам да йөткерәм.

Г. Тукай

Петербург бу юлы да мине үзенең кабатланмас матурлыгы – сихри ак төннәре белән каршылады. Табигатьнең әлеге могҗизасы бу калага аерым бер ямь, илаһилык өсти бугай. Шуңадырмы, аның урам-мәйданнарыннан узган чакта, аяк очларына гына басып йөрисе, пышылдап кына сөйләшәсе килә. Шулай итмәгәндә бу мәгърур каланың серле аһәңен тоеп булмастыр кебек.

Петербургта җанга якын урыннар аз түгел. Бирегә килгән саен, шәһәрнең үзәк урамнарыннан саналган Казанский урамын урап кайтырга яратам. Исеме белән дә, җисеме белән дә игътибарны үзенә тартып торучы әлеге урам ничаклы сер, кадерле хатирәләр саклый. Заманында шушы урамның 39 нчы йортында бөек поляк шагыйре Адам Мицкевич яшәп киткән. Аның янына русның бөек шагыйре Александр Пушкин һәм аның якын дусларыннан берсе – шагыйрь Антон Дельвиг килеп йөргәннәр. Соңрак бу йорт Петербургка сәфәрләрендә Николай Гогольнең сыену урынына әверелгән.

Казанский урамының сулъяк тыкрыгына урнашкан йортка (37 нче йорт) Мәскәүдән үзенең кардәше Ольга Фрейденбург янына яшь гашыйк шагыйрь Борис Пастернак килгәли торган булган. Күпмедер вакытлар урамның 3 нче санлы йортында русның атаклы шагыйре Анна Ахматова яшәгән. Аның кабатланмас сурәтен таш диварлар әле дә хәтерлидер сыман... Кыскасы, Казанский урамын, һич икеләнмичә, шагыйрьләр урамы дияргә мөмкин.

Архитектура ягыннан әллә ни үзенчәлеге абайланмаса да, бу урамның мин эзләгән 5 нче йорты да күркәм, нурлы бина. «Казанский» мосафирханәсе урнашкан әлеге йортта элек-электән танылган шәхесләр туктала торган булган. Моннан йөз ел элек, төгәлрәк әйткәндә, 1912 елның апрель азагында, шушы йортта татарның мәшһүр яшь шагыйре Габдулла Тукай яшәп киткән.

...Тукай яшәп киткән...

...Петербургның ак төннәренә төренеп, сагышлы-сагынулы хисләремнән эчем-тышым туңган, елаган бер халәттә кунакханә катын сүзсез-өнсез күзәтәм. Бары тынгысыз уйларым гына гасырларның нәни Габдулланы саткан, елаткан, Тукай итеп моңландырган, җырлаткан, милләтем дип җан аттырган, ачы язмыш, тәкатьсез авырулар белән тилмерткән тарафка юнәлә... Әнә уйларымның күпмесе күз алдымда чәчелеп «җирдә» ята. Берәмтекләп җыям. Рухына багышлардай, юатырдай, кабатланмас нинди дога-сүзләр табарга?! Бәгырьләрне телгәләп, шагыйрь җаны сыктый:

Үпкәнеңнән бирле, әнкәй, иң ахыргы кәррә син,
Һәр ишектән сөрде угълыңны мәхәббәт сакчысы.

И мәхәббәт сакчысы! Син шулкадәрле таш бәгырьлемени соң?! Син әле дә булса биредә сакта торасың түгелме соң?! Бәлкем, синең өчен «үткән» дигән төшенчә дә юктыр. Димәк, әле син кулына ак ландышлар бәйләме тоткан ак күңелле кызны – Тукай өчен җан аткан татарның затлы бер гүзәле Өммегөлсем-Джоконданы да хәтерлисеңдер?! Хәтерлисең, билгеле! Җавап тоту җилләргә йөкләнгән, диярсеңдер. Искәрмәстән, уйларымны кысрыкларга тәләгәндәй, әнә шул җил, язмыш җиле искиткеч бер тизлек, куәт белән каракучкыл болытларны бергә сөрә. Күз ачып йомганчы салкын, күшектергеч яңгыр коеп үтә. Ахрысы, бер гасыр моннан элек булган вакыйгаларны искә төшерер өчендер.

...Ни кызганыч, Рәсәй башкаласын иңләп-буйлап йөрү, зиннәтле сарайларын, музей-театрларын күрү насыйп булмый шагыйребезгә. Петербургка килгәч, аның үзәк-бәгыренә төшкән үпкә чире тагын да көчәя төшә. Шәһәрнең җелекләргә үтә торган дымлы салкын һавасы шагыйрьне көннәр буе мосафирханәдә утырырга мәҗбүр итә. Дөрес, биредә яшәүче дуслары аны ялгызын калдырмаска тырышалар. Шагыйрьне күреп калырга теләүчеләрнең дә саны көннән-көн арта бара.

Тик әлегә шагыйрь берәүнең дә ишек шакуын теләми. Аның, гадәтенчә, кулларын баш астына куеп, күзләрен йомып, Муса Бигиевларда* үткәргән кара төннең ак фәрештәсен генә күңеленнән кичереп, янә бер юанасы килә. Ни хикмәт, шушы яшерен-тансык хыялый бер мизгелдә каһәрле ютәлен, авыруын, туңуларын онытгырып торадыр кебек.

...«Дөнья читлегеннән» очып чыгарга җыенган чарасыз шагыйрь йөрәгенә кинәт сак ак фәрештә килеп «орынасы» итте. Фәрештә күзгә күренеп йөри башласа, билгеле инде... Төн фәрештәсе, «ак томан» эченнән «йөзеп чыгып», телгә килде. Нинди йомшак, моңлы, иркә тавыш.

– Тукай әфәнде, зинһар, кичерә күрегез. Башкача түзеп торырлыгым калмады. Ютәлегез бигрәк көчле. Сезнең өчен җаным парә-парә килә... Шушы мәтрүшкәле кайнар сөтне эчеп карагыз әле. Шифасы тимичә калмас. Савыга күрегез! – диде дә әлгәре ничек гаип булса, шулай ук «эреп» юкка да чыкты.

Стена аша гына шагыйрьнең шул дәрәҗәдә газаплануын ничек тыныч күңел белән тыңлап ятсын Өммегөлсем? Аның тыю-чикләүләргә буйсынмаган, ни гомер сөю утында дөрләгән кайнар йөрәге бар бит әле. Яраткан Тукаен савыктырыр өчен аның бер уе, бер сүзе, бер сулышы җитәр төсле иде. Аһ, хыял белән чынбарлык арасы нинди тирән упкын икән.

Өммегөлсемнең кодачасы һәм дус кызы Мәрьямнең дә җаны үкси, тәне дерелди, ул шылт иткән тавыштан да сискәнеп, ишек катында кизү тора. Өммегөлсем өйдәгеләр күзенә чалынмасын да, Муса әфәнде генә уяна күрмәсен. Ходайның рәхмәте, ул бүген балалар янында йоклый. «Оят, гарьлек, син ничек җөрьәт иттең?» – дип күзен дә ачырмаслар. Тукайны да кыен хәлгә куярлар. Аңлатып та, акланып та өлгерә алмассың...

«Ихлас, фәрештәдер!» – дип уйлады Тукай, үзен яшәү белән үлем арасында тоткан бума ютәле басыла төшкәч. Ләкин шунда ук бу «кирәксез» тойгыга бар күзәнәкләре, вөҗдане белән карышты. «Күр бу курсистканың кыюлыгын, тәвәккәллеген! Жәлләгән... Сез түгел, туташ, мине язмыш үзе дә жәлләмәгән. Кирәкми дә. Минем максатым, юлым башка. Мине кызганганнарны сөймим мин, туташ. Сез нык ялгыштыгыз...»

Монысы ниткән өн тагын, язгы чирәм төсле кантарлы юл читендә баш калкыта?

– Шагыйрем, син үзең бу минутларда янында яраткан бер җан иясенең булуын теләгән идең түгелме соң?! Менә «мәхәббәт сакчысы» аны синең хозурыңа керүдән тыймады.

Бәхеткә, «хикмәтле төн» тагын кабатланасы итте. «Соңгы сулыш» алганда, тагын теге «ак фәрештә» иңде. Нindидер тылсым өрде, иркә пышылдады. Һәм тагын шулай нур эчендә тиз генә эреп юкка чыкты. Янә каршылыклы уйлар бил алышты. «Хөкемдар мәхәббәт сакчысы» пәйда булды. Һәм әлеге шигырь битен «ачып куйды»:

Дәртемә минем дару бар: йә үлем, йә кавышу;
Боларның һәрберсе сораучыны шатландырыр.
Аңладыңмы, и гүзәл! Йә җаным бул, йә җанымны ал;
Мин янында үлү белән бәхеткә ирештер.

– Үлем фәрештәсе шулай ук якынмыни?

– Юк...

– Ә син ялгышасың, минем «җан фәрештәм» ул түгел ич.

– Беләм.

– Минем соңгы шигырем дә Күкләр аһәңе белән башкача яңгыраячак.

– Хәбәрдар. «Васыятең» дә үзең кебек изге һәм бөек шәкелдә. Син дөньяга елап килсәң дә, киткәндә җырлап китәргә җыенасың. Дөрес әйтәмме?

– Ихтимал. Мәхәббәт фәрештәсе, син соңгы көннәрдә бик үзгәрдең әле. Әмма мин тизрәк бу йорттан качу,

---

* М. Бигиев. Күренекле дин галиме, язучы, философ.

PRESSA.RU

синең тарафтан сөрелү телим. Син үз асылыңа хыянәт итмәссең бит инде?!

...Менә, ниһаять, Тукай үзе теләгәнчә «иректә». Дуслары аны, Бигиевләрдән алып, мосафирханәгә күчерделәр. Әмма ул биредә дә салкыннан, ютәлдән һәм фәрештәләрдән кача алмас, күрәсең.

– Шулай да, рәхмәт сиңа, кара төннең ак фәрештәсе...

Шагыйрь кинәт сискәнеп китте, менә тагын кемдер бүлмә ишеген шакыды.

– Ишек ачык. Керегез! – диде Тукай, ниндидер эчке бер моңсулык белән.

Ишектән елмаеп кереп килүче европача киенгән озын зифа буйлы кызны күрүгә шагыйрь бер мәлгә телсез калды. Ә кыз исә ул арада шагыйрьне сәламләп, түргә узды. Кулындагы яңа ачылып кына килүче ландышлар бәйләмен өстәлгә куйды да, Тукайның чәчәкләргә гаҗәпсенеп карап торуын күргәч:

– Чәчәкләр каян дисезме? Урам чатында финнар сатып тора иде. Бу чәчәкләр Сезгә дә ошый дип беләм. Баксаң, Петербургка да яз килеп җитә икән, – дип елмайды.

Үзе белән бүлмәгә яз исен, ургып торган яшьлек дәртен алып кергән бу кыз, төнге «ак фәрештә» шагыйрьгә яхшы таныш. Ул дусты Фатих Әмирханның* сөйгән кызы Шәмсенисаның бертуган сеңлесе, Чистай кызы Өммегөлсем Камалова иде. Апалы-сеңелле бу кызлар еш кына «Әль-ислах» газетасы редакциясенә Фатих янына кереп йөриләр**.

Кайчакларда аларга Шәмсенисаның уртанчы сеңлесе Хәтимә дә иярә. Берсеннән-берсе чибәр, укымышлы бу кызлар редакциягә килеп керсә, Фатих үзен күкнең җиденче катындагыдай хис итә башлый. Бигрәк тә сөеклесе, асыл зат Шәмсенисаның иҗатка тартылуын, рус, француз телләреннән хикәяләр тәрҗемә итәргә алынуын бөтен йөрәге белән хуплый иде.

Кызлар арасында чаялыгы белән аерылып торган Өммегөлсемнең үзенә җан атып йөрүен белә иде Тукай. (Казанның укымышлы кызлары арасында азмыни аңа җан атучылар?) Әмма кызны күрмәмешкә салынып, һәрчак бүлмәдән тизрәк чыгып китү ягын карый торган иде. Тик менә бүген, мосафирханәдә аның белән икәүдән-икәү, күзгә-күз калгач, күрмәмешкә салыну мөмкин түгел. Ишетүенчә, Өммегөлсем Петербургның данлыклы Бестужев курсларында белем ала. Күр, әнә ничек үзгәргән!.. Русның аксөяк кызларына биргесез... Юк, юк, аңа иң килешкәне – ак фәрештә сурәтендә йөрү.

Өммегөлсем дә Тукайны күзәтә. Шагыйрь бераз хәл алганга охшый. Ютәле дә элеккечә куркыныч түгел. Юкса теге көннәрдә Тукайны жәлләп күпме зар елады Гөлсем.

Бүлмәдә урнашкан уңайсыз тынлыкны Тукай боза:

– Сезне бирегә Муса әфәнде җибәрдеме? – ди шагыйрь шактый кырыс кына.

– Юк, юк. Муса әфәнде минем Сезнең янга килүемнән хәбәрдар түгел. Мин алар фатирында онытып калдырган әйберләрегезне китердем, – дип, кыз кечкенә ридикюленнән өстәлгә портсигар белән чәч тарагы чыгарып куйды.

– Юкка мәшәкатьләнгәнсез, берәр студент кереп алган булыр иде әле.

– Һичбер мәшәкать түгел, Тукай әфәнде, – диде кыз, үзгә бер итагатьлелек белән.

Тик әллә каян сизелеп тора: кызның шагыйрьгә тагын нидер әйтәсе бар. Ниһаять, ул бөтен ихтыяр көчен туплап, сүз башлады:

– Әгәр дә сөекле шагыйребезнең өч төн буе Муса әфәнделәрдә газаплануларын күреп калмасам, бирегә килеп, Сезне борчып йөрмәгән дә булыр идем. Сезгә кичекмәстән Кырымга китәргә кирәк, Тукай әфәнде. Кырым һавасы белән диңгез суы Сезне бик тиз аякка бастырачак. Кырымда минем белән бер курста укучы Мәймүнә атлы кызның әти-әнисе яши. Алар гаҗәеп кешеләр, Сезне бу көннәрдә үк кабул итәргә әзер, – дип, кыз шагыйрьгә телеграф кәгазен суза. – Әгәр риза булсагыз, без Мәймүнә белән Сезне Кырымга озата да барыр идек...

Тукайның кинәт йөзе үзгәрүен күреп, кыз сүзеннән туктап кала.

– Нинди гадәт соң бу укымышлы бай кызларында! «Әфәндем» дия-дия эч пошырулары җитмәгән, берсенберсе уздыра-уздыра мине дәваламакчылар, – дип, шагыйрь, ихтыярсыз, йодрыгын кысып куйды. Аннан тагы, кырысрак күренергә тырышып, сүзен дәвам итте:

– Юкка хафаланасыз, туташ. Миңа Кырым да, Швейцария белән Финляндиягез дә кирәк түгел. Кичә мине Петербургның иң абруйлы докторына күрсәттеләр. Ул авыруымның узгынчы булуын әйтте.

– Бу хәбәргә мин чиксез шат, тик менә бирегә килүем генә Сезгә куаныч өстәмәде, – дип, Өммегөлсем урыныннан кузгалды.

Тукайның: «Кара төннең ак фәрештәсе, рәхмәт сиңа, артыгын сөйләмә, кирәкми, хуш!» – диясе килде. Тик ул сүзләр тел очында калды.

Өммегөлсем янә ихлас дәлилләвен дәвам итәргә уйлады.

– Тукай әфәнде, сүз Сезне җаныннан артык яраткан, шигырьләрегезне догага тиң күргән саф күңелле туташлар турында бара. Сез алардан йөз чөерәсез. Диңгездән баш тартуыгыз да гаҗәпләндерә. Ә бит диңгез үзе Сезгә күпме шигъри илһам өстәр иде.

Тукайның күзендә зәһәр очкыннар күреп, Гөлсем тагын туктарга мәҗбүр булды.

– Туташ, Ходай Сезгә Рәсәй башкаласында белем алу мөмкинлеген авыру шагыйрь янында утырыр өчен бирмәгәндер дип уйлыйм. Белем үрләрен яулаучы кызларыбызны мин башка уй-хисләр белән яналар дип уйласам, сезне күбрәк вак-төяк мәсьәләләр биләп алган

* Ф. Әмирхан. Язучы, публицист.

** Р. Әмирхан. Әмирханнар. – Казан.: «Мәгариф» нәшрияты, 2005.

булып чыкты. Милләтебезнең зур үзгәрешләр алдында торуын азмы-күпме чамалыйсыздыр, шәт? Халкыбызга хезмәткә күпме фидакарь мөгаллим-мөгаллимәләр кирәк хәзер.

– Кичерегез, – диде кыз ишетелер-ишетелмәс кенә. – Ни генә дисәгез дә, Сезгә ярдәм итәргә йөрүемне мин вак-төяк эш дип саный алмыйм. Серноводскидан Сезгә дустыгыз Фатих әфәнде Әмирхан аркылы җибәргән мәктүбемдә мин үземнең мөгаллимә булырга җыенуымны ачык итеп язган идем шикелле. Мөгаллимә булу – минем дә изге хыялым.

Кызның бу сүзләреннән соң, үзен чамасыз бер киеренкелектә сизгән Тукай аңа текәлеп карамый булдыра алмады. Өммегөлсемнең бит урталарыннан тыелгысыз агучы күз яшьләре аны тирән гаҗизлеккә салды. Ул эчтән үзен әрләргә дә, акларга да өлгермәде, ишек шакыдылар.

– Керегез, – диде шагыйрь, үз тавышын үзе танымыйча аптырап. Һәм бүлмәгә шаулап-гөрләп Петербургта укучы бер төркем татар студентлары кереп тулды.

– Мөмкиндер бит, Тукай әфәнде?

– Әссәламегаләйкем, сөекле шагыйребез!

– Хуш кынамысыз, Тукай әфәнде!

– Саумысыз? Күрми калабыз дип шундый борчылган идек...

– Менә бит насыйп булгач...

Һәрберсе шулай үзенчә сөенеп, Тукайны олылыклап, кул биреп күреште, шигырь белән сәламләде:

Бер мөкаддәс хис белән һәрбер кеше хәйран бүген;
Уйный сазым да минем бәйрәм көен, бәйрәм бүген!
Бәйрәм бүген, бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!

– Джоконда, син дә бирედә?! Син һәрвакыттагыча өлгер инде... һәм чибәр, – диде егетләрнең чаярагы, игътибар үзәген бер мизгелгә Өммегөлсемгә күчереп. Тукай чак кына җиңел сулап куйды.

– Ә без сине шәһәр бетереп эзләп йөрибез. Муса әфәнделәргә дә кереп чыктык. Сенат мәйданында узачак «Ак чәчкә» акциясе иртәгәгә күчерелде. Мәрьям туташ белән икегезгә җаваплы эш тапшырыла. Беләсеңдер, шәт, – диде җитди кыяфәтле, өлкәнрәк күренгән егетләрнең берсе.

Өммегөлсем, беләм дигәндәй, баш кагып куйды да ашыгып ишеккә юнәлде. Әллә инде хушлашмады да...

– Ә нигә сез аңа Джоконда дип эндәшәсез? – дип сорады Тукай, кыз чыгып киткәч.

«Өммегөлсем», дип, эчтән генә өзелгән, хыялый елмайган егетләрнең берсе җавапны озакка сузмады.

– Нигә дип... Серле елмаюы өчендер. Гаяз ага Исхакый* Петербургта чагында аңа һәрчак Джоконда дип эндәшә иде. «Мәшһүр итальян рәссамының атаклы портретын хәтерләтә», – дигән иде ул.

– Әйе шул, Өммегөлсемне Леонардо да Винчи портретыннан төшкән серле сурәт диярсең, – диде күзлек аша зәңгәр күзләре көлеп торганы.

* Г. Исхакый. Күренекле сәясәтче, язучы, драматург, нәшир.



Рәсем: Наталья Васильева

PRESSA.RU

– Аның үз исеме тагын да килешлерәк, минемчә, – диде Тукай, егетләргә карамаска тырышып.

– Әйе шул, ант шулай!

– Чын татарча!

– Бигрәк матур исем! – дип гөр килеп, калганнары шагыйрьне куәтләде.

Тукайның да йөзе җанланып, алсуланып китте. Яшьләрнең телгә осталары, шагыйрьнең кәефен күтәрмәк булып, күбрәк сөйләде. Тыйнак-сабырлары бу саваплы очрашуга эчтән генә сөенде. Күңеле нечкәләренең йөрәгеннән кан саркыды. Тукай белән, шигырь белән төшләнгәннәргә шигырь укыды:

Айрылып китсәм дә синнән гомремнең таңында мин,
И Казан арты! Сиңа кайттым сөеп тагын да мин.

Ул таныш кырлар, болыннар тартты әүвәл хиссеми;
Тарта торгач куймады, кайтарды ахыр җисмеми.
....
Зур бу урман: читләре күренмидер, диңгез кеби;
Биниһая, бихисаптыр, гаскәри Чыңгыз кеби.
Кылт итеп искә төшәдер намнары, дәүләтләре
Карт бабайларның, моны күрсәң, бөтен сауләтләре.
Ачыла алдыңда тарихтан театр пәрдәсе:
Аһ! дисең, без ник болай соң? Без дә Хакның бәндәсе.

Тукай аңлады: болар чын татар балалары, чөнки татар җаны беркайчан да моңсыз, сагынуларсыз була алмый. Алар әнә Тукайның үзен дә җылы, сагынулыяратулы хисләргә төреп куйдылар. Шагыйрь бу яшьләргә рәхмәтле иде. Очрашуга йомгак ясап, аларга бүләк бер шигъри рух өстәргә теләве дә шуның өчен иде.

Сөям мин сезне – сез чын яшь егетләр,
Өмет бар сездә, сез – интеллигентлар.

** * **
Бар уем кичен-көндезен сезнең хакта, милләтем:
Саулыгың – минем саулык, авыруың – минем авыруым.

Син каршымда бар нәрсәдән дә изге һәм хөрмәтле:
Дөнья бирсәләр дә, сатмам милләт, миллиятемне.

Тукай беравык алкышларга һәм сокланулы авазларга күмелеп торды...

– Тукай әфәнде, иртәгә сезне «Ак чәчкә» бәйрәменә чакырабыз.

– Без сезне иртән үк кереп алырбыз.

– Туберкулёз белән авыручыларга ярдәм йөзеннән оештырыла ул.

– Петербургның бөтен татар яшьләре җыелачак анда.

Студентлар, Тукай белән очрашудан биһуш булып, иртәгәгә чаклы саубуллашып чыгып киттеләр. Шагыйрь бәйрәмгә барырга ризалык бирде.

Бүлмә тынып калды. Тик нигәдер һаман «Сагыныр вакытлар» тынгылык бирмәде:

Йоклыйсың рәхәт кенә; төнлә уянсаң берзаман,
Як-ягың тып-тын – әле юк яктылык, таң атмаган.

Шулвакыт яшьләр күзендә: җан ачып, җан сызланып
Еглыйсың, Җан-Зөһрә берлән, Җан-Таһирны кызганып.

...Шагыйрь елый иде.

Оят, валлаһи! Петербургтагы журналист дуслары Кәрим Сәгыйд белән Кәбир Бәкергә шушы «фәрештәдән» зарланды түгелме соң инде ул? Имеш, Муса Бигиевларның болай да кысынкы фатирларын курсисткалар чорнап алган. Дөреслектә исә, шагыйрьнең эчке һәм тышкы халәте аларның артык илтифатын, артык олылавын кабул итәр дәрәҗәдә түгел иде шул.

Менә тагын аның каршылыклы җаны, холкы, авыруы, ачы язмышы, санаулы көннәре, мәхәббәт, бәхет хакындагы уйлары, сүз берләшкәндәй, күкрәгенә килепябышты... Тукайның җанында аяусыз тугыз баллы дулкын күтәрелде. Ярсыган ак күбекле дулкын-хисләр чайкалды, чайпалды, чәрдәкләнде.

– Кырым дисең син, табигать иркәсе. Ә бит син яхшы беләсең: ул – суның кояшлы, сай җирендә йөзүчеләр өчен генә җылы икәнен. Минем кебек хакыйкать диңгезендә йөзгәннәр өчен ул башкача. Тирәнрәк төшкән саен, аның суы салкынрак һәм басымы көчлерәк. Шагыйрь күңелендә купкан хисси давылларның куәтен дә, күпме уй-хыялларымны тормыш атлы иң кырыс диңгез йотканын да син әле соңрак аңларсың...

Бу мизгелдә күз яшьләренә күмелеп, баскычтан төшеп килүче Өммегөлсем-Джоконда бер генә нәрсә турында уйлый иде: тизрәк биредән китәргә! Тизрәк! Аяклары аны үзеннән-үзе Нева ярына тартты. Яз язлыгын итә. Невада боз кузгалган чак. Көзгедәй су өстендә берсеннән-берсе зиннәтлерәк сарайлар, йортлар чайкала. Бозлар эреп ята. Тик менә шагыйрь йөрәгендәге боз катламын гына кузгатырлык түгел икән.

Тәкъдирнең мәңгелек туңын-бозын эретергә Өммегөлсемнең кайнар хисләре генә җитмәс, күрәсең. Тукай – зур бер айсберг төсле. Аңа синең ак җилкәнле корабыңа сугылып китү берни тормый кебек. Шулай түгелмени?!

– Юк-юк, һич алай түгел, – дип кайнарланып, күз яшьләре белән үз-үзенә исбатларга тотынды Өммегөлсем. Чөнки ул әле моңа чаклы Казанда

Дворяннар клубында узган әдәби-музыкаль кичәнең татлы «төше» белән яши иде*. «Почта уены» ничек

* Казанда беренче тапкыр үткәрелгән әдәби-музыкаль кичәдә Гөлсем Тукай белән очраша. Тукайның замандашы, язучы, дин белгече, публицист Галиәсгар Гафуров-Чыгътай үзенең көндәлегендә бу вакыйганы төгәл вакыты белән язып куя. 1908 елның 8 март киче була ул. Ул кичне Чыгътай шагыйрьнең Чистай ишаны кызлары тирәсендәрәк чуалуын яза. Икенче көнне иртән Тукай тарафыннан язылган «Кулың» шигыренең шул кызларның берсенә аталуын да искәртә. (Галиәсгар Гафуров-Чыгътай. «Сайланма әсәрләр». «Ихлас». Казан, 2013 ел. 331–333, 342–345 битләр.) Г. Тукай белән Зәйтүнәнең беренче очрашулары 1908 елның май башына туры килә. Ә. Алиева, Ф. Ибраһимова төзегән «Габдулла Тукай: тормыш һәм иҗат елъязмасы» (Татарстан китап нәшрияты, 2003).

якынайткан иде аларны ул кичне. Гашыйк «почтальон Өммегөлсем», форсаттан файдаланып, Тукайга бер-бер артлы хатлар яза да, серле елмаеп, шагыйрьнең учына илтеп сала. Ник башка бер генә кызның хатын тапшырсын! Тукай да моңарчы күрелмәгән бер җылылык белән: «Мине «сәлам хатлары» белән сөендерүче гүзәл туташ шулай берәү генә булдымыни? – дип шаярта. – Сезгә почтальон булу бик килешә. Ә хатларыгызны уку – бәйрәм, – дип пышылдый һәм Өммегөлсемнең кулын йомшак кына тоткан килеш беравык җибәрмичә тора. Кызның бит урталары алланып яна, карашы өтә, елмаюы иркәли. Ул горур кыяфәт, нәфис буй-сын, нәни энҗе калфак, ак энҗе тешләр, чиядәй ымсындырган иреннәр...

Шагыйрь йөрәген ниндидер бер билгесез рәхәтлек хисе биләп ала.

– Тукай әфәнде, ә сез хатларны кычкырып укыгыз, – дип, яшьләрнең шау-гөр килүләре генә аны җиргә төшерә.

– Рөхсәт итсәгез, мин хат иясенә бер шигыремне генә укырмын.

Яшьләр, Тукай авызыннан әйтеләчәк могҗизаи сүзләрне көтеп, тын калды.

Җанын фида иткән фәкыйрьмен, гыйшкың күбәләгемен;
Кил, гүзәл, күрсәт матурлыгың: янаем, кил, янаем.

И Хода, бир акыл, тоткыннар йортына эләкмим;
Бу кызга гыйшкым сәбәпле, диванамын, диванамын.

...Ә менә ул хәзер «шагыйрьне дәвалыйм», дип, бәрелеп-сугылып йөрүе белән көлке бер хәлдә. «Кырымга барырга акча туплыйм», – дип, үзенең бөтен бизәнү әйберләрен, затлы энҗеле калфакларын сатып җибәрде. Аннан күреп, тагын берничә кыз үзләренең яраткан алка, беләзекләреннән ваз кичте. Шагыйрь бу хәлләрне белә калса, аны бүлмәсеннән куып ук чыгарган булыр иде. Өммегөлсемдә нинди гашыйк җан яшәвен күрергә теләми шул шагыйрь. Ә бер атна элек кенә аннан да бәхетлерәк кеше юк иде ләса. Көтмәгәндә-уйламаганда Тукайның Петербургка килүен үз күзләре белән күргәч, ул сөенеченнән нишләргә дә белмәгән иде. Кемнәрдә тукталасы иткән диген әле? Өммегөлсемнең җизнәсе, Петербург мулласы, танылган дин галиме Муса Бигиевларда!

Тукайны Петербургка чакырып язучы Муса әфәнде булганга, шагыйрь вокзалдан туры аларга килә. 1912 елның башында Петербургның бер төркем зыялылары Петербургта «Сүз» йә «Хәбәр» исемле газета чыгарырга җыеналар. Яңа газетага мөхәррир итеп Тукайны чакырып хат язалар. Әмма газета оешып китә алмый. Тукай яз башында Петербургка килеп төшкәндә бу мәсьәлә инде көн тәртибеннән алынган була. Тик менә алдан хәбәр итмәгәнгә, бераз уңайсызрак килеп чыга. Табигый ки, өйдә ыгы-зыгы куба. Кунакка Муса әфәнденең эш кабинетын бушатылар. Күн диванда урын җәелә. Юлда авырып киткәнме, аңа чаклы ук булгандырмы, Тукай туктаусыз ютәлли. Тамагына берни капмый. Өммегөлсем шагыйрьне иртәнге якта юыну бүлмәсенә кергәндә күреп хәйран кала. Кызның күзләрен, ирексездән, яшь пәрдәсе томалый. Гадәттән тышябык, яшүсмер кыяфәтле шагыйрь бу минутларда аңа бик якын һәм кызганыч булып тоела. Сөйләшәсе, юатасы иде үзен... Әмма Әсма апасы аны да, Өммегөлсемгә кодача тиешле Мәрьямне дә Тукай янына якын да җибәрми. Әсма ханымның әмере катгый: «Әдәпсезләнмәгез, шагыйрьгә комачаулап йөрисе түгел!» Апасының тыюлары гына туктата алса икән Өммегөлсемне? Ул инде шагыйрьнең игътибарын җәлеп итәрлек планнар кора, аны дәвалау юлларын эзләргә керешә. Әйтик, шагыйрь хәлләнү белән, ул аңа хәзрәти Пушкин йөргән урыннарны күрсәтәчәк. Тиздән мәшһүр җырчы Шаляпинның концерты көтелә. Ул да таң белән билетка чиратка басар... Дәресләрдән соң шундый матур хыялларга чумып, Бигиевларга барып керсә, ачык ишектән буш диванны күреп, Өммегөлсем өнсез кала.

– Кая ул?

– Кая?.. Баязитов* кешеләре килеп алып китте аны, – ди Әсма апасы. – Җизнәң кайтканны да көтәргә теләмәделәр. – Күренеп тора: апасының кәефе нык кырылган. – Юкка гына борынгылар: «Ит яхшылык, көт яманлык», – димәгәндер шул...

– Апа, ни сөйлисең? Нинди яманлык тагы? Тукай нык сырхау. Алар аны, мөгаен, докторга алып киткәннәрдер...

– Ә җизнәң ни белән шөгыльләнә? Өченче көн инде ниндидер яһүд профессоры артыннан йөгереп йөри. Менә ул хәзер профессор белән кайтып керсә, ни эшләрбез? Кунагыбыздан җилләр искән.

Җайсызрак килеп чыга икән шул. Җизнәсенең олуг кунагын аякка бастырыр өчен җанын бирердәй булып йөрүен Өммегөлсем күрмимени? Петербург татарлары арасында Муса әфәнде кебек укымышлы, итагатьле кешене табуы кыендыр. Шәһәрдәге татар студентлары өчен ул алыштыргысыз киңәшче, остаз. Аның мәхәлләсенә галимнең вәгазьләрен тыңлар өчен шәһәрнең иң ерак почмакларыннан җыелалар. Тукай, бәлки, аның ни дәрәҗәдәге гыйлем иясе булуын төшенеп җитмәгәндер? Юкса Муса әфәнде белән киңәшмичә бу эшне эшләмәс иде. Их, Гаяз абзыйның Петербургта чагы булса! Өч бөек затның очрашуы бөтенләй үзгә булыр иде бит. Әле берничә ай элек кенә Исхакый барында Петербург кайнап-гөрләп торды. Шәһәр чын татар тормышы белән яшәп алды. Язучының яңа язылган әсәрләрен бергәләшеп уку дисеңме, музыкаль кичәләр оештырумы... Төрмәдән качып, Петербургта яшеренеп йөрүче Гаяз Исхакыйны күптән түгел янә кулга алдылар. Төрмәдән ул Өммегөлсемгә хатлар язгалый. Петербург хәбәрләрен сораша.
Ай бу татар язмышлары! Ай бу ачы язмыш җилләре!..

* С. Баязитов. Петербург ахуны, «Нур» газетасының нәшире.

PRESSA.RU

Өммегөлсем, буш диванга утырып, үксеп-үксеп еларга тотынды. Нигә, нигә аның изге уй-ниятләре җимерелә дә тора? Нигә болай бу? Ул бит авыру шагыйрь өчен җанын фида кылырга да әзер. Аңа хәзер бер генә чара кала: «Нур» газетасы идарәсенә барып, Тукайның кайда тукталуын белешү. Аның ашыгып чыгып китәргә җыенуын күргәч, ахирәте Мәрьям аңа шагыйрь онытып калдырган портсигар белән чәч тарагын суза. Сизгер җан бу Мәрьям. Тукай янына бару өчен болар менә дигән сылтау ич.

Сылтау... Менә ул Тукай белән күрешеп, гарьлегеннән үләргә җитешеп, янә Бигиевларга кайтып бара. Мәрьям белән Әсма апасына ни әйтер икән инде ул хәзер? Тукай мине ишетергә теләмәде диярме? Ярый әле өйдәгеләр аның халәтен күреп, кирәкмәс сораулар белән аптыратмадылар.

– Тынычлан, иркә таем. Тәкъдиреңә язылмаган булса, әллә нишләсәң дә булмый. Чистайда Тукай турында: «Безнең Хәйдәр абзый кызы Зәйтүнәне сөя икән», – дигән сүзләр йөрде. Бер дә колагыңа чалынмадымыни?

– Зәйтүнә?? Зәйтүнә дисеңме, апа? Кайчан, кай арада өлгергән соң әле ул кызый Тукайның күңелен яуларга?

– Бик чая кыз, синең кебек укырга да омтылышы зур, дип сөйлиләр. Әле Әгерҗе якларына Бубыйлар мәктәбенә белем алырга киткән, ди.

Өммегөлсем өчен тагын да үтергечрәк хәбәр иде бу. Туганнан туган сеңлесе Зәйтүнәне ул яшүсмер кызга гына санап йөри иде. Ә ул әнә үсеп тә җиткән, Тукай тиклем шагыйрьне үзенә гашыйк та иткән. Сөйкемле җан шул Хәйдәр абзыйның төпчек кызы. Аның укырга һәвәслеген күреп, Өммегөлсем аңа әледән-әле китап-журналлар биргәли иде. Чамадан тыш ярлы яшәүләрен белгәнгә, кием-салымнан да өлеш чыгаргалый иде. Соңгы кайтуында алар туйганчы Камада су коендылар. Күр әле, Тукайны ник бер тапкыр телгә алсын! Нәрсә-нәрсә, тик мондый борылышны көтмәгән иде Өммегөлсем.

Икенче көнне ул Сенат мәйданына барыргамы-бармаскамы дип озак икеләнде. Мондый халәттә берәүгә дә күренәсе килми иде аның. Тик үзе башлаган эшне азагына җиткерергә өйрәнгән кыз ничек бармыйча калсын?

Туберкулёз белән интегүчеләргә ярдәм итәргә теләүчеләр күп була ул көнне. Тукайны да алып киләләр. Европача киенеп куйган шагыйрьне бүген танырлык та түгел. Үзен сырып алган студентларны ул тыныч кына тыңлый. Ара-тирә ютәлләп ала. Өммегөлсем ягына ялгыш кына да күз салмый. Аннан аны тагын каядыр алып китәләр. Тукай белән соңгы күрешү кыз өчен әнә шулай гадәттән тыш моңсу тәмамлана.

Берничә көннән Өммегөлсем Муса әфәнде Бигиевтан Тукайның Петербургтан китәргә җыенуы турында ишетә. Муса әфәнде шагыйрь тарафыннан үзенә карата күрсәтелгән илтифатсызлыкны онытып, Тукай янына барып, күрешеп йөри икән. Шагыйрьне озату мәҗлесендә дә катнаша. Әмма, ни сәбәпледер, аны озатырга вокзалга төшми кала. Дус кызлары ничаклы гына өндәп карасалар да, Өммегөлсем дә вокзалга бармаска була. Соңрак Невский урамында очратып, Тукайны Петербургтан Мәскәүгә чаклы озатып куйган журналист Кәбир Бәкер:

– Тукай үзен озатучылар арасында сине күрмәгәч, нәүмизләнеп калды. «Бик горур кыз булып чыкты сезнең Джокондагыз», диде, – ди аңа.

– Башка берни дә әйтмәдеме?

– Аның көннәре санаулы. Догада тор... Моны доктор да раслады.

– Ничек? Догада?.. Әйт, зинһар? Ходай хакы өчен әйт. Аны ничек табарга була?

– Син соңладың, Джоконда. Без барыбыз да соңладык...

Шушы сүзләре белән Кәбир Бәкер, кызны урам уртасында, йөзләгән кеше арасында япа-ялгызын калдырып, китеп тә бара. Мондый хәбәрдән соң ничек итеп институтка барып утырмак кирәк? Янәшәдә генә почта бинасы күреп, Өммегөлсем шунда керергә була. Тиз генә хәлне аңлатып, Фатих Әмирханга хат язып салыргадыр. Ул ни дә булса уйлап тапмый калмас. Тукта, нигә Фатих Әмирханга? Дөньяда саф чык тамчысыдай Зәйтүнә бар бит әле. Урасын үзенең кайнар мәхәббәте белән шагыйрь йөрәген. Бөтен барлыгын биләсен. Шагыйрь җанындагы барлык үпкә-рәнҗүләрне юып алсын! Тик Тукай гына исән була күрсен! Ак кәгазь битенә «Зәйтүнә, иркә таем» дигән сүзләрне язуга, Өммегөлсем күз яшьләрен тыя алмады. Юк, яза алмый икән ул бу хатны. Хатны ул иң якын сердәше – апасы Шәмсенисага юллый. Аңардан тиз арада Зәйтүнәне әзерләп, юлына һәм яшәренә акча биреп, Тукай янына Троицкига озатып җибәрүен үтенә. Шәмсенисаның җавабы озак көттерми. Ул Өммегөлсемгә Зәйтүнәне Чистайдан да, Казаннан да таба алмауларын хәбәр итә. Язмышның мәкерле уйнавымы соң бу? Сенат мәйданында Тукайны соңгы тапкыр күрүе идемени соң Өммегөлсемнең? Юк, юк, алай була алмый...

Гүя гыйшкың – бер чиркәү, ә мин – аның чаңымын;
Аһ-ваһ итеп, мин ул тавышны көчәйтергә тырышамын.

Безнең арабыз аерылышу пәрдәсе белән капланган;
И Аллаһ! Күтәр син бездән бу караңгы пәрдәне.

Шагыйрь шулай ачыргаланып язган. Өммегөлсем аларны шулай өзелеп-өзелеп кабатлый, Тукайча ялвара. Һәм «мәхәббәт сакчысы» бу юлы, язмышның йомшак җиле булып, Өммегөлсемнең матур коңгырт чәчләреннән иркәләп сыйпап кына үтәсе итә.

* * *

...Көннәрдән бер көнне бу караңгы пәрдә чынлап та күтәрелер. Мәңгелек сәфәргә җыенучы шагыйрь алдында ерак сәфәрләрдән зарыгып сагынып кайткан ак фәрештә пәйда булыр. Һәм...

Тик әлегә алда соңгы бәянга илтүче сынаулы озын юл һәм кул сузымы гына еламсак ел көтәр.

ХАТЫН-КЫЗГА БЕРЕНЧЕ БУЛЫП СИЗДЕРЕРГӘ ЯРЫЙМЫ ЯРАТУЫН, ӘЛЛӘ ЮКМЫ? «ИХ, ШУЛ ЧАКТА ХИСЛӘРЕМНЕ БЕЛГЕРТМӘДЕМ...» – ДИП, ГОМЕР БУЕ ҮКЕНҮГӘ КАРАГАНДА, КҮҢЕЛЕҢНЕ АЧУ ХӘЕРЛЕРӘКТЕР. КАЛГАНЫ – ЯЗМЫШ ЭШЕ...

Гөлназ ИСМӘГЫЙЛЕВА

СИН – МИНЕМ ЯЗЫМ

Гүзәл, ниһаять, бүген аның янына кереп барысын да турыдан-туры әйтергә булды. Күпме яшертен янарга була?!

Әмма әйтергә генә җиңел шул... Тик торганнан ничек итеп янына барып керер соң ул аның? «Тәрәзә гардины төшеп киткән иде, куеп бирә алмассызмы?» – дигән сәбәп белән керү түгел бит бу... Ул вакытта директор бүлмәсендә тәрәзә гардины төшкәч, Гүзәл, озак уйлап тормыйча, туп-туры аның янына йөгерде шул. Атылып килеп керде дә әйтер сүзен онытты... Аның үзенә төбәлгән карашы кызны әллә сихерләде, әллә күңел төбендә яшереп йөрткән хисләрен упкыннан «күтәрде». Җәйге аяз көннәрдә генә була торган ачык күк йөзе сыман зәп-зәңгәр күзләр тирәнлегендә югалып, бу карашларны мәңге оныта алмасын шул вакыт аңлады Гүзәл... Егетнең: «Бер-бер нәрсә булмагандыр бит?» – дигәненә айнып киткәндәй булды ул. «Азат Кадыйрович, директор бүлмәсендә...» – дип, өзек-өзек нидер әйтте дә, йөгереп китеп тә барды.

Гүзәл университетның көндезге бүлегендә укый. Мөстәкыйльлеккә омтылу теләге дә бар, гел-гел әти-әнисеннән акча сорыйсы килмәгәнгә күрә өченче курста укыганда эшкә урнашырга булды ул. Үзен укыткан укытучылар аны шәһәрнең бер татар мәктәбенә сәркатип итеп тәкъдим иттеләр.

Үзенә тапшырылган документларны барлаганда ук коллективта өйләнмәгән укытучы егет барлыгын белгән иде ул. Аны барысы да хөрмәт итүен, аралашканда еш искә алуларын да ишетте. Яшь укытучы кызларның, ул дип, гыйшык утында януларын да сизде. Озакламый үзенең дә шул кызларның берсе булачагын гына күз алдына китермәгән иде. Мәхәббәт алдан әйтеп килми шул... Егетне беренче күрүгә үк йөрәгендә бик


Фото: www.pixabay.com

җылы хисләр уянуын – мәхәббәт «бөреләре» ачылуын тойды. Хәтта егетнең үзеннән ун яшькә өлкәнрәк булуы да нигәдер куркытмады аны.

Гардинны кире үз урынына элеп куйган көннән соң, алар очраклы рәвештә гел ничектер очраша торган булып киттеләр. Уку елының өч чиреге ничек узганы тоелмады да. Егетнең үзенә карата булган хисләрен сизә дә кебек Гүзәл, шул ук вакытта араларында һаман да бернинди аңлашу булмаганга аптырый да иде. Шуңа күрә ул, беркөнне Азат Кадыйрович чираттагы документларын алырга кергәч, бөтен батырлыгын җыеп: «Минем сезгә әйтер сүзем бар. Керермен әле», – дип әйтеп куйган иде...

Бүген директор да иртәрәк кузгалды. Димәк, бар да җай килеп тора... Гүзәл, дөп-дөп типкән йөрәген тыярга тырышып, аның кабинеты янына килеп басты. Ишекне ачыйммы-ачмыйммы дигән халәте чиксез бер гомер кебек тоелды. Ә башында гел бер үк уй бөтерелде: «Йә Ходаем, беренче адымны үзем ясамакчы булам! Аңлармы ул мине?! «Сеңлем, син бигрәк җилбәзәксең. Тик минем йөрәгем буш түгел бит», – димәсме...»

Гүзәл нишләргә белми басып торганда, кинәт ишек ачылып китте. Ул үзе, әлбәттә... Бер мизгел эчендә Гүзәлнең күз аллары караңгыланып киткәндәй булды, телләре сүз әйтә алмас халәткә килде.

– Миңа кермәкче идеңме? Әйдә, Гүзәл, уз, – дип, үзе җитәкләп диярлек кабинетына алып кермәсә, кыз һаман кадаклагандай ишек төбендә басып торыр иде әле.

Юкка борчылган Гүзәл – алар арасында сөйләшү бик җиңел, күптәнге дуслар кебек килеп чыкты. Сүз арасында гына Азат: «Гүзәл, син бит миңа нидер әйтергә теләгән иде бугай?» – дип сорады. Гүзәл каушавын, оялуын онытып: «Азат Кадыйрович, әйдәгез, икәү бергәләп театрга барыйк, бу атнада премьера булачак анда...» – диде. Аннан соң ни булганын ул аңламый да калды – барысы да шундый тиз булды: Азат кинәт аны күтәреп алды да, әйләндерә башлады. «Гүзәл, син дә мине бүтән кызларга димләргә телисең дип уйлап йөри идем бит... Хисләремне белдерергә шуңа кыймадым да... Мин шундый бәхетле!» – дип пышылдады.

...Табигатьнең иң матур язгы көннәрендә Гүзәл белән Азат арасында уянган хисләр гомерлек булырга тиеш сыман иде.

Ул көнне театрдан кайткада Азат Гүзәлгә бер кочак сирень чәчәкләре бүләк итте. «Гүзәлем, син – минем язым. Мин сине ташламам!» – диде.

Гүзәл ул вакытта әлеге сүзләрне дистә ел буена – икенче берәүгә тормышка чыкканчы оныта алмаячагын башына да китермәде. (Мәхәббәттән башлар әйләнгәндә: «Тормыш – катлаулы, син дигәнчә генә бармый, юлларыбыз аерылырга да мөмкин», – дип уйлый-сыңмыни?!) Хәер, кияүгә чыккач та, язлар җитеп, сиреньнәр шаулап чәчәк ата башлагач, «Син – минем язым!» – дигән сүзләрне ишеткәндәй булып, тетрәнеп китүләре гомере буена озатасын белми иде әле ул...

PRESSA.RU

ЙОЛДЫЗЛАРГА ЙОЛДЫЗ АТЫЛГАНДА...



«Галия белән Заһир» җыры

(«Галия» спектакленнән)

Әнгам Атнабаев сүзләре
Рим Хәсәнов көе

Йолдызларга йолдыз атылганда,
Очрашканнар көннәр төн белән.
Бу дөньяны белгәнемнән алып,
Синең барлыгыңны мин беләм.

Кушымта:
Син кайда, мин шунда, Галиям,
(Заһирым),
Шатланам, елыймын һәм көләм.
Мәхәббәт алдында баш иям,
Син кайда, мин шунда, Галиям,
(Заһирым).

Йолдызларга йолдыз атылганда,
Йөрәгемә кунды ялкыны.
Бер ялкыны дөнья балкытырлык
Сөю булгандыр ул, ахыры.

Кушымта.

Йолдызларга йолдыз атылганда,
Гомерләре янып югала.
Ә мәхәббәт гомерләрдән озын,
Мәңге яна, мәңге җырлана.

Кушымта.

«Йолдызларга йолдыз атылганда...» Кем икән соң бу Галия белән Заһир? Гади җир кешеләре түгел һәрхәлдә. Йолдызлар таган атынып уйнаган мәхәббәт дөньясыннан алар. Әле дә шундадыр кебек. Галия белән Заһир. Нурия белән Фидан.

Бу ике шәхес башкорт театры сәхнәсендәге дәверне гәүдәләндерәләр. Әле узган елның декабрендә генә РСФСРның, Башкортстанның һәм Татарстанның халык артистлары Нурия Ирсаева белән Фидан Гафаров берсе – 80, икенчесе 70 яшьлек юбилейларын бәйрәм иттеләр.

– Нишләп «Галия» спектаклен кабатлап куймыйсыз? – дип, тамашачылар еш сорый.

– Аның өчен яшь Фидан белән яшь Нурия юк... – диләр режиссерлар.

Чыннан да, «Галия» спектаклендә бүтән артистларны күз алдына китерү, кабул итү кыенрак икән шул әле.

Нурия Ирсаева ул чорларны бүгенгедәй хәтерли:

– Рифкать Исрафилов Таһир Таһировның (Башкортстанда 60-70 нче елларда популяр язучы, озак еллар КПССның Башкортстан өлкә комитеты өченче секретаре буларак та танылган шәхес – *авт.)* «Галия» повестен радиоспектакль итеп әзерли башлагач, композитор Рим Хәсәнов Галия образы өчен җыр язды. «Галия» радиоспектакль буларак та берничә ел яшәде әле. Аны 9 Май – Җиңү көненә куялар иде. Халык бик яратты. Шуны күрептерме, Рифкать (ул чагында Гафури исемендәге Башкорт академия драма театрының баш режиссеры – *авт.*) «Галия»нең сәхнә вариантын эшләргә булды. Без дә бик теләп ризалаштык. Ул вакытта, узган гасырның 70 нче еллар ахырында халыкта романтик рух көчле иде, ә «Галия»дә нәкъ шундый романтик мәхәббәт тарихы бирелә.

Җырның көе башка иде әле ул вакытта. (Нурия Ирсаева җырлап күрсәтә. Матур көй булган анысы да. Кызганыч, журнал битләре аша тыңлату мөмкинлеге юк. – *авт.*) Иске көе гади иде, ул салмак кына агып, колакка ягылып бара иде.

...Репетицияләр башлана. Рим Хәсәновның әлеге Гафури театрында эшләгән чагы. Килгәләп йөри. Күңеле тыныч – көй язылган, эше беткән. Исрафиловның спектакльне көнкүреш диалогларыннан арындырып, көндәлек тормыштан өскәрәк күтәрергә тырышып йөргән көннәре. Күрәсең, бу шаукым композиторга да йога: ул аңа яңа көй яза.

«Тегесе дә матур бит, кирәкми», – ди артистлар. Ә менә яңа көйне ишеткәч...

– Ул безне Галәмгә алып менеп китте дә йолдызлар арасына чәчте. Анда бернинди көнкүреш авазы юк иде. Спектакль дә искиткеч килеп чыкты. Без дә башкача уйный башладык. Җыр спектакльдән легенда ясады.

Шуннан соң аны радиода яздыралар. (Элек җырларны радиода гына яздыралар иде бит. Ялгышсалар, өр-яңадан башлыйлар, хәзерге кебек туктаган җирдән башламыйлар. Төнге өчкә генә тәмамлыйлар.

– Шундый җырлар була: җырлыйҗырлый да, тыңлый-тыңлый да туясың. Ә менә монысы, күпме кабатланса да, биздермәде мине. Ике генә җыр бар ул шундый: берсе – «Галия белән Заһир» җыры, икенчесе – Фидан башкаруындагы «Кышкы романс». Икесе дә Рим Хәсәновныкылар. Ул безнең театрда дәртләнеп, рухланып эшләдә, бербер артлы шедеврлар тудырды. Бик күп спектакльләргә матур җырлар язды. Кызганыч, театрдан киткәч, ул андый ук кимәлдә эшләмәде инде...

Театр репертуарында «Галия» спектакленә кадәр дә җырлы спектакльләр бар иде. Әмма бу спектакль чыккач, бөтенесен каплады да куйды. Без кая гына гастрольләргә барсак та, Фидан белән Нурия теге җырын җырлар микән, дип сорыйлар иде. Спектакльне карар өчен авылдан авылга ияреп йөргән тамашачылар күп була иде.

«Миңа үз гомеремдә ике Галияне уйнарга туры килде. Берсе – Гадел Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар»ындагы Галия. Икенчесе – Таһир Таһировның «Галия» повесте буенча Рифкать Исрафилов куйган спектакльдә. Тамашачым мине шул ике образ аша аеруча яратты. Миңа әле дә Галия дип эндәшүчеләр бар», – дип яза Нурия Ирсаева үзенең 80 яшьлегенә чыккан буклетында. Галияне озын гомерле иткән яраткан артистыбыз бүген дә Мәҗит Гафури исемендәге Башкорт дәүләт академия драма театры сәхнәсендә йолдыз булып яна.

Ландыш ӘБҮДӘРОВА язып алды.
Казан–Уфа–Казан.

PRESSA.RU



БЕР ТАМЧЫ ЯРАТУ ДА ҖИТӘ...



Рита
СӘЛАХОВА

ДИМЧЕ, ЯУЧЫ РОЛЕН БАШКАРУЫБЫЗ ҺИЧ ТӘ ТАБИБЛЫК ВАЗЫЙФАСЫНА КЕРМИ, ӘЛБӘТТӘ. КЕМНӘР ӨЧЕНДЕР БУ ГАМӘЛЛӘР СӘЕР ДӘ, КӨЛКЕ ДӘ ТОЕЛЫР, БӘЛКИ. ЛӘКИН АВЫРУЛАРГА ШУЛАЙ ЯХШЫРАК БУЛАЧАК. БЕР ТАМЧЫ ЯРАТУ ДА ДАРУГА ТИҢ!

Алар исем-фамилия белән түгел, номерлар белән теркәлә. Һәрберсенең – үз тарихы, үз язмышы... Күп еллар дәвамында дәвалау, күзәтүләр нәтиҗәсендә күбесенең исемен, язмышын, холкын беләсең, кайсы белән ничек сөйләшергә икәнен... Кайберләрен – йомшак сүз белән җайлап була, икенче берләренә катырак та әйтергә туры килә. Эшкә барганда-кайтканда шуларның һәркайсын күз алдыннан үткәрәм. Язмышлары буенча мин аларны шартлы рәвештә берничә төркемгә бүлдем инде: наркоманнар, ирләреннән ВИЧ-инфекция йоктырган корбаннар, оптимистлар, гаепсездән гаеплеләр... Беренче тапкыр ничек безгә килүләре, бөтенесен яшермичә сөйләүләре истә... Үкенгән, тәүбә иткән, сынган-сыгылган чаклары, өметләнгән минутлары күз алдында... Һәрберсенең язмышы гыйбрәтле. Исемнәрен үзгәртеп, шул төрле төркемнәрдәге хатын-кызлар турында чын хикәят сөйлим әле. Язмыш хаталарын төзәтергә үзендә көч тапканнарына сөенәсең. Караңгы тоннель очында яктылык күренгәндәй була...

Алисә

Төскә-биткә чибәр, үз-үзенә ышанган бу ханымны якын итеп өлгердек инде без. Моннан 8-9 еллар элек килгән Алисә түгел инде ул хәзер. Исерек әтисеннән, өйдәге талаш, күз яшьләреннән туеп чыгып китеп, урам йогынтысына эләккән бу кызның авыру тарихы күпләрнекенә охшаган иде. Наркотиклар кулланудан С гепатиты һәм ВИЧ-инфекция эләктергән Алисәне хәзер танырлык түгел. Гади парикмахердан мастер дәрәҗәсенә күтәрелде, үз салонын ачты, машина, фатир сатып алды, кияүгә чыкты, бала тапты. Ялгышларын танып, үзендә ихтыяр көче табып, гепатитны җиңә алды ул. Бер ел буена дәваланды. Авыр дәва... Күпләр түзә алмый. Берара Алисә дә югалды, билгеләнгән көнендә күренми, хәбәре юк. «Нишләп килмисең?» – дип шалтыратам.

– Мин Мәскәүдә. Эш буенча киттем. Дәвалануны ташлармын, ахрысы. Авыр миңа, – ди.

– Юк, барыбер түзәргә кирәк. Син булдырасың! Син моны җиңәргә тиеш! – дип инандырам.

Алисәнең бала табасы килә иде.

– Башта гепатитны дәвалап бетерәбез, аннан инде бала табу турында уйлашабыз, – дим.

ВИЧ, гепатитлар белән ЭКОга алмыйлар бит. Дәвалап, дарулар эчеп, ВИЧ вирусының күпме күләмдә икәнен билгели торган анализ (ПЦР) күренмәслек дәрәҗәдә бик аз микъдарда булырга тиеш. Моңа ирештек! Гепатитны җиңде – ә бала һаман юк! Дүртбиш тапкыр ЭКОга барып карады. Бушлай программалар буенча да, түләп тә... Кабат-кабат ЭКОга барулар никадәр психологик стресс ясаганын үзе кичергән кеше генә аңлыйдыр... Берничек тә барып чыкмый: яралгы тормый, төшә. Алисә, барысына да кул селтәп, әле үрсәләнеп елый, әле күңеле кайтып, боегып кала. Тагын үҗәтләнеп тотына. Ә көз көне шатланып килде безгә: «Әйбәт гинеколог таптым, авырга узмауның сәбәпләре бөтенләй башка нәрсәдә икән», – ди.

Кичә Алисә шалтырата: «Минем гинеколог белән сөйләшегез әле», – дип, телефонын табибына тоттыра. «Гемоглобины түбән, сез билгеләгән дарулардан булырга мөмкинме?» – дип сорый гинеколог.

– Әлбәттә, шулардан. Аны башкасы белән дә алыштырып була инде. Анысын Алисә авырга узган очракта...

Сүземне әйтеп тә бетерә алмыйм:

– Алисә балага узды! 16 атналык авыры бар! – дип, сөенечле хәбәр җиткерә.

Шатлыктан кычкырып ук җибәрәм, күзгә яшьләр килә.

Ничек көттек бит без бу көнне! Менә бит, ихтыяр көче аңа наркоманияне дә, гепатитны да җиңәргә булышты, кияүгә дә чыкты, тиздән баласы да туачак!

Карап торуга мыштым гына күренгән ир-атның беренче анализлардан ук ВИЧ-инфекция йөрткәне ачыкланды!

Дилә

Безнең авырулар арасында наркоманнарның йә азып-тузып, читләр белән кәеф-сафа корып йөрүчеләрнең хатыннары шактый. Дилә дә шундыйлардан. Курчак кебек матур бу хатынга әллә нәрсә була: гемоглобины төшеп, хәле бетеп, табибларга йөри башлый. Анализ арты анализ, тикшеренү арты тикшеренү... ВИЧ-инфекциясе табылгач, стресс кичереп, шок хәлендә калып үкереп елаулары... Каян, ничек?! Кан салдырмаган, гинекологта булмаган, азып-тузып йөрмәгән... Бер сәбәп тә юк кебек! «Булуы мөмкин түгел! Ышанмыйм!» – дип, тагын-тагын анализлар биреп карады ул. Эпидемиологлар җитәкләп йөрде үзен. Ире турында сүз кузгаткач:

– Аның кебек тугры ир дөньяда юк! Читкә йөри торган түгел ул минем Халитем! – дип кырт кисте.

Алай да ирен дә анализлар тапшырырга алып килергә күндердек. Аңарда икенчел инфекция иде инде! Ерак юлларда шофер булып йөрүче Халит күптән инде башка хатыннар белән очраша торган булган. Хастаханәгә салдык. Ләкин иммунитеты төшеп беткән иде инде. Дәвалануга соң кереште. Аяк-куллары хәрәкәтләнмәс булып, кома хәлендә менингоэнцефалиттан үлеп китте. Ә Дилә һаман безгә дәваланырга йөри...

Надя

Минем пациентлар арасында бер гаилә бар. Озын җирән чәчле, яңа чыккан үлән төсле яшел күзле шат күңелле Надя һәм нәкъ чиләгенә күрә капкачы ире: үзе кебек үк шаян телле, ерык авызлы Саша.

Фото: www.pixabay

PRESSA.RU

Әйтерсең, алар авырмыйлар, әйтерсең, алар узып барышлый гына кергәннәр!

Бер алты еллап беләбез инде аларны. Ике ай саен килеп күренеп китәләр. Икесе дә ВИЧ-инфекцияле булып танышканнар. Башка шәһәрдә яшиләр. Бәлки, андагы танышларына күренәселәре, авыру икәнлекләрен сиздерәселәре килмидер? Шаулап-гөрләп, балаларын ияртеп килеп керәләр һәрчак. Берчак шулай иртүк, әле эшкә килеп кенә утыруга, болар килеп керде. Минем ярдәмчем, шәфкать туташы булып эшләүче Клара ханым Надяның озын затлы күлмәгенә, ясаткан чәчләренә, биек үкчәле туфлиләренә игътибар итеп:

– Надя, әллә театрга дип тә килдегезме? – дип сорап куйды.

– Юк, без сезнең янга бәйрәмгә килгән кебек киләбез! Иртән 4 тә үк юлга чыктык инде, – дип аңлата башлады Надябыз. – Балаларга Казанны да күрсәтәсе бар. Парк-аттракционнарда булып, «Әкият»кә барып, үзебезгә бәйрәм оештырып кайтырга дип килдек әле.

Кәефләре шәп, юктан да кызык табып, үз күңелләрен үзләре күтәреп йөри белгән бу гаиләне без «кояшлы кешеләр» дип йөртә башладык.

Шунысына игътибар иткәнем бар: безнең күп пациентлар үз бизнесларын уңышлы алып баралар, чит илләргә йөреп торалар, гаиләләре белән ерак сәяхәтләргә чыгалар, спорт белән актив шөгыльләнәләр. Әйтерсең, яшәүнең бөтен рәхәтен, ләззәтен татып калырга, тормышның кадерен белергә ашыгалар.

Миңа ВИЧ-инфекцияле егет белән танышсам яхшырак...

Мәрьям

Гаепсездән гаепле, инфекцияне очраклы рәвештә саксызлык аркасында йоктырган Мәрьям... Аһ, шул диңгезгә баргач, нигә дип кенә дус кызларын тыңлады ул! Беләгенә тату ясатып кайтмаган булса соң!.. Матур була, янәсе. Заманча, модалы була... Үзе дә бит матурлык дөньясыннан: дизайнер. Температуралап йөргәннән соң, битләрен кызыл таплар каплап алмаса, лимфа төеннәре зурайамаса, гади салкын тию генә дип, берни сизмәс иде. Инфекция бер ел дәвамында үзен белгертмичә яшәргә мөмкин бит... Берничек тә узмагач, аптыраган кыз анализлар тапшырып карый. Һәм аяз көнне яшен суккандай була: ВИЧ-пробасы уңай!

Беренче килүендә үк тыйнаклыгы, тәрбиялелеге белән яулады ул безне. Зәңгәр күзле, аксыл дулкын чәчле, спортчылар кебек зифа буйлы бу кызга ничек булышып була соң, ничек хәлен җиңеләйтергә? Вакытында анализларын тапшырып йөри, гел тикшерелеп тора. ВИЧ прогрессиясе күзәтелми. Бик төгәл, пунктуаль үзе.

Бер килүендә ул:

– Сезгә соравым бар иде... – диде дә, әйтергәме-әйтмәскәме дигәндәй, кыенсынып тукталып калды. Аннан, тәвәккәлләп, сөйләп китте. – Киңәшәсем килгән иде. Минем берәр егет белән танышып, гаиләле буласым килә. Әбием белән генә яшим. Ул гел битәрли. «Бигрәк оялчан син! Кияүгә дә чыгалмыйсың шуңа. Гел эш, эш дип кенә йөрисең», – ди. – Кыз кыенсынып миңа төбәлде. – ВИЧ позитивлы кеше белән танышсаң, уңайлырак булыр иде. Шундый егетләр юкмы? Сәламәт егетне алдыйсым килми...

Клара ханым белән бер-беребезгә карашып куйдык. Шәфкать туташының кызык бер ягы бар: пациентларның кайсы айда, нинди көндә туулары белән кызыксынып, йолдызнамәләр буенча тагын да тулырак ачмакчы була аларны. Яучылыкка да бик маһир: менә бу хатынга и туры да килер иде инде кичәге ыспай ир, дип куя. Ул да булмый, таныштыру юлларын да эзли башлый. Бу юлы да Мәрьямнән җәһәт кенә туган көнен сорап куйды. «25 гыйнвар» дигән җавапны ишеткәч: «Сукояр икәнсең, студентлар көнендә тугансың, әйбәт билге», – дип сөйләнә-сөйләнә, телефонын язып алды. «Менә дигән егет табабыз үзеңә», – ди.

Кыз саубуллашып чыгып китте, чираттагы авыру керде. Йә Хода! Зәңгәр күзле, аксыл чәчле, озын буйлы тыйнак бер егет! Мәрьямнең туганы диярсең! Клара белән бер-беребезгә карашып куйдык.

Дамир иде бу. Корпоратив бәйрәмнән соң егетләр белән саунага барганнар, массаж ясаучы кызлар интим хезмәтен дә күрсәткән үзләренә. Салган килеш вакытлы мавыгу, уен белән башланган берничә сәгать аянычлы тәмамланган. Егет бик борчыла, әти-әнисенә дә, дусларына да белгертәсе килми. Ә үзенең эчендә утлар яна.

– Дамир, син өйләнгәнме?

– Юк, – ди ул уңайсызланып.

– Кызың бармы соң?

Юк икәнен белгәч, тагын сораштырабыз:

– Танышырга теләр идеңме соң?

– Теләр идем дә бит. Кайда танышасың инде... – ди ул өметсезләнеп.

– Кара әле, син хәзер генә безнең кабинеттан чыккан кызга игътибар итмәдеңме? – дип төпченә Клара.

– Күтәрелеп карарга да оялдым... – ди егет.

Ул арада шәфкать туташым Дамирның йолдызнамәсен өйрәнә иде инде. Бизмән йолдызлыгында туганын кай арада белде дә, Сукоярныкы белән кай арада чагыштырды ул.

– Туры килә! – дип пышылдый. Дамирга телефон номеры язылган кәгазь суза.

– Бүген үк шалтырат! Без биргәнне әйтсәң, үзе дә аңлар Мәрьям, – дип озатабыз аны.

Атна-ун көн дә узмады, егет белән кыз икәүләп анализларының нәтиҗәләрен белергә килделәр. Шундый матурлар. Очрашып озак та йөрмәделәр – өйләнештеләр. Хәзер бергәләп бәби көтәбез!..



СИБГАТУЛЛИНА Миләүшә

Казан дәүләт университеты, Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты

Ире Илһам белән Кәрим һәм Хәким исемле ике малай үстерәләр.

Карьера: «Татарстан–Яңа гасыр» каналының әдәби-музыкаль тапшырулар берләшмәсе баш мөхәррире, «Оsta татар» проекты җитәкчесе. Филология фәннәре кандидаты.

Тормыш шигаре: «Әлхәмделиллаһ!»

https://www.facebook.com/suyumbike.zhurnaly

«Оsta татар»

Байтак еллар хыялланган эшем тормышка ашты. «Оsta татар» проектын башлап җибәрдем! Татар телендәге тележурналистика мәктәбе, ораторлык курслары, публика алдында чыгыш ясау осталыгы, аудиториядән курыкмау, фикереңне җиткерә алу һәм башка юнәлешләрне үз эченә ала. 20 ел телевидениедә эшләү вакытында бик оста, тәҗрибәле һөнәр ияләре белән очраштым. Күбесе ирешкән уңышлары, үз һөнәренең нечкәлекләре турында сөйли алмый, кыенсына. Кешегә ничек кирәклеген күрсәтеп, аңлатып биргәндә, югалып калулардан арынырга мөмкин. Моңа мастер-класслар, тренинглар аша ирешеп була. Алга таба онлайн укыту да күздә тотыла. Балалар өчен махсус дәресләр бар. Ниятләр зурдан!


Алинә илһамландырды!

Бу айларда татар җанлы кешеләрне бер вакыйга бик сөендерде, дип беләм: ул да булса XXIII Кышкы олимпия уеннарында татар кызы Алинә Заһитованың Россиягә беренче алтын медаль яулавы. Аның чыгышын караганда горурлык, шатлык хисләре кичереп утырдым. Яшьләрдә җиңүгә дәрт, көч бар, Ватан хакына дип тырышу бар – менә шунысы мөһим иде. Аннан, минем өйдә ирләр командасы бит: алар белән бергәләп хоккейчыларның җиңүен котеп алдык.


Иманлы җир – бәрәкәтле җир

Гарәп Әмирлекләрендә милләттәшебез Исмәгыйль Шәнгәрәевләрдә кунакта булып кайттык. Алар хатыны Мәрьям ханым белән 11 бала үстерә. Балалары татар, рус, гарәп, инглиз телендә аралаша, намаз укый.
Бу илдә һәрнәрсә сокландргыч. Анда, мәсәлән, төзелеш эшләре мәчеттән башлана. Иң элек мәчет салалар, аннан соң – юллар. Тыныч, иманлы, бәрәкәтле җир. Безгә дә күп нәрсәләргә өйрәнергә була алардан.



сөендерде



көендерде

сөендерде



көендерде

сөендерде



көендерде

Балаларга вакытлары калмый

Мәктәптә укый торган балалары булган әти-әниләр аларның укырга яратмавы, теләп укымавы белән очраша торгандыр. Бу мәгариф системасының җитешсезлегеннән, дип уйлыйм. Җәмәгать эшләре, электрон журналлар һәм башка мең төрле мәшәкать – укытучылар җилкәсендә. БДИ белән дә килешә алмыйм. Баланың логик фикерләвен, иҗади сәләтен юкка чыгару өчен уйлап табылган кебек. Чит илдә акылы зәгыйфь балалар өчен имтиханда уңайлырак булсын өчен кертелгән контроль системасы икән ул. Бездә шушыны куллана башлаганчы, әти-әниләрдән ризалык сорасыннар иде, ичмасам.


Алгамы, арткамы?

Улым 32 нче музыка уен кораллары мәктәбендә шөгыльләнә, курайда уйный. Алар күптән түгел хосписка концерт куярга бардылар. Менә шушы хосписларда авыру балалар, шулай ук әти-әниле булып та ятим калган балалар күп. «Манзара» тапшыруында «Игелек» рубрикасы бар. Шуның аша «Зәкят» хәйрия фонды белән эшлибез, бергәләп авыру, ятим балаларга булышырга тырышабыз. Атнага бер тапкыр җылы ризык ашамаган балалар да бар икән арабызда. Югыйсә заман алга бара, без яхшырак яшибез, дибез. Алга бару шулай була микәнни?

Бер җенесле гаилә буламы?

Дөньяның 24 илендә бер җенесле гаиләләрне законлы рәвештә теркәргә рөхсәт ителгән... Европада зәңгәрләр парадлары үткәрелә... Мондый хәлләрне минем зиһенем кабул итә алмый. Ислам динендә дә зур гөнаһ бит инде бу гамәлләр. Мондый гаиләләр тәрбиягә алган балалар кем булып үсә инде, йә? Миңа калса, бу илләрне Атлантида язмышы көтә.

PRESSA.RU



Тарих, тынлык, Таллин



Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

Аның таш юллы тар, тыныч урамнарында үзеннән-үзе тормыш мәгънәсе хакындагы уйларга чумасың. Барган җирдән туктап калып: «Бу җиргә мин нигә килдем?» – дигән сорауга җавап эзли башлыйсың... Әлбәттә, бу шәһәрдә кешеләр яши – каядыр баралар, кайталар... Әмма бернинди шау-шу юк! Кычкырып сөйләшмиләр дәме соң алар?! Каршыңа килгән һәрберсе ирен чите белән генә елмаеп узып китә... Ачык һавадагы музей дип тә атар идем мин Таллинны: бүгенге көннәргә кадәр сакланып калган борынгы биналарда урта гасыр рухы яши...

Балтыйк буе илләре табигате, борынгылыгы, үзенчәлекле халкы белән мине күптән үзенә тартып тора иде. Кызым йөргән «Казан» бию ансамбленең балалар студиясе укытучысы Нигина Әхмәдуллина: «Таллинга бию бәйгесенә барабыз», – диюгә, шунда ук балам белән бергә үзем дә барырга ризалаштым. Хыялларны бер чынбарлык итәргә бит инде!

Таллин Санкт-Петербургтан 400 чакрым чамасы. Бу юлны без бик тә уңайлы автобуста үттек. Шунысы кызык, япан кыр уртасыннан чикне чыгу белән Россия җирендә гомумән дә күренмәгән җил тегермәннәре санап бетергесез анда. Электр энергиясе ясыйлар! Ул тегермәннәрнең зурлыгына балалар гына түгел, мин дә шаккатып карап барам. «Бу иксез-чиксез кырларда эстоннар нәрсә үстерәләр?» – дигән соравыма, автобус йөртүчебез: «Үстермибез, алар буш тора», – диде. Минем аптыраганны күреп булса кирәк, горурлык белән өстәде: «Без бит Евросоюзда – аның кагыйдәләре буенча яшибез!» Кырларында нәрсә үстерәсен ил түгел, Европа союзы хәл итә, димәк... Шулай итеп, эстоннар авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнмиләр, ә башка дәүләтләр җитештергәнне сатып алып ашап яталар икән. Зур сәнәгать тармагы да булмаган бу дәүләттә эшсезлек хөкем сөрә. Тик моңа да әллә ни борчылмый кебек эстоннар. «Без – пенсионерлар дәүләте», – диде Таллин урамында йөргәндә бер эстон абзые. Яшьләр Швециягә барып эшли, диделәр. Ә анда барып кайту күрше авылга җилдереп кайту белән бер икән монда. Таллинга исә ял итәргә, алда язганымча, җан тынычлыгы табарга кайталар.

Казаннан соң Таллин әкияти шәһәр кебек тоелды миңа. Бер мең еллык тарихы булган башкалабыз да аның кебек тарихка төренеп утырырга тиеш кебек югыйсә... Таллинның әнә һәр почмагыннан, һәр кирпиче, һәр ташыннан урта гасыр тарихы рухы бөркелә кебек. Балтыйк буе дәүләтләренең барысындагы кебек, монда да бик күп борынгы биналар сакланып калган. Нәкъ менә сакланган – өр-яңадан торгызылмаган!

Таллин урамнары туристлар белән тулы. Алар урта гасырның кабатланмас рухын эзләп, тарих белән күзгә-күз очрашыр өчен монда киләдер кебек тоелды миңа.

Шәһәрнең тарихы XI гасырдан ук башлана. Ул вакытта аның исеме Колывань була, соңыннан Ревель дип йөртелә. Үз тарихында бик күп идарәчеләрне күрә: Дания, Швеция, Россия империясе, Советлар Союзы... Кызганыч, Бөек Ватан сугышы елларында тарихның күп өлеше, бомбалар астында калып, җимерелә.

Таллинның тарихи йөрәге Виру капкаларыннан башлана. Нәкъ шушы урыннан зур диварлар, бик күпсанлы манаралары булган Иске шәһәргә керәсең. Ул Таллинның иң борынгы урыны, төп тарихи мирасларының берсе. Аның эченә узу белән, кайсы гасырда яшәгәнеңне онытасың. Тар урамнарда йөреп торучы машиналар гына сине чынбарлыкка кайтара... Иске шәһәрдә урнашкан Изге Олаф чиркәве – шәһәрнең төп горурлыгы. Каланың иң биек манарасы ул! Таллинда бүгенге көнгә кадәр язылмаган канунны саклыйлар: шәһәрдә төзеләчәк башка биналар 154 метрлы шушы чиркәүдән биегрәк булмаска тиеш. Чиркәү төзелеше белән бәйле төрле риваятьләр дә тарихка серлелек өсти. Менә аларның берсе.

...Бер бай шәһәрдә гыйбадәтханә салдырырга уйлый. Нәкъ шул вакытта калага кайсыдыр яктан бер оста килә һәм бу эшкә алынырга ризалыгын бирә. Төзелеш барышында минем кем икәнне белә алмасагыз, күпме акча сорыйм, шуның кадәр бирерсез, дигән шарт куя. Бай риза була, тик төзелеш тәгәлләнер алдыннан остага бирәсе байлыгын кызгана башлый: тирә-якка шымчыларын җибәрә. «Останың кем икәнен белмичә кайтмагыз», – ди. Шымчыларның берсе бер авылдан узып барганда баласын йоклаткан ананың җырын ишетә. «Әтиегез Олаф чиркәү төзи, тиздән кайтыр», – дип җырлый әни кеше. Шымчы шәһәргә кайткан вакытта останың, чиркәүнең иң очына менеп, тәре куйган мәле була. Шымчы: «Олаф, бераз кыеграк бит!» – дип кычкыра. Оста моны ишетеп сискәнә һәм... егылып төшеп вафат була. Бай исә үзенең бу гамәле өчен бик ояла һәм Аллаһ йортына останың исемен бирә.

Иске шәһәр ике өлештән тора. Берсендә һөнәрчеләр һәм сәүдәгәрләр яшәгән, икенчесе калкулыкта урнашкан, һәм ул урын һәрвакыт хакимиятнеке булган. Хәзер анда



Изге Олаф чиркәве. Готика архитектурасы үрнәге – күккә кадалып торган шпильле бу бина Таллинда гына түгел, хәтта бер-ара дөньяда да иң биеге булып санала.

Эстония парламенты урнашкан. Шәһәрнең ике өлешен ике яктан ике урам бәйли. Аның берсе – «кыска аяк», икенчесе «озын аяк» дип йөртелә. Шуңа күрә Таллинны, кызык итеп, «аксак шәһәр» дип тә атап йөртәләр.

Тыныч, шул ук вакытта нindидер әкияти серлелеге булган шәһәр ул Таллин.

Иске шәһәрнең тагын бер мирасы – Юан Маргарита башнясы. Ә риваяте болайрак. Марго атлы балыкчы кызы белән Герман исемле крестьян егете яратышалар. Тик яшьләр төнге сәгать 12 сукканчы гына күрешә алганнар. Ә бер очрашуда гашыйклар, вакыт хакында онытып, өйләренә кайтырга соңга калалар һәм шәһәрнең капма-каршы ягында торган ике манарага әйләнәләр...

Ратуша мәйданы Иске шәһәрнең йөрәге дип санала. Без Таллинга Раштуа алдыннан бардык. «Мәйдандагы серлелек ике тапкырга арткан вакыт», – диде эстоннар. Таллиндагы иң биек чыршы да монда куелган икән. Ул төрле утлар белән балкый. Шул утлар яктысына күмелгән мәйданда Раштуа ярминкәсе гөрли... Европа шәһәрләрендә бу вакытта

Фото: автор

PRESSA.RU



Ратуша мәйданында Европадагы иң борынгы даруханә эшли. Ул 1422 елда ачылган.




Юан Маргарита башнясы. Ул чынлап та «юан» – диаметры 25 метр.

Борынгы йортлар, чирәп түбәләр, таш түшәлгән юллар – барысы да сагындырыр, мөгаен.

ярминкәләр үткәрелүен беләбез инде. Мин дә Таллинда әнә шул ярминкәләрнең берсен күрү бәхетенә ирештем. Мәйдан – эстоннарның милли эчемлеге «Вана Таллин» ликеры кушылып ясалган глинтвейн һәм кыздырылган чикләвек исенә төренгән. Ул ис, ярминкәгә кайчан килүгә карамастан, борынны кытыклап тора... Инде сәүдә рәтләре турында. Йоннан эшләнгән ниләр генә сатмыйлар монда: милли бизәкләр төшерелгән бияләй, койрыклы башлыклар, җылы кофталар, йоннан әвәләп ясалган курчаклар... Барысы да шундый матур! Хәер, бәяләре дә... «Бу бары тик туристлар өчен генә эшләгән сәүдә рәтләре, шуңа күрә кыйммәт, – дип аңлатты безгә андагы танышларыбыз. – Иске шәһәрне чыгып берничә квартал узуга, шушы ук әйберләрне ике-өч тапкыр очсызракка да алырга була». Тик тәмле алданудан безнең бер дә чыгасы килмәде шул. Ничек чыгасың – урам тамашасы үзенә бөтерде дә алды!

Европадагы иң борынгы даруханә дә – шушында. Аның бер почмагында бүген музей оештырылган. Нәрсә генә юк анда: елан кабыгы, бака боты, кыздырылган керпе, карлыгач оясы... Гомумән, кешелек дөньясы аспирин уйлап тапканчы нәрсә белән дәваланса, шулар. Шунда ук хәзерге заманда эшләгән дарулар да сатыла. Нәкъ әлеге даруханәдә дару буларак марципан ясалган. Хәзер исә ул, белгәнебезчә, тәм-том итеп кулланыла. Миндаль оны белән шикәр кайнатмасыннан ясалган әлеге шоколадның Таллинда музее да бар. Камырга охшаган бу тәмлүшкәдән төрле фигуралар ясап, аны буяп, чын сәнгать әсәре тудыралар. Балалар да бик яратты ул музейны. Кулларын ялый-ялый бик озак үз әсәрләрен иҗат иттеләр. Ратушада тагын бер күзгә ташланган борынгы бина – Изге Рух чиркәве. Башка гыйбадәтханәләр белән чагыштырганда, ул бик кечкенә һәм үтә дә гади. Стенага уеп ясалган борынгы сәгать кенә аңа ниндидер бер кыйммәт өсти. Таллиндагы иң борынгы урам сәгате ул! Төркемнән аерылып, йөгереп кенә лютераннарның шушы гыйбадәтханәсе эченә кереп киттем. Ниятем – гыйбадәт кылу өчен куелган эскәмияләргә утырып карау иде. Чит ил киноларында гел шуларны күрсәтәләр бит. Чиркәү эче бик тыйнак – лютераннарда иконалар юк. Утырып, Ходай белән сөйләшү өчен эскәмияләр рәте генә тезелгән. Тик уем барып чыкмады. Ишек төбендә утырган дин әһеле: «Эчкәрәк үтү 2 евро тора», – дип кисәтте. «Аллаһ йорты түләүле буламыни?» – дип сорадым, аптырап. «Сез Россиядәндер, анда гыйбадәтханәләргә дәүләт ярдәм итә, ә без бары тик халыктан җыелган хәергә генә яшибез», – дип җавап бирде ул. Эстоннар үз дәүләтләрен дөньяви дип атый. Алар артык дини түгел. Халкының

Нәрсә алып кайтырга



Эстониянең сыйфатлы йон әйберләренең даны, әйткәнемчә, совет чорыннан ук билгеле. Йоннан нәрсә генә бәйләми алар?! Милли орнаментлар төшерелгән кофталар, бияләй, перчатка-оекбашлар, пальто, пончо... Һәркем кесәсенә карап сайлый. Туристлар күбрәк озын «койрыклы» бизәкле башлыклар ала – «койрыгын» шарф урынына муенга урарга мөмкин. Бәясе 20 евродан башлана. Эстониягә барып, ничек шоколадсыз кайтасың?! Бер плитка Kalev шоколады 1 евро тора: тәме безнең кибет киштәсендәгедән күпкә аерыла. Артыш агачыннан ясалган әйберләр бик популяр. Май кисү өчен хуш исле кечкенә агач пычаклар матур сувенир да, көнкүрештә дә файдалы. Кыйммәтрәк бүләкләр алырга телисез икән – гәрәбә кибетләренә барыгыз. Андагы гәрәбәнең күплеген, матурлыгын күреп, кибеткә нигә кергәнеңне онытасың... Иң гади бизәнү әйберләренең бәясе 30 евродан башлана.


Фото: www.pixabay.com

14 проценты гына тормышларында дин мөһим роль уйный, дип саный.

Иске шәһәрдәге борынгы биналарда кешеләр тыныч кына яшәп ята – гадәти тормыш алып бара. Тик андагы өйләр хәзерге заманда төзелгәннәрдән аерыла. Борынгы биналарның икенче катында кечкенә ишекләр бар, алар барысы да ябык – күз иң элек шуларга төшә. Нинди ишекләр икән соң бу? Бик озак эзләдек табышмакка җавапны. Ә ул гап-гади булып чыкты. Таллин – Балтыйк диңгезе ярында утыра, шуңа күрә гомер-гомергә порт шәһәре булган. Ганза союзы вакытында якын-тирәдәге бөтен товар Таллинга китерелгән. Ул әйберләрне саклау өчен складларны өй түбәләре өстендә төзегәннәр. Шул рәвешле малны дымнан һәм тычканнардан качырганнар. Еллар үтеп, шәһәрдә сәүдә кимегәч, әлеге складларның кирәге калмаган – алар бикләп куелган. Иске шәһәр бик кечкенә – аркылыга-буйга бер чакрымдыр, мөгаен. Тик ул тар тыкрыкларны ничә кат урасам да, үзем өчен тарихның, архитектураның яңа якларын ачтым. Таллинга тагын бер кат юлым төшсә, әлеге тыкрыкларга, һичшиксез, кабат барып чыгар идем. Минем күзгә чалынмаган тарих калгандыр әле анда!

Таллинны мегаполис дип әйтеп булмый. Кечкенә генә Европа шәһәре ул, халкы бары тик 500 мең генә. Трамвай, троллейбус йөри, метро юк. Җәмәгать транспорты бушлай булган бердәнбер шәһәрдер дә әле ул. Дөрес, бездәге кебек монда да транспортны озаграк көтәсе. Ә менә юлларда бөке бөтенләй юк. Чөнки халык ашыкмый, чапмый – тормышның тәмен белеп, тыныч кына яши. Гомумән, эстоннар ашыгырга яратмый, артык сүз сөйләмиләр, бик ачылмыйлар да. Алар белән чынлап торып дуслашсаң, гомерлеккәдер диган фикергә килдем. Бар нәрсәне уйлап, санап эшлиләр бугай: сүзне дә, гамәлне дә.

Таллинга киткәнче: «Сак булыгыз, эстоннар безне яратмый, гомумән, анда русча сөйләшергә тырышмагыз», – дип кисәтүчеләр булды. Нидер сорарга кирәк булганда, юлны тапмаганда русча да мөрәҗәгать иттек – җавап бирмичә китеп баручы очрамады: белсәләр, тиз арада аңлатып бирәләр. Русча аңламасалар – немецчага, аны да аңламыйм дип җилкә сикертсәләр – инглиз теленә күчтек. Таллинда яшәүче руслар исә үзләрен бераз кимсетелгән итеп тоя кебек. «Безне яратмыйлар монда», – диде автобуста сөйләшеп киткән урыс агае. Эстон телен белгәннәр генә җүнле эшкә эләгә ала, эш юк монда, дип тә зарланды. «Нигә Россиягә кайтмыйсыз соң алайса?» – дип сорагач, «Монда өйрәнгән җир, кайтмыйм», – дип кырт кисте үзе.

Мәчете дә булмаган Таллинда хәләл ризык табу бик авыр.

Без Татарстаннан дип, горурланып йөрдек Таллинда. Беләләр безне! Бер эстон хәтта: «Татарстан бит Россиянең Дубае!» – диде. Дубай кебек бай булмаса да, ыгы-зыгысы белән аннан калышмаган Казаныбыз сагындырды үзе. Шулай да, тормыш мәшәкатьләреннән алҗыган вакытларда, ял көннәрен анда үткәрергә тагын барыр идем мин Таллинга. Борынгы калада үзең өчен нинди дә булса яңалык ачарга, дөнья куудан туктап, тын алырга, тар урамнары буйлап узганда күңелдәге сорауларга җавап табарга һәм кабат яшьнәп яшәргә кире Казанга кайтыр өчен булса да...

P. S. Безнең төп максатыбыз – Эстониягә барып сәяхәт итүдән бигрәк, Татарстанны таныту иде бит. Кызларыбыз булдырды! Таллин сәхнәсендә ут яндырып биеп, халыкара бәйгедә беренче һәм икенче урынны алдылар. Безнең балалар өчен җан атарга килгән түбәтәйле-калфаклы Эстония татарларына аерым рәхмәт!

Аш-су


Фото: www.vinegrette.ru

Эстоннарның милли аш-сулары ит, балык һәм яшелчәдән тора – ул гади һәм туклыклы. Итне алар бик сирәк кыздырып ашый, күбрәк шулпада пешерәләр – димәк, дөрес туклананалар. Балык белән дуңгыз итенә, кара ипигә өстенлек бирәләр. Бәйрәм өстәленә канлы колбаса, тутырылган йомырка куялар: иң популяр ризыклары шушы. Сөтле аш яраталар – аның 20 ләп төре бар, диделәр. Хәтта десертка да баллы аш чыгаралар. Сөт ризыкларын, боткаларны да үз итәләр. Милли ризыкларының берсе – Картулипорс. Исеме авыр булса да, үзе бик гади: бәрәңге боламыгына төреп пешерелгән ит.

PRESSA.RU

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!

Минем туган авылым – Татарстанның Лаеш районындагы Татар Сараланы. Авылымның исемен кеше аңламаслык сүзләргә, тарихи фактларга нигезләнергә тырышып аңлатырга теләмим. Исеме бары тик табигатькә генә бәйләнгән, минемчә.

Сары алан... Шулай дигәч тә, сап-сары чәчәкле алан күз алдына килә. Бездән 40–50 чакрымда гына урнашкан Имәнкискә авылының IV–VIII гасырлардагы яшәеше тарихка «Имәнкискә культурасы» исеме белән кереп калган. Мин үзебезнең авылны да шушы культурага карый дип уйлыйм. Бер тирәдә яшәгән авыллар арасында әллә ни аермалыклар булмагандыр. Кем белә, бәлки, Пугачев явы да безнең авыл аша үткәндер. Урманыбыздагы казылган траншея эзләре, 60 нчы елларда Златоустта эшләнгән кылыч табылуы да шуңа ишарәдер. Авыл халкы Кан елгасын изге урын санаган. Имеш, монда канлы сугыш булган, елга тулып кан аккан.

XVII гасырларда авыл исеменә «Татар» сүзе килеп кушыла. Шушы чорларда авыл зиратыннан берәр чакрым ераклыкка гына бер төркем урыслар килеп урнаша. Торабара алар авылын Рус Сараланы дип атыйлар. Әмма алар үзләрен вакытлыча килгән кебек кенә тота, хәтта зиратлары да булмый. Әле дә Рус Сараланы кешеләрен ун чакрымдагы Рождествено авылы зиратына җирлиләр.

Совет чорында ике авыл бер колхозга берләшеп яшәде. Рус Сараланы кешеләре татарларны яшелчә үстерергә өйрәтте. Үзләре тимер эшенә бик һәвәсләр иде.

XX гасыр башында авылыбызда дөньяви мәктәп-мәдрәсә ачыла. Тора-бара ул районыбыздагы бердәнбер татар мәктәбенә әйләнә. Авылда беренче радио да шушында эшли башлый. Аны Шамил Усманов үзе сынап карый. Мәктәпне тәмамлаган 500 ләп кеше укытучы һөнәрен сайлый.

1928 елда авылда больница ачыла. Беренче көннән алып, сугышка кадәр монда ирле-хатынлы Шароновлар табиб булып эшли. Шаронов сугыштан яраланып кайтканнан соң да Саралан белән элемтәләрен өзмәде. Авылдашыбыз Әхмәтҗанова Зәйтүнә дә медицина техникумын тәмамлап, гомере буе авылдашларга ярдәм итте.

1931 елда авылда китапханә эшли башлый. Халык аны избач дип йөртә. Совет хөкүмәтенең халыкны укырга-язарга өйрәтү программасы тулысы белән укытучылар һәм китапханәләргә йөкләнә. Пионерлар, өйләргә йөреп, кычкырып китап укыйлар.

Безнең авылдагы «Яңалан» колхозын утызынчы еллар башында Шәйдуллин Габдулла төзи. Авылдагы беренче тракторист Заһир исемле кеше була. Сугышка алынганчы, Гали дигән кеше дә эшләп ала. Аннары тагын ике егетне укыталар: Кәли Зиннәте белән Пырак Мифтахы тракторист таныклыгы алып кайталар, әмма аларга озак эшләргә туры килми, икесе дә сугышта ятып кала. Абыйларының эшен беркайда да укымаган, тракторны үзлегеннән өйрәнгән яшүсмерләр дәвам итә. Шуларның берсе Хәмәтвәли Минвәлиев 70 нче елларга кадәр тракторда эшли. Авыл халкы бүген дә сагынып искә ала аны.

Бөек Ватан сугышына Татар Сараланы 500 ир-егетен озата. 1941 елның август аенда әтием Гыймадиев Сәлахны дә сугышка чакырып повестка килә. Хәтта вакыты да күрсәтелгән: 3 августта, сәгать унда Лаеш военкоматында булырга, диелгән. Иртәдән өйдә ыгы-зыгы башлана, әни әтигә юлга ризык әзерли, Мәликә әби сыер саварга чыгып китә. Сыер сауганда аны паралич суга. Ике сәгать кенә ятып, әби җан бирә. Әти авыл советына барып, китүне бераз кичектерергә үтенә. Әмма моны рәис кенә хәл итә алмый, чоры кырыс – бер минут соңарсаң, дезертир булачаксың. Шулай да военкоматтан сәгать өчкә кадәр рөхсәт алына. Әти шул вакыт эчендә әнисен җирләп, елый-елый сугышка чыгып китә. Шул китүеннән 1944 елның язында гына – гарипләнеп кайта. Ә аңынчы, үзәкләрне өзеп, аның үлүе турында ике тапкыр «кара пичәтле» хат килә. Әтинең кайтканын Галия апа болай хәтерли: «Әни, безне уятып, әти кайтканын әйтте. Әти безгә берәр шакмак шикәр бирде. Мин шул шикәрне учыма кысып, йоклап киткәнмен».

Сугыш яралары әтине гомер буе озатып йөрде. Башындагы снаряд кыйпылчыгы эзе дә, бер кулының юньләп хәрәкәтләнмәве дә, үпкәсен тишеп узган пуля да үзен сиздерде. Күз алдыма сулыш җитмәүдән тыны кысылып, авыр сулыш алып килеп баса ул. Гомеренең соңгы елын урманчылыкка багышлады. Авылны чорнап алган урманнарда аның өлеше зур.

Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар өчен куелган һәйкәлдә 220 авылдашыбызның исеме уелган.

Авылдашларым арасында сугыш елъязмасына исемнәрен онытылмаслык итеп язып калдырганнары да бар. Кыямов Гарәф абый – II һәм III дәрәҗәдә Дан орденнары кавалеры.

Сугыштан соңгы яралары да төзәлеп бетмәгән авылларга тагын бер фаҗига яный – Куйбышев сусаклагычы төзелү. Безнең авыл өч чакрымдагы тау башына – комлы һәм сусыз урынга 1953 елда күчеп бетәргә тиеш була. Иске йортларда кечкенә балалары белән тол калган ятим хатыннарга ул күченүнең нинди фаҗига икәнен күзаллыйсызмы? Ул йортларны сүтеп, кабаттан яңа җиргә күчереп салу өчен авылда атлар да юк, ирләр дә... Болар кабат шул хатын-кызлар белән яшүсмер балалар һәм... сыерлар өстендә булды.

...Ә авылның бер генә урамын да су басмады... Күченергә кирәк булды микән?! Яңа авылда дүрт урам булып, үзәк урамда төрле идарәләр урнашты. Клуб өчен мәчетне сүтеп алып килделәр, китапханә дә шунда сыйды.

Шушы күченү аркасында авыл ничә гасырлык тарихын, никадәр гаиләсен югалтты. Кешеләр үз урамнары белән күчәргә теләде, әмма алай ярамый, һәркемгә йорт урыны билгеләнгән, диделәр. Гомер буе туганнар кебек яшәгән күршеләр бер-берсеннән аерылды. Сугыш кына түгел, әнә шундый күченүләр дә күп афәт китерде милләтебезгә.

Нәҗия ГЫЙМАДИЕВА.
Казан шәһәре.

Анам язмышы мине һәрчак уйландыра, тетрәндерә.

Әнием Фазлыева Әдисә Хәсән кызы (кыз фамилиясе Гилимшина) 1928 елның 25 маенда Башкортстанның Балтач районы, Каргалы авылында туа.

Зурәтәй – революционер, зуринәй баерак катлам кешесе, укымышлы хатын була. Шуңа күрә кайчак икесе ике яклы булып, бәхәсләшеп тә китәләр. Зуринәй белән зурәтәйнең өч кызлары туа: 1925 елгы Рәмзия апа, аннары әнкәй, 1931 елда Әлфия апа. Зуринәй бик уңган, җитез хатын була. 1932 елны кисәк кенә чирләп үлә. Кызларның олысына – 5, әнкәйгә – 3, ә иң кечесенә 1 генә яшь була. Ачлык заманы, зурәтәй революция эше белән мәшгуль. 1934 елны зурәтәйгә беркайчан да кияүгә чыкмаган үги зуринәйне димлиләр. Аларның үзләренең биш балалары туа. Бик авыр еллар, халык ачлыктан шешенә, барган җирдән егылып үлүчеләр дә була.

Үги зуринәй өч ятимне үз итми, читкә тибәрә. Үзенекеләрдән калса гына ашата, юк өчен дә битәрли. Өч бертуган белем дә ала алмыйлар. Олысы җиде ел укыса, әнкәй белән сеңлесе нибары дүрт кенә класс укыйлар. Мичкә ягарга дип, урманнан җилкәләренә күтәреп, зурәтәй белән чыбык-чабык ташыйлар.

Сугыш башлангач, тормыш тагын да кыенлаша. Суыктан, ачлыктан әнинең организмы тәмам какшап, үлекле шешләр чыга. Бәхетенә, шешләр тишелеп ага, шулай котылып кала.

Җиденче классны тәмамлаганнан соң, Рәмзия апаны 15 яшендә колхозга үлчәүче-бухгалтер итеп алалар. Хезмәт көненә һәр кешегә кашыклап он бүләләр. Халык басуда нинди үлән үсә, барысын да ябырылып ашый, дип сөйли иде әнкәй. 12 яшендә үз күзләре белән күргән бер вакыйганы сөйли ул: «Тучыбай юлында бер яшь хатын үлеп ята, аның янында чүпрәккә төрелгән яшь баласы, елап, әнисенең күкрәгеннән эзли».

14 яшендә әнкәй, үзенә ике яшь өстәтеп, кызлар белән Свердловск өлкәсенә торф чыгарырга китә. Товар вагоннарында килеп, Сарга станциясендә иске баракларда яши башлыйлар. Көненә 300 грамм ипи бирәләр. Ачтан үлмәс өчен, төнлә басуга чыгып, өшегән бәрәңге эзлиләр. Эш хакы түләү дигән әйбер булмаган. Әни монда сигез ел эшли. Аннары Свердловск шәһәренә асфальт заводына урнаша. Монда инде бераз акча бирсәләр дә, үзе киенмичә, ашамыйча җыеп барып, елга бер кунакка кайтканда өйдәгеләргә ситсы, чәй, шикәр алып кайта.

1953 елда, ялга кайткач, зурәтәй аны сугышта бер аягын өздергән күрше авыл егетенә димли. Бу егет – минем әткәй – аннан 9 яшькә олырак була. Алар алты бала табып үстерделәр. Икесе дә көн-төн колхозда эшләде, 1986 елда шәһәрдә йорт урыны алып, үз өебезне салып чыктык. Үз йортыбыз әзер булганчы, кеше өстендә яшәдек әле. Авылдагы өйне саткан акчага бер иске генә йорт алып, бер малайга аны корып бирделәр. Газизләрем авылда да бүрәнәнең ике башыннан күтәреп, икесе бер өй салганнар иде инде. Монда да тормышлары җайлы гына бармады, бер туганыбыз кияүгә бармый гына бала тапты. Аны үзләренең җиденче кызлары итеп үстерделәр.

Әткәй мәрхүм инде. Әнкәйне үзләре үстергән шул сеңлебез тәрбияли. Аның янында акылга зәгыйфь 64 яшьлек ир туганыбыз да бар әле. Аны әни туганнан бирле үзеннән калдырмады. Мин әнинең сабырлыгына торып-торып шаклар катам. Нинди генә авырлыклар күрсә дә, күңеле катмаган, сынмаган-сыгылмаган. Мин аның беркайчан да хәзерге кешеләр кебек күп итеп ашаганын күрмәдем. Тамагына бик чамалап кына ашады. Быел әнкәйгә 90 яшь тула. Без аны бик яратабыз, аның алдында баш иябез. Алда гомерләре булса иде, дип телибез.

Лилия ФАЗЛЫЕВА.
Свердловск өлкәсе,
Югары Пышма шәһәре.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз. Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2. e-mail: ssuum@yandex.ru

PRESSA.RU



ИКЕГЕЗ ГЕНӘ БЕЛЕГЕЗ

Без шундый төрле: бу четерекле темалар турында якыннарыбыз, дус кызларыбыз белән кайберләребез сөйләшә, уртаклаша, сорауларына җавап таба ала. Ә кемдер ояла, тартына, кыенсына... Сәламәтлеккә бәйле булганда, үзеңне борчыган сорауларны эчеңә җыеп йөрергә һич ярамый. Менә шуның өчен дә журнал битләрендә бу әңгәмәне башларга уйладык та. Болар хакында без – хатын-кызлар өчен чыга торган «Сөембикә» журналы да язмаса, сөйләмәсә, кем язар, кем сөйләр?! Четерекле сорауларыбызга медицина фәннәре докторы, профессор, Казан дәүләт медицина университетының медицина психологиясе кафедрасы мөдире Владимир Давыдович МЕНДЕЛЕВИЧ җавап бирә.

? Үзеңдә җенси проблемалар барлыгын ничек ачыкларга? Кайсы очракларда табибка мөрәҗәгать итәсе?

Теләсә кайсы көйсезлек ул – сине нәрсәдер борчый, рәхәт кенә яшәргә комачаулый, кайдадыр авырта яки нидер күңелгә авырлык китерә дигән сүз. Җенси көйсезлек тә шулай. Еш кына кешенең башта бар да яхшы була, җенси мөнәсәбәтләр аңа рәхәтлек һәм канәгатьлек бирә. Ә көннәрдән бер көнне ниндидер проблемалар башлана. Әмма фригидлык, ягъни җенси салкынлык очрагы – аерым мәсьәлә.

Табибка кайчан мөрәҗәгать итәргә соң? Моны һәркем үзе өчен үзе хәл итә. Алай да җенси тормыш – ул ир белән хатынның уртак дөньясы. Берәүдәге көйсезлек икенчесенең дә тормышына күңелсезлек китерә.

? Ир-атларда һәм хатын-кызларда бу көйсезлек ничегрәк чагыла?

Ир-егетләрнең күп очракта шәһвәте кими (импотенция). Тагын бер проблема белән еш мөрәҗәгать итәләр – мәнинең тиз бүленеп чыгуы (вакытсыз эякуляция). Хатын-кызлар исә җенси мөнәсәбәтләрдән канәгатьсез калудан яисә җенси мөнәсәбәтләрнең аларга авырту китерүенә зарлана. Күп вакыт бу проблема хатын-кызларның үзләрен түгел, ә аларның ирләрен борчый. Сексопатологларга артык еш җенси мөнәсәбәткә керүчеләр дә килә, әмма андыйлар сирәк.

? Җенси теләк нилектән кими?

Фәнни телдә алибидемия дип аталучы бу көйсезлекнең сәбәпләре күп булырга мөмкин. Кешенең рухи халәтенә дә бәйле ул, нейроэндокрин системага да... Җенси теләк, ягъни либидо организмдагы гормоннардан тора. Кешенең яшен дә исәпкә алмый булмый. Яшүсмер чакта һәм яшь вакытта ул иң югары ноктасында була. Еллар узган саен кешенең җенси ихтыяҗы да табигый төстә кими.

? Фригидлык дигән төшенчә дә бар бит. Бу еш очрыймы? Хатын-кызларның җенси сүлпәнлеген дәваларга мөмкинме?

Фригидлык еш очрый торган җенси көйсезлек төре түгел. Җенси мөнәсәбәтләрнең ешлыгы, әйтүебезчә, яшькә һәм кешенең гәүдә төзелешенә дә бәйле. Берәүләргә интим мөнәсәбәтләр көн саен кирәк булса, кемгәдер атнага яки айга бер дә җитә. Күп кенә хатын-кызларда җенси теләк соңрак уяна. Кайберәүләр 30 яшьтән узганнан соң гына оргазм кичерә башлый. Бала табу да хатын-кызның җенси сизгерлегенә уңай тәэсир итә. Хатын-кызларның рәхәтлек ала алмавы дөрес җенси тәрбия булмавыннан да килә.

? Ә аны ничек дөрес итеп бирергә соң?

Беренчедән, җенси тормыш хакындагы мәгълүматны баладан яшермәскә! Мәгълүмат бала аңларлык дәрәҗәдә һәм дөрес итеп бирелергә тиеш. Ул турыда уйларга иртә әле сиңа, ул начар әйбер, андый әйбер турында уйларга ярамый, дип, балада җенси тормыш турында кечкенәдән үк негатив фикер тәрбияләмәскә кирәк. Мондый негатив караш аңа киләчәктә комачауларга мөмкин.

? Ир белән хатын озак яшәгәндә бер-берсенә шулкадәр ияләшә, аларга хәтта бергә йоклау күңелсез дә була башлый. Мондый очракта бер-береңә тартылуны ничек саклап калып була?

Бик дөрес сорау. Чынлап та, күп еллар бергә яшәп, читтә бернинди дә җенси мөнәсәбәтләре булмаган кешеләрдә бер-берләренә карата суыну күзәтелә. Җенси мөнәсәбәтләрнең тәме югала башлый. Ләкин теләк белән секс бер үк әйбер түгел. Озак еллар бергә яшәгән ир белән хатын бер-берсенә гел тартылып торсын өчен ниндидер әзер рецептлар юк. Кемнәрдер порнографик фильмнар карый. Кемгәдер ире яки хатыны урынына башка берәүне: кайчандыр күзе төшеп йөргән кешене яки бик чибәр артистны күзалдына китерә... Булыша, диләр.

Хатын-кыз җенси тормыштан рәхәтлек кичермәсә, сексопатолог аңа ярдәм итә аламы?

Һичшиксез, ярдәм итә. Ләкин башта аноргазмиянең сәбәбен ачыкларга кирәк. Психологик проблема икән, психотерапия кирәк булачак. Әгәр дә инде нейроэндокрин сәбәп булса, бу очракта дарулар билгеләр. Кайчак оргазм кичерә алмау партнер аркасында да булырга мөмкин. Менә бу очракта инде сексуаль тренинг ярдәм итә ала.

Даими рәвештә җенси канәгатьсезлек кичереп яшәү организм өчен зарарлымы? Оргазмсыз яшәү хатын-кызларда нинди чирләр китереп чыгарырга мөмкин?

Фәндә ниндидер нәтиҗәне фәкать җитди фәнни тикшеренүләргә генә нигезләнеп ясарга була. Секс булмау аркасында сәламәтлеккә нинди дә булса зыян килә икән дигән фараз берничек тә расланмаган. Канәгатьлек ала алмаган хатын-кызлар үзләренә мастурбация белән ярдәм итә ала. Андый хатын-кызлар аз түгел. Оргазм кичерү сәламәтлек өчен, әлбәттә, мөһим.

Хәзер вумбилдинг күнегүләре бик популяр. Кече оча сөяге органнарының мускул зәгыйфьлеге дә җенси тормышка тәэсир итәме?

Җенси орган мускулларының сүлпәнлеге волюистик тоемга (канәгатьлек алуга) тәэсир итми калмый. Әмма бөтенесе дә бу мускулларга гына бәйле түгел. Хатын-кызларда оргазм ике төрле була: клиторга бәйле оргазм һәм табигый оргазм.

Иремне якын да китерәсем килми, хәтта тәнем чиркана, дигән хатын-кызлар бар. Сәбәбе нәрсәдә? Ничек ярдәм итеп була?

Тән чиркану ул – күңелдә шул кешегә карата булган мөнәсәбәтләр чагылышы. Димәк, җанда әйтелмәгән үпкә-рәнҗешләр җыелган. Һәр очракта да сәбәпләрен ачыкларга кирәк. Гаилә психологы ярдәме дә кирәк булуы бар.Әлеге проблема хәтта гаиләнең таркалуына да китерергә мөмкин.

Лилия ГӘРӘЕВА әзерләде.

Беркемгә дә әйтә алмый йөргән сорауларыгызны язып та җибәрә аласыз.

БЕЛМӘСӘҢ — БЕЛ



Наилә ГАЙНАНОВА,
Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының баш белгече, акушер-гинеколог

Хәрәкәттә – бәрәкәт бар, ди халык. Ләкин бүгенге тормыш рәвешебез шундый: аз хәрәкәтләнәбез, эшебез дә күбрәк утырып эшли торган, җәяү йөрү дә сирәк эләгә. Фәндә гиподинамия дип аталучы бу күренеш кан тамырларының акрынлап кысылуына китерә. Гел утыру аркасында мускуллар һәм кимерчәкләр кан тамырларын сыта башлый. Нәтиҗәдә, кече оча сөягендәге органнарга кан тиешенчә барып җитми. Хатын-кызның авыр күтәрүе, тар кием киеп йөрүе, йөклелек тә кан тамырларының кысылуына китерә. Моңа тагын аналыкның бөгелүе дә, кан тамырларының киңәюе дә, табиб күзәтүеннән башка гына бала табу да йогынты ясамый калмый.

Кече оча сөяге органнарында канның дөрес йөрмәве, кан йөрешенең сүлпәнлеге бала табу яшендәге хатын-кызларда авырга уза алмау кебек күңелсезлекләргә китерә. Йөкле ханымнар өчен дә бик куркыныч бу. Әгәр дә кан тамырларының кысылуы инде күптәннән килсә, кан йөрешенең сүлпәнлеге тора-бара бәвел юлларында, җенес органнарында төрле чирләр китереп чыгара. Хатын-кызның тиз кызып китүе, ярсуы, холкының еш үзгәрү сәбәбе дә шушы кан йөреше бозылудан булырга мөмкин.

Кан тамырларындагы кан йөрешенең сүлпәнлеген җитди нәрсәгә санамыйча, дәваламый калдырырга ярамый. Дарулар куллану белән беррәттән, махсус күнегүләр ясау, йога белән шөгыльләнү дә яхшы нәтиҗәләр бирә. Йөзү дә бик файдалы.

Пассив тормыш рәвешен үзгәртү, дөрес туклану, гимнастика, бассейнга йөрү – кан тамырлары тараюдан, кан йөреше бозылудан саклануның иң беренче баскычлары. Оча сөяге тирәсе мускулларын ныгытучы махсус күнегүләр дә бар. Алар катлаулы түгел, шул ук вакытта хатын-кызларга үз организмнарын яхшы формада тотарга булыша, кече оча сөяге органнарында кан әйләнеше бозылу аркасында килеп чыгарга мөмкин күп кенә патологияләрне булдырмый кала.

Һәр хатын-кыз үзлегеннән ясый ала торган берничә күнегүне генә мисалга китерәбез.

- Мөмкин кадәр тирәнрәк сулыш алып, эчне кабартабыз. Сулышны 10 секундка тоткарлап, эчне булдыра алганча эчкә тартабыз һәм сулышны көчәнеп чыгарабыз. 7–10 тапкыр кабатлыйбыз.

- Идәнгә ятып, арканы күтәрәбез. Баш чүмече һәм арт сан (утракса) идәннән аерылмый. Моны да 7–10 тапкыр кабатларга кирәк.

- Аркага ятып, иңбашларны, терсәк, баш чүмечен идәнгә терибез, аякларны 90 градуслы почмак белән өскә күтәрәбез (классик «Березка» позасы). Билне куллар белән терәтеп, 2 минутлап шушы хәлдә торабыз. Аннары аякларны төшерәбез. 10 тапкыр кабатлыйбыз.

- Гимнастика тубы белән ясаган күнегүләр дә бик файдалы. Мәсәлән, тупка башта арка белән, аннары эч белән ятып, яртышар сәгать туп өстендә тәгәрибез.

PRESSA.RU



Рафаэль ШӘВӘЛИЕВ,
Республика клиник балалар хастаханәсенең баш табибы

ПРИВИВКА: ЯСАТЫРГАМЫ, ЮКМЫ?

Бүген Россиядә ел саен бер-ике яңа төр вакцина теркәлә. Совет заманында балаларга прививка ясату мәҗбүри булса, хәзерге көндә бу эш ата-аналарның язмача рөхсәте белән генә башкарыла. Һәм күпчелек ата-аналар прививка ясатыргамы, әллә аннан баш тартыргамы дигән сорау алдында кала.

Иң элек «нәрсә соң ул вакцина?» дигән сорауга җавап биреп китик. Вакцина – үтерелгән яки көчсезләндерелгән бактерия һәм вируслардан торган препарат ул. Аны керткәч, организмда иммун системасын саклый торган антитәнчекләр барлыкка килә. Актив ясалма иммунитет (табигый иммунитет чир кичергәннән соң барлыкка килә) вакцина ясап, ике-өч атна вакыт үткәннән соң формалаша һәм айлар, хәтта еллар дәвамында саклана. Хәзерге вакытта берьюлы берничә инфекциядән саклый торган вакциналар бар. Мәсәлән, элек дифтериягә каршы бер прививка ясасак, коклюштан (бума ютәл) – икенчене, йогышлы тартышу авыруыннан (столбняк) өченчене ясый идек. Ә хәзер өч инфекциядән бер вакцина ярдәмендә генә дә сакланып була.

Профилактик прививкалар календаре буенча, Россиядә вакцинаны баланың беренче көннәреннән үк ясый башлыйлар. Беренчеләр рәтенә В гепатитына каршы прививка керә. Бала тудыру йортыннан чыгарыр алдыннан балага туберкулезга каршы вакцина (БЦЖ) ясала. Һәм бер яше тулганчы балага коклюш, дифтерия, йогышлы тартышу авыруына (столбнякка) каршы прививка, ә авыруларга бирешү куркынычы зур булган категориягә кергәннәргә гемофилия инфекциясенә каршы прививка да ясатып өлгерергә кирәк.

Икенче яше киткәч, кызамык, паротит һәм кызылчага каршы вакцина ясала. Чит илләрдә һәм Россиянең кайбер төбәкләрендә бу яшьтәге балаларга мәҗбүри рәвештә пневмококк, папиллома вирусы, ротовирус, менингококк инфекциясе, талпан энцефалиты һәм А гепатитына каршы прививка да эшләнә.

Балтыйк буе илләрендә, АКШ, Австралия, Канада, Германиядә бала туугa, аңа 12–15 инфекциягә каршы прививка ясап куялар.

Без, табиблар, беравыздан, прививка ясатырга кирәк, дибез. Вакцина йогышлы чирләрдән саклау өчен ясала, ә андый авырулар күпчелек очракта начар тәмамлана. Авыру кичергәннән соң, гомерлеккә инвалид калган, хәтта савыга алмыйча гомерләре өзелгән балалар да бик күп. Ә вакцина ясату ел саен 3 миллион үлемне булдырмый калырга мөмкинлек бирә.

Хәзерге вакытта профилактик прививкаларны сырхауханәләрдә дә, прививка ясауда махсуслашкан клиникаларда да ясыйлар. Балага ясалган вакцина турында һәр мәгълүмат аның амбулатор картасына язылып бара. Ул мәгълүмат бала бакчага һәм мәктәпкә барганда кирәк булачак. Прививка картасы булмаса, бакча һәм мәктәпләрдә баланы кабул итмиләр.

Прививка ясатудан баш тартып, балагызның сәламәтлегенә һәм тормышына куркыныч тудырасыз – шуны онытмагыз!

Ничек әзерләнергә?

- Прививка сәламәт балага гына ясала. Әгәр балагыз авырып торса яки авыргаңнан соң тулысынча сәламәтләнеп бетмәгән булса, прививка ясатуны кичектереп торыгыз. Баланың тән температурасы нормальләшкән, ләкин ютәле, томавы бетеп җитмәгән икән, шулай ук сабыр итәргә кирәк. Салкын тиюнең җиңелчә төре яки эчәк инфекциясе бул ганда, вакцинаны баланың тән температурасы төшүгә ясатырга рөхсәт ителә.
- Бабасыр, лямблиоз, аскаридоз ише паразитлар булганда прививка ясатырга киңәш ителми. Бу паразитларның организмга эләгүе иммунитетның инде какшаган булуын күрсәтә, шуңа күрә вакцина кешене кирәк дәрәҗәдә саклый алмый.
- Климат кинәт алышынганда (әйтик, бала җылы яктан ялдан кайтуга) прививка ясатуны кичектереп торырга кирәк. Ике-өч атна эчендә организм яңа климатка ияләшә, прививканы шуннан соң ясыйлар.

ЕШ БИРЕЛӘ ТОРГАН СОРАУЛАР

Аллергиясе булган балага вакцина ясарга ярыймы?

– Күпчелек очракта вакцина ясарга ярый. Астма, атопик дерматит, аллергик ринит булганда балага зур дозада глюкокортикоид (гормонның бер төре) бирелмәсә, прививка ясарга рөхсәт ителә. Тавык йомыркасына аллергия булган балаларга кызамык, кызылча, паротитка каршы вакцина ярый, ә грипкка каршы прививканы махсус клиник шартларда ясарга кирәк.

Ни өчен кайбер балалар прививка ясалган булса да авырый?

– Вакциналарны саклау дәрәҗәсе дә, балаларның организмы да төрле. Мәсәлән, кызамык, кызылча, паротитка каршы прививка ясалган 100 баланың бишесе бу авыруларның берәрсе белән чирләргә мөмкин. Ләкин алар авыруны прививка ясалмаган яшьтәшләренә караганда җиңелрәк кичерәчәк.



МАТУРЛЫК ВИТАМИННАРЫ

Һәрберебез яшьлеген озынайтырга хыяллана. Матур булып калу өчен ниләр генә эшләмибез! Ләкин матур күренү өчен кремнар куллану гына җитми, беренче чиратта сәламәтлекне кайгыртырга кирәк. Организмга бик кирәкле матурлык витаминнары турында кардиолог, терапевт, Евразия терапевтлар ассоциациясе әгъзасы Альбина ШАҺИДУЛЛИНА сөйли.

А ВИТАМИНЫ (ретинол). Тән тиресе һәм чәчләр матурлыгы, күзләр сәламәтлеге өчен кирәк.

УЛ ҖИТМӘСӘ А витамины җитмәүнең беренче билгеләре: чәчләр сынучанга әйләнә, кавыклана, күз күрүе начарая, тән тиресе корый. Гинекологлар эрозия, полип, мастопатия кебек авыруларның барлыкка килүендә дә А витамины җитмәүне сәбәп итеп күрсәтә. Ретинол организмдагы коллаген синтезын яхшырта, шул рәвешле тән тиресенең тыгыз, шома булуын тәэмин итә.

B_9 ВИТАМИНЫ (фолий кислотасы). Тирене пигментлы таплардан, җыерчыклардан саклый, тырнакларны ныгыта, чәч коелуны туктата һәм аның үсешен тизләтә.

УЛ ҖИТМӘСӘ Организм тиз һәм еш хәлсезләнсә, тик торганда күпләп чәч коелса, тырнаклар сына башласа, B_9 витамины җитми дигән сүз. Аның организмга тиешле күләмдә кермәве анемия, тромб барлыкка килү ихтималлыгын да арттыра. Менопаузаны җиңелрәк кичерергә дә B_9 витамины ярдәм итә.

С ВИТАМИНЫ (аскорбин кислотасы). Табигый антиоксидант (картаю процессын тоткарлый, коллаген эшләп чыгаруда катнаша), шулай ук теш урты һәм тешләр өчен бик файдалы.

УЛ ҖИТМӘСӘ Тән тиресе корый, яргалана, төсен җуя. Теш урты еш каный, тешне чистартканда авырта башлый. Хәтта тешләрнең төшүенә дә китерергә мөмкин.

Н ВИТАМИНЫ (биотин). Органнарның лайлалы тышчасы сәламәтлеге, организмдагы майны «яндыру», углеводлар алмашын көйләү өчен кирәк.

УЛ ҖИТМӘСӘ Тел кору, яргалану, төсе тоныклану, авыз тирәсе бозылу (дерматит) – биотин җитмәү билгеләре. Рационга Н витаминына бай ризыклар кертмәсәң, конъюнктивит, даими рәвештә күңел болгану, аппетит бозылу, хәлсезлек, депрессив халәт, йокы килү, чәч коелу күзәтелә башлый. Шулай ук организмда холестерин һәм шикәр күләме арта, анемия барлыкка килә.

Е ВИТАМИНЫ (токоферол). Эстроген гормоны эшләп чыгаруда катнаша, тиредәге дымлылыкны саклый һәм күзәнәкләрдәге кан әйләнешен яхшырта.

УЛ ҖИТМӘСӘ Матдәләр алмашы бозыла, җенес гормоннары бүленеп чыгу кими, хәтер һәм күз күрүе начарая. Балага узарга теләгән һәм инде йөкле булган хатын-кызлар өчен бу витамин аеруча да кирәк: ул яралгыны саклый торган гормоннар бүлеп чыгаруда катнаша, баланың физик һәм психик үсешен тәэмин итә.

D ВИТАМИНЫ (кальциферол). Сөяк, теш, тырнак һәм чәч ныклыгы өчен җавап бирә, иммунитетны ныгыта, нерв, йөрәк-кан тамырлары системалары эшчәнлеген көйли.

УЛ ҖИТМӘСӘ Тешләр эштән чыга: кариес барлыкка килә, тешнең эмале ныклыгын югалта, сары яки соры төскә керә. Кәеф еш һәм тиз үзгәрә башлый, тиктомалдан кызып китү, юкка да чыгырдан чыгу, агрессия күзәтелә. Менопауза вакытында D витамины җитмәсә, остеопороз барлыкка килү куркынычы арта.

Организм үзенә кирәкле витаминнарны һәм микроэлементларны табигый продуктлардан алырга тиеш. Табиб белән киңәшмичә даруханәдән витаминнар сатып алырга ашыкмагыз!



PRESSA.RU

КАЗАНЧА ТАПАЛГАН ИТ



Татарстанның атказанган артисты Алсу ӘБЕЛХАНОВА – татар эстрадасындагы чибәр, зәвыклы артистларыбызның берсе. Әле Казан дәүләт консерваториясендә белем алганда ук бәрхет тавышы, затлы сәхнә киемнәре белән тамашачы күңеленә юл сапкан җырчы ул. Воркутада туып, Ульяновскида үсеп, Казанда укыган Алсуны бүген татар дөньясында белмәгән, танымаган кеше бар микән? Кемдер аның 1990 нчы еллар ахырында сәхнәдә әле беренче генә адымнарын ясаган чагын хәтерлидер, кемдер «Европа-Плюс» радиосы яки «Татарстан–Яңа гасыр» каналында «Хәерле иртә» тапшыруы аша беләдер. Әйе, балачактагы журналист булу хыялы аны – инде танылган җырчыны «Останкино» телевидение мәктәбенә алып килә.

...Ә гадәти тормышта Алсу – Әмир белән Солтанга кайгыртучан әни, ире Радикның иркә хатыны һәм, билгеле инде, ачык йөзле уңган хуҗабикә. Аш-суга хирыслыгы гомере буе ашчы булып эшләгән әнисе Җәүһәриядән аның. Алсуга бар да тиз булсын, тәмле һәм... матур булсын. Ә иң мөһиме: аның пешергәне кадерле егетләре күңеленә хуш килсен. Бу осталык дәресебездә дә ул, егетләренең күңелен күрим, дип, мичтә яшелчәләр белән ит пешерде.



Кирәк:
• 600 г сум ите;
• 200 г гөмбә;
• 4-5 помидор;
• 1 баш суган;
• икешәр аш кашыгы майонез һәм кибет каймагы (майлылыгы мөһим түгел);
• 100 г каты сыр;
• тәменчә тоз-борыч, таба майларга үсемлек мае.


Фото: Ксения Богданова

Эш барышы:

■ итне юып, җепселләренә аркылы бер бармак киңлегендә итеп уч яссуы кадәр кисәкләргә турыйбыз. Һәр кисәкне полиэтилен капка тыгып, агач тукмак белән тапыйбыз.

■ Тапалган итне төбе майлы табага тезеп, тоз һәм борыч сибәбез.

■ Шампиньон гөмбәсен юып, юка итеп турыйбыз һәм ит өстенә тезәбез.

■ Гөмбә өстенә боҗралап туралган суган телемнәре куеп чыгабыз.

■ Каймак белән майонезны бергә кушып, соус ясыйбыз. Соусны суган өстеннән мул гына итеп ягабыз. Аның өстенә вак угычтан уылган сыр сибәбез. Сыр да аз булмасын, күп булган саен – тәмлерәк.

■ Сыр өстенә юка итеп киселгән помидор телемнәре тезеп чыгабыз.

■ Ит кисәкләре арасына тәм өчен бер-ике борчак кара борыч һәм дәфнә (лавр) яфрагы кыстырырга да мөмкин.

■ Итле табаны бер сәгатькә 180 градуска кадәр кыздырылган мичкә урнаштырабыз. Кибеп китсә, аз гына кайнаган су өстәргә була.

■ Табынны яшел аш тәмләткеч үләннәр, тозлы кыяр һәм яшелчәләр белән бизәп чыгарабыз.

Фәйрүзә Хисамиевадан

«ФАНТАЗИЯ» САЛАТЫ



Кирәк:

- 1 банка ак фасоль (үз суында, 400 г);
- 400 граммлы 1 банка консервланган ананас (боҗралысы);
- 400 г тавык түше;
- 300 г корейча әзерләнгән кишер;
- майонез.

Эш барышы:

■ Тавык түшенә майонез, аджика һәм тәменчә генә тоз салып ясалган соус ягып, духовкада кыздырабыз.

■ Суынган тавык итен эрерәк кисәкләргә турыйбыз.

■ Фасольнең суын сөзеп, җылымса су белән чайкатабыз. Артык суыннан арындырабыз.

■ Ананасның ширбәтен саркытып, вак шакмаклап турыйбыз.

■ Корейча әзерләнгән кишер бик озын булса, бераз кыскартабыз.

■ Тирән савытка тавык ите, фасоль, ананас, кишер салып, майонезны тәменчә өстәп бутыйбыз.

PRESSA.RU

МОДА УЛ – ВИРУС

Танылган имиджмейкер, стилист Надежда ӘЮПОВА белән быелгы язгы мода һәм арзанга гына матур киенү хакында сөйләшмәкче идек, Ул моданың без бөтенләй белмәгән якларын ачып салды.

Фото: Елена Хәсәнова

Хаталар

– Мода ул – вирус. Матур, затлы күренәм дип, беркайчан да модага иярмәгез. Аннары, дөнья модасы һәм безнең Казандагы мода – алар икесе ике нәрсә һәм икесе ике дөньядан. Казан модасы – кытайлар арзанга нәрсә тәкъдим итә, шул. Бездә күпме генә кеше Миланга барып, быелгы коллекциядән кием сатып алыр икән?! Европада тегелгән кием сирәк кибетләрдә сатыла, алар кыйммәт.

Шуңа да мода турында түгел, бәлки, хатын-кызга ничек матур итеп киенү, затлы, зәвыклы итеп күренү хакында сөйләргәдер. Яшермим, кибетләрдәге халык сатып ала алырдай кием белән затлы күренүе кыен. Алар, бердән, тар, кыска, ачык; икенчедән, начар синтетик тукымадан, сыйфатсызлыгы белән әллә каян кычкырып тора. Ә бит андый начар кием сатып алу өчен без артык бай түгел. Ике-өч тапкыр киюгә төерчекләр барлыкка килә, рәвешен югалта, электрлаша, чүп җыя. Андый кием тәнгә дә рәхәт түгел.

Бездә зәвыклы итеп бик азлар гына киенә белә. Күпчелек ачык кием киярге – секси күренергә ярата. Моның сәбәпләре төрле: ир-егетләргә ошыйсы килү, шатлык-куанычлар аз булу, кибеттән яхшырагын сайлау мөмкинлеге булмаганга... Карагыз сез урамдагы хатын-кызларга: тар чалбары ботына сыланып, бөтен җитешсезлеген күрсәтеп тора. Шушы тар чалбарга кыска топ һәм кыска кардиган кигән. Бу бит модалы киенү түгел, бу – фигураңның бөтен кимчелеген ачып күрсәтү! Болай да тазарак гәүдәле ханымнарның өске ягы – киң, итәге тар синтетик күлмәк кигәнен күрсәм, бөтенләй кәефем төшә. Югыйсә яхшы тукымадан иркенрәк итеп тегелгән күлмәк кисә, нинди күркәм күренәсе ул! Юк, иркен күлмәк үзен тагын да тазарак күрсәтә дип саный. Тар кием кияргә яратасың икән, рәхим ит, ябык! Кем комачаулый? Матур гәүдәле ханымга бөтен кием килешә.

Ничек киенергә?

Затлы киенгән ханым әллә кайдан аерылып тора. Беренчедән, аның киемнәре ябык. Икенчедән, йон, ефәк, кашемир, җитен, киҗемамык, ягъни табигый тукымалардан тегелгән. Ул ялтыр-йолтыр килеп торган арзанлы бижутерия кулланмый. Күлмәген тагын да матуррак күрсәтер өчен чын ефәктән тегелгән искиткеч матур шарф тагарга мөмкин. Һәм син аны әнә шул шарфыннан хәтерләп каласың да.

Һәр хатын-кызның шкафында бер генә булса да кыйммәтле яхшы күлмәге булырга тиеш. Әлбәттә, ул бик яхшы табигый тукымадан тегелгән; гәүдәгә сыланып, кысып тормый. Ачык беж, ачык көрән кебек табигый төслене алырга киңәш итәм. Футляр күлмәкләрдән баш тартырга кирәк. Алар бик аз кешегә генә килешә.

Затлы күлмәк өстеннән күн куртка яки сырган пуховик кимиләр. Күн куртка киеп, гомумән дә затлы күренүе кыен. Шуңа күрә плащ алырга кирәк. Беж төсендә, әйбәт крой белән – тездән түбән итеп тегелгән яхшы плащ. Җәйге салкынча көннәрдә дә кияргә була аны. Плащ бөтен кием белән килешә.

Салкын вакытта кияр өчен пальто кирәк. Ә иң яхшысы – ике пальто, берсе – ак, икенчесе кара төслене. Йон яки кашемирдан тегелгәнне. Яхшы тукымадан тегелгән киемнәр озак хезмәт итә: тузмый да, төерләнми дә, кыршылмый да.

Берара хатын-кызлар арасында күн чалбар модада булды. Мондый чалбар кигән ханым кырыйдан караганда шулкадәр көлке күренә. Аны бит көне буе киеп йөрү мөмкин дә түгел. Гомумән, җөе тәнне кисеп керердәй тар киемнән –

чалбармы ул, күлмәкме, пиджакмы – баш тартырга кирәк.

Джинсы чалбар кияргә яратучыларга аннан баш тартырга димим. Әмма сыланып тормаганын һәм, һичшиксез, изүе ябык ефәк блузка яки топ белән. Затлы челтәр кофта белән дә матур булачак. Топ өстеннән пиджак яки бәйләнгән кардиган кияргә була. Пиджаклар һәм кардиганнар һәрвакыт актуаль. Әмма пиджакның да тарын түгел, ә янбашына кадәр төшеп торганын, иркен итеп тегелгәнен алырга кирәк. Мәсәлән, хәзер кызыл төс модада. Әмма кызыл белән кызылның аермасы бар. Бер кешегә килешкән кызыл төс башка кешегә килешми, аңа кызылның башка төсмере барадыр, бәлки. Кызыл төс һәрвакыт модада булачак.

Аяк киеме һәм сумка

Хатын-кызның бөтен гардеробы аяк киеменә нигезләнә. Яз өчен кимендә өч аяк киеме булдырырга кирәк. Беренчесе – уңайлы, калын үкчәле батильоннар. Икенчесе – тигез табанлы яки тәбәнәк платформадагы кроссовки, слипон, лофер, мокасин ише бик уңайлы аяк киеме. Өченчесе – үкчәле туфли, бәлки, лодочкалардыр. Төсе – беж, фил сөяге, тән төсендә, аз гына алтынсу төс йөгертелгән дә булырга мөмкин. Мондый туфлиләрне сез теләсә кая, теләсә нинди кием белән кия алачаксыз. Әлбәттә, алар яхшы күннән тегелгән булырга тиеш. Ясалма күннән тегелгән, шуның өстенә ялтырап торган аяк киемнәре турында түгел сүз.

Сумкада да, аяк киемендә дә бернинди дә артык детальләр булмасын. Ялтыравык әйберләрне тормышында бәйрәм җитмәгән хатын-кызлар ярата. Ә безгә хатын-кызның нәфислеген, затлылыгын алгы планга чыгарырга кирәк. Сумка белән аяк киеме, перчатка бер төстән булырга тиешме, дип сорыйлар. Әгәр дә сумка һәм перчатка бер комплекттан икән, бу мөмкин. Юк икән, кирәкми. Бер кибеттән зәңгәр сумка алып, икенче кибеттән аңа иш перчатка эзләп йөрү кирәкмәгән эш. Барыбер төсләрне туры китерә алмассыз.

Лилия ГӘРӘЕВА әзерләде.



Киңәш

Быелгы язгы-җәйге мода үзенең демократиклыгы белән үзенчәлекле.

■ Моданың төп юнәлеше – уңайлылык һәм комфорт.

■ Көндәлеккә кия торган киемнәр сыйфатлы табигый тукымалардан тегелә. Алар тәнгә йомшак, хәрәкәтләрне чикләми.

■ Быел язгы-җәйге сезонда сыйфатлы трикотаж һәм бәйләнгән әйберләр модада.

■ Денимнан тегелгән киемнәр модага кире кайта: биле биек чалбарлар, күлмәк, сарафан, джинсы куртка – бар да актуаль булачак. Бигрәк тә ак төстәге джинсы киемнәр.

■ Кызыл төс беркайчан да модадан чыкмастыр, мөгаен. Быелгы сезонда күлмәк, пиджаклар гына кызыл төстә түгел, хәтта плащлар да кызыл.

■ Язгы ачык төсләр модада. Алсу һәм фирүзә, кызыл сары һәм алсу... төсләрнең ярашуы төрлечә булырга мөмкин. Шулай ук күп кенә танылган сәүдә йортлары яшел төс тәкъдим итә.

■ Яңа сезонда бахрома кире кайта. Бахрома сумкаларны гына түгел, итәк, күлмәк, хәтта җәйге пальтоларны да бизи.

■ Ерткыч җәнлек тиресе быел да популяр. Хәер, аның модадан чыгып та торганы булмады бугай.

■ Яшь-җилкенчәк өчен поп-арт актуаль. Модельерлар үз коллекцияләрендә төрле персонажларны бик иркен куллана. Яраткан героегызның йөзе сурәтләнгән футболканы урамда бик рәхәтләнеп кия аласыз.

■ Спорт темасы беркайчан да актуальлеген югалтмады. Үзеңне спортка кагылышлы итеп күрсәтү – хәзер модада. Спорт костюмыннан йөрү дигән сүз түгел бу, киемдә спортка кагылышлы бер-ике элемент булу да җитә.

PRESSA.RU

Ишегалдын тутырып гөлләр үсмәсә, җәйнең ни яме?! Хәзер кибеттә нинди генә чәчәк орлыгы юк! Үстермәм дигән җирдән алып үстерерсең. Апрель ае тәрәзә төбенә берьеллык чәчәк орлыклары чәчү вакыты. Чуптар чәчәкле бәрхет гөл, настурция, циния, кашкарый (астра), петуния, арыслан тамагы (львиный зев) – безнең шартларда бик рәхәтләнеп үсә, төсләре аллы-гөлле, тиз чәчәк ата, озак куандыра торган гөлләрдән.



ГӨЛБАКЧАДА ЭШЛӘР БАР

■ Әле утыртмаган булсагыз, апрельнең беренче атналарыннан да калмый, петуния белән кашкарыйны һәм арыслан тамагын тәрәзә төбендәге тартмаларга чәчәргә кирәк. Петуниянең орлыгы үтә дә вак, туфрак белән күмдерсәгез, тишелмәскә дә мөмкин. Шуңа күрә аны дымлы туфракка гына чәчәләр. Чәчәкләре мул булсын өчен, үсемлекне тармакландырырга кирәк. Биш чын яфрагыннан соң сабак очын өзеп алсагыз, петуния ян тармаклар биреп, купшырак булачак.

■ Арыслан тамагының биек булып та, тәбәнәк булып та үсә торган төрләре бар. Кояшны ярата, артык тыгыз итеп утыртсаң, бер-берсенә комачаулый. Чәчәкләре төрле-төрле ачык җете төстә була, бик матур, кырауларга кадәр өзлексез чәчәк ата. Чәчәк сабагындагы бер бөре тәмам ачылганда, икенчесе ачылып, ә өченчесе әле тулышып кына килә. Озын төрләрен букетка да кисәргә була.

■ Настурциянең орлыгы эре, каты кабыклы. Аны туфракка гына чәчәләр, әмма чәчәр алдыннан бер тәүлек җылымса суда бөрттерсәң яхшы. Настурция берьеллык дип саналса да, безнең җирлектә көзгә аның орлыклары өлгереп, туфракка коела һәм икенче язда үзлегеннән тишелеп чыга. Ул да чәчәккә тиз бөреләнә һәм сары, кызгылт сары, кызыл эре чәчәкләре белән көзгә кадәр күзне иркәли. Талымлы да түгел үзе.

■ Кашкарыйны белмәгән, яратмаган сирәктер. 1 сентябрь бәйрәме дигәндә, гел шулар күз алдына килә. Аны да уҗымга чәчеп үстерәләр, әмма турыдан-туры җиргә генә чәчәргә дә мөмкин. Алай иткәндә, кәлшәләре аеруча нык була, чирләми. Мәсәлән, үзем көне буе кояш төшә һәм кардан тизрәк арына торган бер урынны казып, кәбестә, циния һәм кашкарый орлыкларын шунда гына чәчәм. Биек булмаган дугалар утыртып, өстен ике катлы лутрасил белән каплыйм (40 яки 60 лы лутрасил-тукыма). Моны елына карап, апрель ахыры яки май башында эшләргә була. Күчереп утыртырлык булып үсеп җиткәч, үз түтәлләренә күчерәм.

■ Җәйге тымызык кичтә йолдызларга карап капка төбендә утырырга кем яратмый?! Шул тирәгә генә май башларында маттиола дигән чәчәк орлыгы сибегез әле. Көндез карап сокланыр өчен купшы гөл түгел ул түгелен. Аның кыйммәте башкада – кичке эңгер төшүгә бөтен тирә-якны оҗмах исенә күмә. Җәй буе капка төбегез хуш искә күмелсен дисәгез, ике-өч атна саен яңаны чәчеп торыгыз. Шулкадәр талымсыз, тиз үсә.

■ Апрель аенда ирис, чалмабаш, флокс, дельфиниум, хризантемаларны да бүлгәләп утыртырга мөмкин. Ирислар өчен җилдән ышык, кояшлы урынны сайлагыз. Чалмабашлар яктыны яратсалар да, кояш нуры көне буе туры караганда аларның чәчәге тиз коела. Күпьеллыкларны август башында да күчерергә була.

■ Апрель аенда кышкылыкка төреп калдырылган гөлләрне дә ачарга кирәк. Төбен каплаган мүлчәне тырмалап алсаң яхшы, югыйсә калын мүлчә катламы аша тамырларга яз җылысы тиз генә үтеп кермәс.

■ Идән асты яки базда сакланган дәлия (георгин) бүлбеләрен дә җылыга чыгарырга онытмагыз. Уяна торсыннар. Дәлияләр җылы ярата. Шуңа да аларны кырау төшү куркынычы беткәч кенә туфракка утырталар. Күләгәлерәк урын кулайрак. Утыртасы оя төбенә су җыелып тормасын өчен, вак таш, кирпеч калдыклары салып калдыралар. Бүлбенең сабак төбендә үсә торган бөреләре була, аларны туфракка күмеп калдырмагыз.

Лилия ГӘРӘЕВА әзерләде.
Фото: www.pixabay


Кучкар. Компромисска һәм килешүләргә барырга туры киләчәк. Үз фикерегездә нык торам дисез икән, йә эшегез, йә дусларыгыз белән хушлашырга туры килмәгәе. Киреләнгәнче, вазгыятькә икенче яктан карагыз.


Үгезбозау. Берникадәр таркаулыктан интегерсез. Мондый хәлдә язмыш биргән мөмкинлекләрне дә абайламый калуыгыз бар. Йолдызбагарлар хыялларга бирелмичә, бүгенге көнне уйларга киңәш итә.


Игезәкләр. Вакыйгаларга бай ай. Моңарчы хәл ителми калган мәсьәләләр баш калкытачак. Бу ай барлык кирәкмәгән нәрсәләрдән арыну өчен яхшы вакыт: кирәкмәгән киемнән, күңелне борчыган уйлардан, яман гадәтләрдән...


Кысла. Кайчандыр кылган хатаны төзәтеп, киләчәкне бераз үзгәртү форсаты чыгар. Мөгаен, бу ай тормышыгызның иң уңай чоры булмас. Тагын бер мөһим киңәш: хисләрегезне яшермәскә тырышыгыз.


Арыслан. Тормышыгызда тотрыклылык һәм гармония хөкем сөрер. Бу айда барысы да кирәгенчә барачак. Сизгерлек бар сездә. Йөрәгегезне тыңласагыз, ялгышмассыз.


Сөмбелә. Язмыш сезнең белән дуслашмакчы, күрәсең. Бик уңышлы ай. Әмма вак-төяк нәрсәләргә көчегезне һәм вакытыгызны исраф итеп, уңышны качырырга да озак түгел.


Бизмән. Уңыш тавының түбәсендә торасыз, шуны абайлыйсыз микән? Үзегездә таулар күчерерлек көч барлыгына инанырсыз. Кызып китә торган гадәтегез бар, холкыгызны йөгәнләргә кирәк, югыйсә якын дустыгызны югалтырсыз.


Чаян. Тормышыгызның ак юлына килеп кердегез. Иҗади, юмарт, киң күңелле Чаяннарга язмыш бигрәк тә хәерхаһлы. Нindидер файдалы бер эш килеп чыгар. Алай да үз көчегезне дөрес бәяли күрегез.


Укчы. Хезмәтегезнең татлы җимешен татырсыз. Бу матди керем генә түгел, абруегызның да артуы булыр. Эш дип, кайчак гаиләгезне дә онытучан сез, боларны бизмәнгә салырга туры килмәгәе.


Кәҗәмөгез. Мәшәкатьле, әмма уңышлы ай. Уңышның нигезендә хезмәт сөючәнлегегез һәм җитезлегегез ята. Үзегезгә карата хөрмәт тоярсыз. Якыннарыгызның берәрсе зур уңышы белән сөендерер.


Сукояр. Айның беренче яртысы зур әйберләр сатып алу, нindидер килешү төзү яки мөһим эшләргә алыну өчен бик яхшы вакыт. Бу айда башланган танышлык зур дуслыкка әверелер. Йолдызлар сезнең яклы.


Балык. Уңышны койрыгыннан эләктерә торган ай бу. Язмыш сезгә бик күп мөмкинлекләр ача. Аның фәрманы белән гел нәкъ кирәкле вакытта, кирәкле урында булырсыз.

апрель дә кабынган йолдызлар

Татарстан



Миләүшә Айтуганова (5.04.1963) – **журналист, продюсер, тарих фәннәре кандидаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.**

Популяр җырлар авторы Ләбиб Айтугановның кызы. Балачагыннан ук балалар табибы булырга хыяллана. Журналистикага этәргеч биргән кеше ул вакытта «Зеленодольская правда» газетасында практика үтүче Венера Якупова була. Быел аның журналистикага килгәненә утыз ел. Студент елларыннан ук радиода эшли (1986–1998). 1998–2002 елларда «Татарстан» дәүләт теле-радио комитеты рәисе урынбасары, 2002–2016 елларда «Татарстан–Яңа гасыр» компаниясе җитәкчесе урынбасары, баш продюсер. 2005 елдан Казан дәүләт культура институтында кино һәм телевидение режиссурасы кафедрасын җитәкли, профессор. Узган елның апреленнән «Татаркино» дәүләт оешмасы директоры.


Россия



Валерия (Алла Перфилова) (17.04.1968) – **Россиянең халык артисты, җырчы.**

Саратов өлкәсенең Актарск шәһәрендә туа. Музыка мәктәбендә эшләгән әти-әнисе аны кечкенәдән музыка белән үстерә. Мәктәпне тәмамлап, 1985 елда Мәскәүнең Гнесиннар исемендәге музыка-педагогика институтына укырга керә. Иосиф Кобзон һәм Елена Великанова классында укый. Тамашачы аны беренче тапкыр 1992 елда «Утренняя звезда» конкурсында күрә. Шул ук елны инглизчә беренче альбомын яздыра. 1993 елны икенче ире – продюсер һәм җырлар авторы Александр Шульгин белән яңа альбомга керешә. 2002 елда Валерия, шоу-бизнес белән арасын өзеп, Актарскига кайтып китә. Әмма озакка түгел, тагын бер елдан Иосиф Пригожин белән әзерләгән «Страна любви» альбомы чыга.

Чит илләр



Энди Макдауэлл (21.04.1958) – **актриса һәм модель.**

Американың Көньяк Каролина штатында туа. Әнисе музыка укытучысы була. 1980 нчы еллар башыннан модель бизнесына керешә. Күпләр әле дә аны «L'Oreal» фирмасының реклама роликлары аша таный. Экраннарга беренче тапкыр 1984 елда «Грейстоук: Легенда о Тарзане, повелителе обезьян» фильмында уйный. Станиславский методы буенча актерлык осталыгы дәресләре ала. Танылу аңа «Секс, ложь и видео» фильмыннан соң килә. Без исә аны «Вид на жительство», «День сурка», «Четыре свадьбы и одни похороны» фильмнары аша беләбез. «День сурка» фильмындагы роле өчен «Сатурн» премиясенә лаек була.

Фото: www.usiter.com
prikolnye-kartinki.ru

PRESSA.RU





«МИН ШУЛАЙ КҮРӘМ...»

Табигатьтәге нәзберек бизәкләрдән фәлсәфи мәгънә табып, яшәү асылына якынаю омтылышын фотосурәттә чагылдыра белү – сирәкләргә бирелгән сәләттер. Андый фотосурәтчылар иҗаты кемне дә битараф калдырмый: табигать могҗизаларына күзеңне ача, йокымсыраган уеңны сискәндерә, әйләнә-тирә мохит белән яңача аралашу теләге уята. Танылган язучы Марсель Галиевнең 50 ләп эшен берләштергән «Тынлык дәшкәндә» дип аталган фотокүргәзмәне караганнан соң да үзеңдә нәкъ менә шундый ихтыяҗ барлыгын тоясың. Гүя автор һәр фоторәсеме белән Раббыдан илһамланган табигатьнең үзенең дә кабатланмас иҗатчы икәнен раслый. Үзең дә сизмәстән, күр инде, юкса без дә шундый ук урманнардан йөрибез бит, нигә соң бу хикмәтләр безнең күзгә-башка чалынмады икән дип гаҗиз каласың хәтта. Сәнгать белгечләре исә Марсель Галиев эшләрендә табигатьнең шундый самими, ихластан илаһи иҗаты – әверелүләр темасын күреп, моны ачыш, сынлы сәнгатьтә яңа бер сәхифә дип атады.

Автор белән бергәләп урман хәятен гизгәндә, чыннан да шулаймы соң бу, кебек сораулы-өндәүле фикерләргә урын калмый шикелле. Чөнки барысы да ничек бар шулай, сәнгати ялангач халәттә «уянган». Монда син тарихи шәхесләрдән – «Семирамида». «Нурсолтан», «Скиф яугире», «Мөрид Шамил»не дә, «Шамбала изгеләре», «Урман ияләре»н дә күрә аласың. «Биюче гөмбәләр» циклына нинди генә гөмбәләр кермәгән. Гади генә гөмбә дә әллә нинди, күз күрмәгән экзотик зат булып кабул ителә. Чәчәкләр таҗыннан ялалып чыккан «Галәм хуҗасы», «Лемуриец», «Җил иясе» кебек фотосурәтләрен автор «Фитографика» дип атаган.

– Фотоаппараты бик шәптер инде аның, – диләр күргәзмәгә килгән кешеләр. Марсель Галиев әллә нинди катлы-катлы объективлары булган фотоаппарат асып йөрми – күзенә берәр матур күренеш чалына калса, кесәсендә йөрткән уч төбе чаклы фотоаппаратын ала да... «Яшәүнең кызыгын таба белсәң, КҮҢЕЛЕҢ АЯЗ БУЛСА ГЫНА сурәткә җан өртелә...»

Хикмәт шунда: язучының сүздән – сурәткә, сурәттән мәгънә чыгаруга ирешүе – табигатьне сизгер тоя белүеннән киләдер. Чатыртауның җилен дә мәҗүсиҗанлы итеп, «Галибанә татар моңын» да тарихи эпохаларны бер учка җыеп, гаҗәеп образлы тел белән тасвирлаган әдипнең **сүз сурәтеннән күз сурәтенә** күчү мәленең шаһитлары без бүген. Рәссам рухлы әдипнең урман дөньясындагы кыргый да, зиһенле дә садәлек асылын кеше җанына якынайтып, үз фәлсәфәсенә төреп бирә белүе соклангыч! Казан тирәсендәге урманнарга Күк катларыннан мөкәммәл сәнгать әсәрләре индерелгән дип кем уйлаган?!

Күргәзмәне карагач, Фәндәс Сафиуллин болай дигән иде: «Бу – философ-фотографның күңел тоемына корылган иҗаты. Язучы философ булганда гына иң тирән каләм иясе була, чын язучы булганда гына иң тирән философ була. Марсельнең язмышына менә шушы ике бәхет тәңгәллеге бирелгән».

Марсель Галиев үзе исә, гадәтенчә, бераз шаяртып:


– Урманда мин аучы кебек йөрим. Агачларны үземә ияләштерәм. Аларга да соклана белгән тамашачы кирәк. Алар мине үзләре дәшеп китерә. Берәр агач янында озаграк юансам, әйләнә-тирәдәгеләре көнләшә башлый. Мин шулай күрәм... – ди.

Расиха ФАИЗОВА








МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ

Семирамида (фитографика)
Каен елмаюы
Борынгы кош
Атилла
Гуцул («Биюче гөмбәләр» циклыннан)
Гуру (укытучы) («Биюче гөмбәләр» циклыннан)
Па дан соң («Биюче гөмбәләр» циклыннан)
Ул белә...
Атилланың акыны Баянҗар
Урман ияләре

PRESSA.RU







«Почта России»ның «Подписные издания» (ПАП) рәсми каталогы буенча ЖУРНАЛЫБЫЗНЫҢ ИНДЕКСЫ П2204

Татарстаннан читтә яшәүчеләр әлегә «Роспечать» каталогындагы элеккеге индекс буенча языла алалар 73002

1 апрельдән 2018 елның икенче яртыеллыгы өчен газета-журналларга язылу башланды



Сайтта: www.syuyumbike.ru
ВКонтактеда: vk.com/suumbike
Фейсбукта: www.facebook.com/syuyumbike
Инстаграмда: www.instagram.com/suyumbike_journal

Журналыбызга онлайн режимда : http://podpiska.pochta.ru сайтында (регистрация узып) языларга мөмкин



Электрон версиягә язылган очракта, яңа санны компьютерда, планшетларда, барлык мобиль җайланмаларда PDF форматта укырга була. **iPad** һәм **iPhone** кулланучылар «Сөембикә» журналының электрон версиясен App Storeдагы «Pressa.ru» киоскына кереп, хатын-кызлар өчен журналлар арасыннан таба ала.
Электрон версиягә язылу турында тулырак мәгълүматны «Сөембикә» журналының сайтында «Язылу» бүлегендә табып була.

16+

РЕКЛАМА